

Әхмәт Рәшит



# Язмыш җилләре

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2006

УДК 821.512.145-1
ББК 84 (2Рос=Тат)-5
Р98

**Рәшит Ә.Ә.**

Р98 Язмыш җилләре: Шигырьләр, поэмалар / Әхмәт Рәшит; Кереш сүз авт. З.М.Мансуров. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2006. — 271 б.

ISBN 5-298-04173-6

Әлеге китапка шагыйрьнең чорыбыз, ил-җир, халык язмышы турында уйлануларын чагылдырган әсәрләре тупланды.

ISBN 5-298-04173-6
© Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Рәшит Ә.Ә., 2006

## *«Мөмкин» белән «түгел» арасы*

Мәңгелек Илаһи затның илчесе итеп җибәрелгән пәйгамбәрләр дә чынбарлыкта аерым заманнарның адәми яшәеше җирлегендә күзаллана. Фани дөнья гамьнәре белән янып яшәүче шагыйрьләргә исә баштанаяк үз чорының улы булып калырга язган. Гомумән, заман рухына буйсынмаган иҗатчы асылда бөтенләй туа алмыйдыр. Мондый хәл бик табигый, чөнки теге яки бу дәвернең җете мөһере сугылган әсәрләр генә чорлар алышынган вакытта үзләренең рухи кыйммәтләрен югалтуга дучар ителмәскә мөмкин. Ә яшәү мәгънәсен чагылдырган иҗатының киләчәк язмышы кайсы каләм әһелен генә бимазалап тормый икән?!

Үзеннән-үзе аңлашыла торган мондый гадәти зарурият югарылыгыннан караган чакта, шагыйрь Әхмәт Рәшит артыгы белән замана баласы буларак күзаллана. Әйе, артыгы белән замана баласы, чөнки шулай әйтергә җирлек бар. Үзебез шаһит, үтеп киткән гасыр гаять каршылыклы иде: иҗтимагый, социаль, идеологик яктан гына түгел, шуларга бәйле рәвештә, кешелек асылын билгели торган рухият җәһәтеннән дә. Әлбәттә, мондый җирлектәге яшәеш кысаларында замандашлар төрлечә халәт кичергәннәр. Әле бит тәкъдирнең үзенчәлекләре дә була. Әйтик, Тукайны кыска гомере буена эзәрлекләгән «печать проклятия»ләр, үзебезчә гадиләштереп әйткәндә, «кара сакал»ларның язмышка әрнет-

кеч «төзәтмә»ләр кертеп торуы. Тоташ драматизмнан гына торган егерменче гасыр исәбендә мәхәббәт сакчысы тарафыннан үгисетелгән затлар бихисап исәпләнәдер. Кемнәргәдер тиңләштерергә теләмим, әмма тугыз яшеннән (!) бөтенләй ятим калган Әхмәт Рәшитне дә күпмедер дәрәҗәдә «ят яратылган» иҗатчылар җөмләсенә кертмичә булмый.

Шагыйрь биографиясендәге ошбу хәл-халәткә басым ясап үтүем йомшак күңелле укучыларымны хискә бирелдерергә теләүдән түгел. Хикмәт шунда, гомер юлының шулай аянычлы башлануы булачак иҗатчыда тирән эз калдыра. Нәкъ менә шушы фаҗигаи гаҗизлек аның яшәү рәвешенә үҗәтлек белән катгый искәрмәләр кертә, шәхеснең холык-фигыленә дә үз хасиятләрен өсти, хәтта язу алымын барлыкка китерүдә дә драматик асылын әледән-әле сиздереп торырлык йогынтысын ясый. Ун яшьлек малайның шигырьләр яза башлавы да газиз әти-әнисен югалту тетрәнүләренә турыдан-туры бәйле. Хәер, истәлек рәвешендә язылган бер мәкаләсендә ул әлеге бәйләнешне үзе дә искәртә. «...Гаҗәп матур иде дөнья ул көнне, — дип искә ала шагыйрь. — Язны мактап шигырь язмасаң, гөнаһ булыр төсле иде. Сугыштан соңгы авыр елларда алдагы көнгә фәкать өмет белән караган, күгәрчен гөрләсә дә, күзләренә мөлдерәмә яшь тулырга торган, йөрәгенә әрнүле моңнар оялаган миндәй ятим бала өчен бигрәк тә шулай».

Шигърият сәнгатьнең иң мәһабәт төре булып саналса да, шигырь кешеләргә ләззәт бирер өчен генә язылмый. Бигрәк тә татарда. Юк, шигъриятта «тормыш елмаюы» гына чагыла алмый, чөнки яшәешебез сөенечле мизгелләрдән генә тормаган. Халыкның уй-гамен аһәңле сүз белән аңлатып

биргән бердәнбер сәнгать төре буларак, шигърият инде күптән татарның туктаусыз сызланучы җан авазын яңгырату чарасына әверелгән. Кулына каләмне бик яшьли алган Әхмәт Рәшит тә безнең шигъриятгәге үтәли мотивны баштук дөрес тойган.

Без халыкка хак сүз әйтү өчен,
Өзелгәнбез аның бәгыреннән.

*(«Антидөньялардан атыла тора...»)*

Малайлыктан чыгар-чыкмас борын
Чырайларга кунды кырыслык...

*(«Идеаллар искә төшкәндә»)*

Чыннан да, йөрәгенә кече яшьтә үк салынган җөй аны күзгә күренеп өлкәнәергә мәҗбүр итә. Балачакта язмыш сынавын кичергәннәр өчен, гадәттә, тормыш чынлыгы чагыштырмача кырысрак булучан. Шуңа күрәдер Әхмәт Рәшит ирексездән газиз халкына ныграк елыша һәм үзен яшьли халык улы итеп тоя башлый. Иҗатының башлангыч чорында язылган «Минем шәҗәрәм», «Автопортретка штрихлар», «Варислар» кебек поэмаларында аеруча анык сиздергәнчә, шагыйрь үзенең яшәве белән әти-әнисен генә түгел, ә туган кавеме элгәрләрен дә дәвам итә. «Ә аталар узган данлы юллар Бүгенгегә килеп тоташкан, — дип искәртә ул «Минем шәҗәрәм» исемле поэмасында. — Алар каны хәзер безгә күчкән, Җир нур җыйган кебек кояштан...» Гомумән алганда, аның авыр югалтулардан башланган язмышы халык язмышының бер өлеше буларак күзаллана.

Гасырларны иңләп атлап киләм,
Үлми,
        сүнми,
                армый,
                        ялыкмый.

Бабамнарны барлыйм.
Мин — бер улы
Татар дигән батыр халыкның.

*(«Гасырларны иңләп...»)*

Сизеләдер, Әхмәт Рәшит иҗатында аллы-гөлле күбәләкләргә мөкиббән китү кебек гамьсез сентиментальлек бөтенләй диярлек очрамый. Аның инануынча, фидаилар башын Себер җибәргән татар шигыре татлы десерт вазифасын үтәүдән ерак тора. Шигърияткә педантлык килешми. Бу җәһәттән моңлы җилкенчәк кулына ияләшкән пегас төпкә җигелеп тартучы ат хезмәтен дә үти. Башкача әйткәндә, Әхмәт Рәшит әсәрләре нигезендә яткан халык гаме риторик алым нәтиҗәсе рәвешендә түгел, ә җан-рух биографиясе җирлегендә яңгыраш алган йөрәк авазы буларак кабул ителә. Моң сирпеп торган менә шушы якты гамь аңа әдәби иҗатта да, иҗтимагый эшчәнлектә дә талант көчен бер олуг максатка тупларга ярдәм итә. Ә шагыйрьнең тулы ачылган таланты күпкырлы булуы белән аерылып тора. Әдәбият галиме Хатыйп Миңнегулов билгеләп үткәнчә, «Әхмәт Рәшит иҗаты идея-тематик һәм жанр ягыннан шактый төрле. Ул иҗтимагый-социаль, мәхәббәт, фәлсәфи мәсьәләләр хакында уйлана, үзенең уй-хисләрен лирик шигырь, поэма, мәдхия, мәсәл, җыр, робагый жанрларында шәкелләштерә, балалар өчен дә самими, үтемле шигырьләр иҗат итә».

Табигате белән тыныч кешеләр язучы вазифасын күтәрә алмыйдыр. Каләм әһеле тыштан сабыр күренсә дә, ул, асылда, «эчке янулы» булырга тиеш. Аны намус тынгысызлыгы һәрдаим уяу тота. Битарафлык иҗатчы холкына салынмаган. Дөрес, сабырлык белән тәвәккәллек арасындагы чикне күпләр атлап чыгарга җөрьәт

итми. Илдә хөкем сөргән кануннар да баш калкытырга теләүчене тыеп тота. Ә менә Әхмәт Рәшит әле 8 нче сыйныфта укыганда ук, бу куркыныч чикне бозар өчен, үзендә азмы-күпме батырлык таба. Әлеге вакыйга болайрак була. Элекке Олы Тархан районы үзәгендәге мәктәпкә күчкәч, әти-әнисез калган малайга фатирда торырга туры килә. Фәкыйрьлек үксез җанны кыен хәлдә калдыра. Киеме сәләмә. Кеше почмагында ачлы-туклы яшәүдән аның тәкате тәмам корый. Өмет чаткысын да күрсәтмәгән шундый кара көннәрнең берсендә ул, төбәктәге ятим балаларга ярдәм итүен сорап, Иосиф Сталинның үзенә мөрәҗәгать итәргә карар кыла. «Письмо на татарском языке...» Гап-гади дәфтәр битенең өске өлешенә әүвәл шундый сүзләр язып куела. Гәрчә хатны кемнеңдер ярдәме белән урысча яза алыр булса да, ул үзенең үтенечен «халыклар атасы»на саф ана телендә бәян итә. Мөгаен, әлеге балаларча үҗәтлек гамәле шагыйрьнең милләтпәрвәрлек сыйфатларын көчәйтүгә китергән беренче җитди адымы булгандыр. Мөрәҗәгать эзсез югалмый: юлбашчыдан ТАССР Югары Советы аша килеп төшкән җавап хаты яшь буынга кайгыртучанлык күрсәтергә бурычлы эреле-ваклы түрәләрне аякка бастыра...

Каләм әһеленең «общественный кеше» булырга тиешлеген әлегә тирәнтен аңлап бетермәсә дә, ул үзеннән-үзе тормышта рөхсәт ителгәннең чикләрен киңәйтү омтылышы белән яши башлый. Өметсезлеккә бирелми, чөнки ышана: «Мөмкин» белән «түгел» арасында Күзгә күренмәстәй күперләр бар...» Казан дәүләт университетының өченче курсында укыган чакта, Әхмәт Рәшитнең мәктәп елларындагы тәвәккәллеге янә кабатлана. СССР җитәкчесенә хат юллауның җаен

белгән студент инде Никита Хрущевка мөрәҗәгать оештырырга ният кыла. Максаты — Татарстан радиосының татарча тапшырулар вакытын арттыру. Биш йөзләп имза белән җибәрелгән хатка Мәскәү Кремле хуҗасыннан уңай җавап килә.

Билгеле, каршылыксыз тормыш булмаган кебек, каршылыкларга кермичә, әдәби әсәрләр дә тудыра алмыйсың. Яшәешнең әлеге хасияте шагыйрьләргә аеруча кагыла. Чорның һәртөрле киеренкелеген йөрәге аша үткәргән иҗатчы ничек инде шәхси кичерешләрендә генә казынып ятсын?! Иҗтимагый күренешләрнең күзенә туры карый белергә өйрәнгән һәм үзе дә драматик «массовка»ларда катнашкан шагыйрь буларак, Әхмәт Рәшитнең язганнарында заманның кискен каршылыклары, кешенең җан-рух сызланулары шактый тулы чагыла. Бу табигый, чөнки авторның һәрбер әсәре нигезендә уйлап чыгарылмаган кырыс чынбарлык ята, һәм әлеге дә баягы эмоциональ мәгълүмат аның халәте рухиясендә һәрвакыт мөлдерәп тора. Иҗатташым үзе үк искәртеп үткәнчә, «Җан тетрәткеч ачы хакыйкатьләр Кереп поскан безнең күзләргә...» Өстәвенә яшьли кителгән күңел үзенә күпне сеңдерүчән. Шул ук вакытта шагыйрьнең башы өстендә әти-әнисе генә түгел, ерак гасырларда яшәп киткән аксакаллар да тукып тора кебек.

Әсезгә әле яшисе —
Җир сөреп, ашлык чәчеп
Һәм үзсүзле дөнья белән
Көн саен бәхәсләшеп.

*(«Васыять»)*

Татар булып яшәүләре
Бу дөньяда, ай-һай, авыр!..

*(«Зар»)*

Һәм Әхмәт Рәшит яшь варисларын барлап торучы элгәрләргә гомеренең аерым бер биеклегеннән үзенчә җавап та бирә:

Урадым тузанлы юлларны —
Еракта калдылар эзләрем;
Дөньяның бүгенге хәленнән
Олы бер хакыйкать эзләдем.

*(«Урадым»)*

Безнең әле килер заманнарда
Әллә нинди эшләр кыласы бар;
Үз иманын, үз йоласын тотып,
Татарның чын татар буласы бар.

*(«Без — бар!»)*

Әлбәттә, хакыйкать биеклегенә күтәрелү җиңел генә бирелми. Мондый максатка йөз төбәп барган чакта, гадәттә, урау юллар аша үтәргә туры килә. Читкә тайпылулар да булгалап тора. Һәм алданулар да... Бу уңайдан әдәбият белеме классикларының «Барыннан да элек идея!» дигән уртак кагыйдәне алга сөрүләре искә төшә. Анысы шулайдыр, әмма каныңа сеңдерелгән идея аерым төзәтмәләргә мохтаҗ булса?! Ерактагы балачакта Сталин белән хат алышкан Әхмәт Рәшиткә тора-бара нинди генә идеологияләр мәктәбен үтәргә туры килмәгән. Диссидент каләм әһелләре берсен берсе кабатлап әйткәнчә, язучы өчен хакимият тарафыннан эзәрлекләнү түгел, ә кешелексез идеологиянең әгъвалавы күпкә куркынычрак. Совет чорындагы тоталитар сәяси системаның котылгысыз көчле басымы Хәсән Туфан кебек классик дәрәҗәдәге әдипләрнең дә башын бутады. Аңларга тырышып карагыз: уналты ел дәвамында сөрген михнәтләрен кичергән тәҗрибәле шагыйрь илнең халкын эзәрлекләүче юлбашчыларга мәдхия

укуын барыбер туктатмады (?!). Төгәлрәк әйткәндә, татар шигъриятенең алтын хәзинәсенә керәчәк кабатланмас иҗат мирасында аның күпмедер дәрәҗәдә «кызыллык» йөгертелгән әсәрләре, ягъни үзенең җинаятьчел асылын әледән-әле күрсәткәләп торган режимга карата лояль мөнәсәбәтен белдергән шигырьләре дә байтак. Яудан соң батырлар күбәя дигәндәй, хәзер мондый четерекле мәсьәлә уңаеннан акыл сату әхлакый яктан бик үк урынлы да түгелдер. Әле туксанынчы елларга кадәр күп кенә шигъри китаплар Ленин бабабызга багышланган әсәрләр белән ачылып китә иде. Монысы инде әлеге дә баягы вөҗүдкә үтеп кергән коммунистик тәрбиядән, намуслы шәхеснең иман рәвешендә сеңдерелгән сәяси тәгълиматка үзенчә бирелгәнлегеннән киләдер. Боларның бөтенесе дә инануга бәйләнгән. Андыйларны гаепләүдән Аллам сакласын!..

Совет идеологиясе сынавын һәркем үзенчә кичте. Һәм шагыйрь Әхмәт Рәшит тә. Әйе, ил күләмендәге бу шаукым аңа да кагылып үтте. Гәрчә үзе балачакта иҗтимагый көнкүреш шартларына карата тискәре мөнәсәбәтен белдергән «гыйсъянчылык» гамәлен кылса да, шагыйрь булып өлгергәч, ул шушы җәмгыятьнең баш-баштак хакимнәренә өлешчә дан җырлауга корылган «Иптәш коммунист» исемле поэмасын язды. Үзе әлеге фиркадә торган булса, аның хәлен аңларга да мөмкин. Юк, бу ялкынлы тарафдарның патриотик бурычын үтәве булмады, сәяси вазгыять йогынтысына ихтыярсыз бирелүнең бер нәтиҗәсе иде. Дөресен генә әйткәндә, мәҗбүри вазифалар өстенлек алган Совет хакимияте чорында кысу алымнары иҗатчыларга карата да киң кулланылды. Әйтик,

Язучылар берлегендә эшләп килгән шигърият секциясенең 1961 елда үткәрелгән бер утырышында шагыйрь Әхмәт Рәшитне «иҗтимагый әһәмияткә ия булган темаларны күтәрмәүдә» гаепләп чыгалар. Бу очракта нинди темаларга өстенлек бирелергә тиешлеге беркетмәдәге фикер сөрешеннән һәркемгә яхшы аңлашылса кирәк. Мәҗбүрилек төсмерендәге тәкъдим үзенең эшен башкара: Нурсолтан, Гәүһәршат, Сөембикә кебек «иҗтимагый» кызларыбыз табу тузанында күмелеп ятканда, ерактагы Америка коммунисты Анджела Дэвислар татар шигырендә үрнәк итеп куела... Шунысы бик тә сөендерә, Әхмәт Рәшит «Шигырьләремнән танырсыз...» исемле мәкаләсендә «ур-ра-патриотлык» ягына авышып алуын үзе дә таныды; «гөнаһлы» саналган әсәрләрен сайланма җыентыкларына кертмәде һәм замана чиренә бирешүне шигырендә дә гаепләде:

> Күндәмлеккә шундый күнегелгән —
> «Ур-ра!» дидек хәтта ялгышка;
> Үз-үзенә үлем карарын да
> Каршылады кемдер алкышлап.
>
> *(«Заманалар...»)*

Форсат чыкканда әйтеп үтим, үз иҗатына тәнкыйди карый алган затларны шәхсән үзем ихлас хөрмәт итәм. Хәйләкәрлек катыш зирәклеге белән беренче очрашуымда ук үзенә җәлеп иткән олпат шагыйребез Сибгат ага Хәкимнең, сөйләшеп утырган чакта, башлангыч иҗат чорының берничә елын бөтенләй сызып атарга теләге барлыгын күрсенеп әйткәне әле дә хәтеремдә. Өлкәнәя барганда кителмәстән классик югарылыкта яза башлаган Нури Арслановның да элеккерәк шигырьләренә беркадәр оялыб-

рак каравы шагыйрьнең дусларына яхшы мәгълүмдер. Нибары сигез елда биниһая зур иҗат мирасы калдыруга ирешкән бөек Тукаебызга да, «Кызмагыз бик, чыкса мәйданга басылган чүпләрем» дип, киләчәк буыннардан үзенә карата бераз мәрхәмәтлерәк булуларын сорарга иксез-чиксез горурлыгы комачау итмәгән. Үзеңә үзең ревизор булу, һичшиксез, һәркем өчен зирәклек билгесе. Кызганыч, бездә хәзер «конвейерга салып» язылган бихисап әсәрләренең һәркайсын да яхшыга санаучылар артык күбәйде, андыйларны исә үзләре исәнсау чагында иҗатларын җиз иләк аша үткәрү мәсьәләсе бөтенләй борчымый.

Иҗтимагый тормыштагы юнәлешләр дә һәрдаим үзгәреп торучан. Кешеләр арасында аумакайлык көчәйде. Сәясәттә «пычраклык микъдары»ның артуы да дәүләти зирәклекнең тоныклануына китерде. Ике төрле хакыйкать хокукый яшәеш алды. Хәтта руханилар да сәясәткә ныклап кергән заманда, әлбәттә, халык язмышыннан аерылгысыз шагыйрь читтә кала алмый. Әмма мондый һәртөрле ыгы-зыгыдан ул күпмедер өстенрәк булырга бурычлы. Һәрхәлдә, шушы максатка омтылырга тиештер.

Үзенең иҗатында кискен сыйфат үзгәреше ясарга ният кылган Әхмәт Рәшит сиксәненче еллар башында тарихи әсәрләр язуга ныграк игътибар итә башлый. Күңеленә яшьли кереп урнашкан милләт гаме аны бай тематик катламнарга китереп чыгара. Зур максатка муафыйк адым эчке сиземләү нәтиҗәсе дә, чөнки туган халкына чынлап хезмәт итәргә алынган шагыйрь күпмедер дәрәҗәдә тарихчы чалымнарына да ия булырга тиеш. Югыйсә мәдәни хәтергә нигезләнмәгән әсәрләр эшләнеш ягын-

нан көпшәк килеп чыгучан. Өстәвенә совет чоры мәктәбендә үтелгән тарих курсы татар балалары өчен үтә кыска булып чыкты, хәтта иң фаҗигале 1552 елыбыз да күпчелек укучыларның күңелендә тирән уелып кала алмады. Бу җәһәттән шагыйрь Әхмәт Рәшит хөр фикерләүгә юл ачкан яңа хәбәрдарлык шартларында нәкъ менә шушы һәлакәтле еллар тирәнлегенә беренчеләрдән булып төште һәм Сөембикә ханбикәбез образы аша татар халкы кичергән гаять авыр сынау чорының социаль-драматик асылын мөмкин кадәр тулы чагылдырган поэма иҗат итүгә иреште.

Дөнья әдәбияты мирасыннан күренгәнчә, элекке заманнарда тарихи поэмалар ничектер риваять кылу рәвешендәрәк язылган. Мифлар шигъриятенең булуы да безгә яхшы мәгълүм. Әлбәттә, мондый тенденцияләр татар әдәбиятында да тамыр җибәрерлек җирлек тапкан. Ә халык иҗатында чагыштырмача күбрәк тә. Безнең заманның нәкъ менә сиксәненче еллары башында, искәртеп үткәнемчә, шигъриятта тарихилыкка ирешү өчен яңа мөмкинлекләр ачылды. Чын тарихи вакыйгаларга нигезләнгән шигъри әсәрләргә татар халкында ихтыяҗ аеруча зур иде. Аңлашыла ки, кырыс чынбарлыкта тәрбияләнгән Әхмәт Рәшит әлеге мөмкинлектән бик вакытлы файдаланды. Югарыда телгә алынган «Сөембикә» поэмасын кабул итәргә киң җәмәгатьчелек, аеруча гаммәви мәгълүмат чаралары хәтта әзерләнеп тә җитмәгән булып чыкты. Тыю мөһере сугылган тарихи чынбарлык сәхифәләренең кинәт ачылып китүе күпләрне инде күнегелгән иске гадәт буенча өркетеп җибәрде бугай: шагыйрь үзенең каләмен кыю рәвештә иркен җибәреп язылган тарихи әсәрен

башта аерым өзекләр хәлендә генә шигырь сөючеләр игътибарына тәкъдим итә алды.

Тарихка авышкан Әхмәт Рәшит теманы үзләштерүдә эзлеклелек күрсәтте. «Сөембикә» поэмасыннан соң «Колшәриф» язылды. Аннары «Мөхәммәдьяр»... Тарихи затларыбызга багышланган әлеге әсәрләр әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнде. Чыннан да, шигъри трилогияне хәтерләткән бу поэмалар бер-берсен тулыландырып кына калмыйча, халкыбызның күптән көтелгән тарихи сурәтенә җете шәрехләр дә өстәде. Шагыйрьнең соңрак дөнья күргән «Казан» поэмасы исә үзенчәлекле хатимә, шушы мөкатдәс теманы беркадәр гомумиләштергән эпилог буларак кабул ителә. Гүяки халкыбызның мәдәни-тарихи хәтере белән ашланган иҗатчы хәтере гасырлар өстеннән очып бара, бер-берсеннән аз-маз үзгәрәк язмышлы буыннарны вакытның бәлзәмле җебе белән үзара бәйләргә омтыла, бүгенге ирекне кысуга китергән кичәге иҗтимагый тәртипсезлекләрнең киләчәккә сабак булырлык сәбәпләрен эзли. Гомумән, Әхмәт Рәшитнең дәрсе гыйбрәт алырлык тарихи әсәрләре безгә үткәннән киләчәккә барырга үзенчә ярдәм итә.

Мантыйкчылар искәрткәнчә, акылның берьяклы эшчәнлеге иҗатта бертөрлелеккә китерә. Бу уңайдан Әхмәт Рәшиткә хафага төшәрлек сәбәп юк — ул шигъриятнең һәммә юнәлешендә дә үзен бердәй иркен тоя. Күргәнебезчә, зур иҗат потенциалына ия булуны таләп иткән поэма жанрында да шагыйрь кыйсса-дастаннары белән данлыклы әдәбиятыбыз хәзинәсенә саллы өлешен кертә. Хәзер инде аның әлеге шигъри төргә караган унбишләп әсәре бар. Алар эчтәлекләре ягыннан да, шәкелләре җәһәтеннән дә төрле. Шулар

арасыннан «Йолдыз вакыты белән» исемле поэмада, минем карашымча, авторның эзләнүчәнлек хосусияте аеруча калку чагылыш тапкан.

Мин камиллек эзлим тереклеккә,
Камил акыл эзлим заманнарга;
Мин яхшыны телим дәвамларга,
Мин яманны телим тәмамларга...

Бу юлы шагыйрь гасырлар өстеннән генә очып калмый, җанын һәрдаим ымсындырып торган очсыз-кырыйсыз галәм киңлекләренә чыга. Табигый ки, киңрәк орбитага чыга барган саен, шигъри гомумиләштерүләр дә зурая бара. Бу гөнаһлы җирдә үзе ачкан хакыйкатькә ул шул рәвешле еракка китеп карарга җөрьәт итә. Хәер, нindидер илаһият белән өртелгән шигырь үзе дә безгә шушы тарафлардан иңәдер кебек тоела. Нәкъ менә шундый биеклектән автор үзен дә эченә алган инсаниятнең асыл йөзен, дөнья халыклары язмышында газиз кавеменең насыйп кылынган вазифаи урынын ачыграк күрергә тели. Ә илаһи биеклектән барысы да уч төбендәге кебек күренә икән бит. Кешелек кырмыска оясын хәтерләтә. (Хәер, Коръәнгә кертелгән әлеге сөйкемле җан ияләрен гайре камиллектә һич тә гаепләргә теләмим.) Зурдан кубып кылынган кайбер гамәлләр шулкадәр дә беркатлы булып тоела, кайчак көләсе дә килеп китә. Аерым мәхлукларның үзләре турында ныграк кайгыртулары аркасында, халык кадәр халык әледән-әле фаҗигагә дучар ителә. Мондый чакта йөрәк өзгәләнә.

Кояш сукмагыннан шагыйрь бара. Аның үзенчә инануы бар: «Бу дөньяны үлчәп булмый өч яссылык белән...» Хәтта ел фасылларының да бишенчесе булырга тиеш. Исбат ителмичә

нигез итеп алынган кадими постулатлар нилектән әле икейөзле янусларның фикерләвен аклап килә? Сорау арты сорау туа. Атомнар әллә ничә кисәкчеккә бүлгәләнеп беткән заманда шагыйрь кайбер шиклерәк аксиомаларны да ватарга омтыла. Шул ук вакытта әсәр герое үзенең «анти-мин»е белән каршылыкка керә. Гадиләштереп әйткәндә, берсе югарыга омтылган саен, тегесе аның чабуыннан тарта. (Хәтта күкнең үзендә дә татарлык кабатлана икән.)

Анти-минем иске фәлсәфәсен
Адым саен төшереп тора искә;
Юк, барыбер туктап кала алмыйм —
Мин камиллек эзлим яшәешкә...

Бер уйлаганда, үткәннәрне инде кайтара алмыйсың, киләчәкнең ничек булачагы билгесез. Димәк, алар — юк (?!). Менә шуларны бүгенгедә ничек үзара бәйләргә? Әлбәттә, әлмисактан килгән тамырлар үткәннәрне киләчәккә тоташтыра. Без маргиналлар түгел. Әгәр дә бүгенге дөнья йөзендә җиде миллионлап татар яши икән, милләт шәҗәрәсен тәшкил иткән кардәшләрне исәпләргә саннар җитмәс иде. Теләсә нинди халыкны шундый тамырлар яшәтә. «Үткәнемнән барам иртәгемә — Барам шулай мәңгелеккә табан» дип белдергән шагыйрь, һичшиксез, Аллаһ тарафыннан яралтылган газиз кавеменең озын гомерле булуына тирәнтен ышана. Алай гына түгел, язмыш юлын йолдыз вакыты белән үлчәп, аңа ерак киләчәктән лаеклы урын барлый.

Күренә ки, Әхмәт Рәшитнең фикерләргә сәләтле кешене иксез-чиксез уйлануларга чакырган әлеге поэмасында, аеруча «Пәйгамбәрләр канлы байрак тотып...» кебек юлларында, Һади Такташ иҗатының беренче «гыйсъянчылык

чоры» аһәңнәре дә яңгырап куя. Ә инде әсәрдәге «Мин — Кеше!» рефрены Литва шагыйре Эдуардас Межелайтисны искә төшерә. Юк, әлеге охшашлык чалымнары кемнедер кабатлау юлына күчүдән түгел, зур гомумиләштерүләрдә башка олуглар белән фикердәш булудан килә. Ышанып әйтергә мөмкин, Әхмәт Рәшитнең «Йолдыз вакыты белән» исемле лирик-фәлсәфи поэмасы татар шигъриятенең югарылыгын күрсәтүче әсәрләр рәтенә керергә хаклы. Кызганыч, менә шундый үзенчәлекле иҗат уңышына үз вакытында төпле бәя бирүче табылмады. Нишләмәк кирәк, куанычлы хәбәр ирештерүче кәрваннар да безләрдә элек-электән соңарып килгән.

Инде җиргә төшеп, шуны искәртәсе килә, Әхмәт Рәшитнең күпкырлы иҗаты белән тулаем танышкан чакта, аның рухиятен ачып бирүче хасиятләр җитерәк булып күренә: замана мәдәнияте белән баетылган фәһемлелек, дөньяга караш киңлеге, чынбарлыкны аңлау тирәнлеге, фикерләү ачыклыгы, онытыла башлаган төп идеалларга күзләрне зуррак итеп ачтыру... Гадәттә, теге яки бу әсәрдә әлеге сыйфатларның чикләнгәнлеге сизелсә, сүзнең очы үзеннән-үзе каләм әһеленең тәрҗемәи хәленә барып тоташа. Иҗатка шушы яктан караганда, Әхмәт Рәшитнең күпчелек әсәрләре нәкъ менә тормыш белеменә, шәхси тәҗрибәгә таянган булулары белән аерылып тора. Балачакта ук гамьле ир-егет кыяфәтенә кергән шагыйрь, яклаучысыз калуы аркасында, чынбарлыкның сынауга тиң сабакларын артыгы белән алган. Гомер юлының һәрбер борылышы аңа үзенчә тәҗрибә өстәгәндер: Казан дәүләт университетында белем алуын вакытлыча өзәргә мәҗбүр булып, ерак Төркестан тимер юлында тауар поездла-

рын озатучы вазифасын башкару да, югары уку йортын тәмам иткәннән соң төрле җаваплы урыннарда эшләү дә, элекке СССР буйлап иҗат сәфәрләренә йөрү дә, шулай ук Һиндстан, Япония, Төркия, Кипр, Греция, Сингапур, Малайзия кебек илләргә чыгып гыйбрәт алулар да... Менә шуңа күрә аңарда тормыш матурлыгын яисә ямьсезлеген уйлап чыгару ихтыяҗы юк. Тоныклык аңда йокымсыраган мәгънәсез хикмәтләр шагыйрьнең табигате өчен бөтенләй яттыр.

Рухи маяга ия булган шагыйрь, билгеле, иҗатта үзен чагыштырмача ирекле тота. Чынбарлык күренешләрен бөтен киңлегендә колачлый алган Әхмәт Рәшит әсәрләрендә дә аерым тормыш деталенең шигъри образга иркен күчешен тоемларга мөмкиндер. Аның сәнгати күзаллавы, гадәттә, мантыйк кысаларыннан чыкмый. Һәм шигъри сурәтләү алымнары ягыннан ул аңлы төстә реалист булып кала. Язу өслүбе тотнаклы — сабырлык сизелеп тора. Шул рәвешле ачык итеп фикерләргә омтылу шагыйрьне үзеннән-үзе сурәтләү ачыклыгына алып килә. Гомумән, татар классик шигыренең гасырлардан күчкән реальлеге Әхмәт Рәшитнең күңеленә шактый иртә кергән. Шагыйрьнең тотрыклы тезмә шәкелгә өстенлек бирүе дә аның әлеге традицион мәктәпкә тугрылыгын күрсәтә. Алда китерелгән шигъри өзекләр дә моның шулай булуын раслый. Барысы да табигый. Пыяла өргәндәге кебек: эчтән чыккан тының нинди уй-гамьнәр белән корылган булса, үзең күрергә теләгән бәллүр дә шундый рәвешне ала. Сере бик гади. Шул ук классиклар искәрткәнчә, чынбарлык формасы якыннан түгел, үзенең асылы белән матур.

Галиҗәнап каләм шуңа төшендерә: камил дәрәҗәдәге язу рәвешенә ирешү барыбер тел-

не өйрәнүгә кайтып кала. Сүз белән эш итә белү, әйе, иҗатта мөһим роль уйный. Менә бу яктан Әхмәт Рәшит үзен бәхетле итеп саный ала — тел-өслүб осталыгының беренчел нигезе аңа шагыйрьлек таланты белән бергә бирелгән: җөмләләре төзек, сүзләре үз урынында, теле сыгылмалы… Тел җәһәтеннән ул тезмәдә дә, чәчмәдә дә һөнәрмәндләрчә эш итә. Язганын мөкәммәл дәрәҗәгә җиткерүдә, кемнәрдер шикелле, читләрнең ярдәменә мохтаҗ түгел. Киресенчә, телнең нечкәлекләрен яхшы белгән мөхәррир буларак, мондый хезмәтне башкаларга үзе күрсәтергә мөмкин. Сүз байлыгы зур. Дөрес, дөньяга киң итеп ачылган күзләр белән караучы шагыйрь кайвакыт алынма сүзләр куллануда үтә интернациональлек күрсәтә шикелле. Нәзбереклеге белән аерылып торган татар шигыре тукымасына ул нинди генә кәлимә яисә сүзтезмә кертеп җибәрми! Менә аларның кайберләре: ноосфера, апокалипсис, инфузория, $E = mc^2$, гипоталамус, квадратура, дилемма, генетик код, хеви металл, homo sapiens… Дөрес, боларның уй-хис агышына күпмедер ятыш булганнарын авырлык белән «йотып» та җибәрергә мөмкин, вәләкин сүзләр сайлаудагы мондый чамасызлык шагыйрь иҗатының миллилек нисбәтен саклауга хезмәт итмидер. Тезмә әсәрләрдә искәрмә рәвешендә бирелгән астөшермәләрнең артык күбәеп китүе дә шигъри дулкынга корылган күңелне ничектер җайсызлык халәтенә өстерәп кертә. Тарихка мөрәҗәгать иткәндә, әлбәттә, аларның булуы зарурдыр. Әмма лирик кимәлдә язылган әсәрләрдәге сәнгати чынлык күпчелек очракта үзе турында үзе сөйләргә тиеш. Телебез мөмкинлекләре чиксез. Бары тик иҗтиһат итәргә генә кирәк. Хәер, иң кирәкле

алыштыргысыз сүзне сайлап алуның кыенлыгын, иҗатның җаваплылыгын шагыйребез үзе дә искәртеп үтә:

Туксан тугыз мәгънәсез сүзгә каршы
Бердәнбер мәгънәле сүз табып кара!..

*(«Баш шәрифләренә акыл кирәк тә...»)*

Шигырьләр олау-олау да,
Илаһи сүз сирәк.
Дөньяга юл күрсәтердәй
Пәйгамбәрләр кирәк.

*(«Шигърият»)*

Әдәби әсәрләрне ачы балан кабып укучы кайбер нәзберек затлар өчен Әхмәт Рәшитнең реаль җирлектәге шигъри дөньясы ап-ачык булып тоелырга мөмкин. Алар да хаклы. Зәвыгы булган кеше шуны сизмичә калмас: бу шагыйрьнең язганнарында җиңел генә аңлатып бирә алмаслык ниндидер эстетик мөлаемлык бар. Әлеге мөлаемлык нигезендә, минемчә, күңелнең ихласлыгы ятадыр. Чыннан да, ихласлык сәнгать әһеленең иң кирәкле сыйфатларыннан берсе булып санала, гомумән, һәртөрле иҗатны үтәли сафландырып торучы бәрәкәтле чыганак рәвешендә күзаллана. Табигый ки, әгәр авторның күңеле мондый башлангычтан мәхрүм икән, аның әсәрендә әлеге нигъмәт чагылыш таба алмый. Димәк, язучы булу таланты гына җитми, кеше булу таланты да кирәк. Безнең Әхмәт Рәшитебез дә: «Бу юлы мин тудым Кеше булып, Бу тууым — шигырь язар өчен», — дип тикмәгә генә әйтмәгән. Шагыйрь өчен аеруча мөһим зирәклеккә дә ихласлык аша гына ирешеп буладыр. Шундый югарылыкка күтәрелгән акыл ияләре әлеге зарурият турында кат-кат искәрткән.

Хәтта сокланырга мөмкин, ихласлык Әхмәт Рәшит күңеленә мөлдерәп торырлык итеп салынган. Юмартлык белән мулдан бирелгән самимилек, күрәсең, үксез җанда уңдырышлы җирлек тапкан. Кайчак аның тормыштагы аерым гамәлләренә карап, «И, сабый күңелле шагыйрь!» дип тә әйтәсе килә. Риячылар белән тулы безнең чуардан-чуар дөньяда, әйе, артык эчкерсез затларга җиңел дә түгелдер. Әмма ана сөте аша иңгән шушы бәһаләп бетергесез сыйфат каләм иясенә укучы белән ихлас әңгәмә корырга ярдәм итә. Бу яктан шагыйрь Әхмәт Рәшитнең күпчелек әсәрләре, минем карашымча, үзара ышанычка корылган булулары белән аерылып тора. Җырларын гына алыйк. (Ә мондый нәзакәтле жанрга садәлек аеруча мөһим шарт.) Менә аларның кайберләре: «Беренче мәхәббәт», «Зәңгәр күлмәк», «Язгы гөлем», «Тәрәзәләр язга елмая»... Күпләребез раслар, бу җырлар белән инде берничә буын үсте. Аларны белмәгән татар юктыр. Шагыйрь өчен бу бәхет түгелмени?! Әлеге җырларның инде дистәләрчә еллар дәвамында онытылмыйча яшәве, барыннан да элек, авторның ихласлык белән баетылган лириклык талантына килеп тоташадыр. Юк, җырда алдап булмый. Кеше җанының тирәнлекләрен яктыртып күрсәтү өчен үз җаныңның эчтән балкып торуы зарур. Әмма дөнья бу, каләм ияләренең дә төрлеләре бар: күңелендә сумала кайнатып, үзләрен фәрештәгә санаучылар да, тормышта монафикъларча уйнап, ихлас булып кыланучылар да... Тик әдәптән аерылгысыз әдәбият ясалмалыкны кабул итә алмый: холыктагы мондый сыйфатларның һәммәсе дә ак кәгазьгә барыбер саркып чыга.

Каләмдәшем Әхмәт Рәшитнең иҗатын ту-

лаем күздән кичерү мине аның үзе хакында гына түгел, гомумән, бүгенге шигърият һәм заман турында бер-берсенә тыгыз бәйләнгән менә шундый табигый уйлануларга этәрде. Моның өчен җирлек бар, чөнки шагыйрьнең авыр сынаулардан торган гомер юлында чорның каршылыклы агышы шактый тулы чагылыш тапкан. Ничек кенә булмасын, үзенә тиешле «чирәм җир»не ул сабыр рәвештә сөрә бирә. Исеме тирәсендә ниндидер шау-шу куптарып эшләүне бөтенләй яратмый, шуңадыр без аңа кайчак игътибар да итмибез бугай. Хәер, бериш мәгълүм исемнәрне эченә алган «обойма»ларга сыймаучы Әхмәт Рәшит үзе дә әдәбият мәйданында Роберт Әхмәтҗан, Рәшит Әхмәтҗан сыман беркадәр аерымрак тора кебек. Дан-дәрәҗә белән бозылмаган. Тәүге шигъри юллары белән танылу алып килгән әсәрләре арасында байтак еллар ятса да, ул үзенә күктән бирелгән әлеге дә баягы эстетик мөлаемлыкка һәрвакыт тугры булып кала. Сүз дә юк, аның шагыйрьлек холкы күпмедер үзгәрмичә калмагандыр, әмма иҗатының саф-чиста үзәге метаморфозалар кичермәгән. Һәм әлеге асыл сыйфатлар авторның бер-берсен тулыландыручы барлык әсәрләрен тоташ картинага берләштергән чакта, ягъни төрле елларда язганнарын күңелдән тулаем үткәргән мәлдә, бөтен төсләре белән ачылып китә. Үзеннән-үзе шундый нәтиҗәгә киленә: туган халкына тугры хезмәт итүче Әхмәт Рәшитнең иҗаты, чыннан да, татар шигъриятенең кирәкле бер буыны булып күзаллана икән.

*Зиннур Мансуров*

# I

*Сафлансын дип күңелләрем,*
*Арынсын дип яманнардан,*
*Урап кайтам кайчакларда*
*Пәйгамбәрле заманнардан.*



* * *

Җир Кояш тирәли әйләнгән арада
Уела божралар зиреккә, тирәккә...
Уела божралар бәгырьгә, йөрәккә,
Җир Кояш тирәли әйләнгән арада.

Яз килә дөньяга — уяна бөреләр;
Ут ялмап, су ялап торса да — тереләр.
Туа көн — яшәүнең шатлыгы, газабы,
Бер кыска гомернең башы һәм азагы.

Җир Кояш тирәли әйләнгән арада,
Әйтерсең бер мизгел елның дүрт фасылы.
Нидә соң, нидә соң яшәүнең асылы
Җир Кояш тирәли әйләнгән арада?..

Кемдер бар, кемдер юк дөньяда иртәгә —
Кул мөмкин селтәргә, нигә, дип, кылган эш;
Тәгәри Җир буйлап мәңгелек йомгагы
Һәм килә яңадан Яз атлы юаныч.

Җир Кояш тирәли әйләнгән арада,
Хыялда өр-яңа өметләр уяна —
Киләчәк исемле тылсымлы ут яна,
Җир Кояш тирәли әйләнгән арада...

## *Кәбисә ел*

Белмимен нинди фал юрарга —
Нилектән бу йолдыз яңгыры?
Ник әле бер өнсез бушлыктан
Гел шомлы хәбәрләр яңгырый?!
Йолдызлар атыла искәртеп:

Бу таңда кем булыр, кем булмас,
Иртәгә кем булыр, кем булмас —
Барыбер булганнан ким булмас.
Чыгара Мәңгелек Мизгелгә
Иң соңгы рәхимсез карарын:
Югала дөньядан дөньялар,
Үзгәрә яшәеш ярлары.
Ә быел ни булган Галәмгә?
Ник ешрак атыла йолдызлар?
Яшисе яшәлеп бетмәгән
Җаннарга ник үлем кул суза?
Ник үчле Мәңгелек Җирдәге
Тынгысыз бу Адәм затына?
Яналар, сүнәләр гомерләр,
Ә күктә йолдызлар атыла.

## *Бер уйлап карасаң...*

*(Экзюпериның «Бәләкәй принц»ын укыгач)*

Син, сөеклем, ачуланма миңа —
Мин тормышта шүрәле күк надан;
Башка планетадан, дисең мине —
Әйе, әйе, мин ят планетадан.

Мин еректан килдем, җилдәй җилеп,
Ал таңнарын Җирнең күрер өчен,
Тузганак та түгел, амеба да...
Адәм булып Җирдә йөрер өчен.

Мин мәңгелек илләреннән килдем —
Чикләнмәгән иде анда гомер,
Мин кош булып түгел, кеше булып
Бераз яшәп карау өчен килдем.

Мин ерактан килдем, галәм гизеп,
Көч вә куәт җыеп бар йолдыздан;
Инде Центаврның альфасыннан
Киткәнгә дә миллион гомер узган.

Мин оныттым инде чын исемем —
Без сөйләшә идек бүтән телдә;
Тик нигә соң Бөек Төзүче Зат
Олактырды мине шушы илгә?

Сез башкача икән, сез башкача,
Сезнең дөньягызны аңлау кыен;
Ә нишләп соң якын итте күңел
Ят дөньяның сәер гамәл-уен?

Һәм ... нишләптер Кордильерлар тавы...
Амазонка мине чакырмады...
Һәм... чит күрде, кабул италмады
Гоби чүле... дала... такырлары...

Ак каенлы, сайрар сандугачлы
Шушы төшкә килеп төшкәнмен мин,
Әмма яшәешнең аңлаешсыз
Туксан тугыз серен чишкәнмен мин.

Язмышыма шулай язылганмы —
Эләккәнмен нигә нәкъ бу илгә?
Мин бәхетсез түгел — шулай икән,
«Нигә?» дигән сорау биру нигә?

Балаларым, әйе, Җир уллары —
Адәм белән Хава нәселеннән;
Ә шулай да күңел кәгъбәсендә
Тагын әллә ниләр яшеренгән.

Һәр таң саен сорау бирә миңа
Әкиятле һәм кампитрлы заман.
Мин күптәнге җисми тормышымнан
Һаман әле, һаман аерылмаган.

## *И Ходаем, рәхмәтлебез Сиңа*

Аллаһ әкбәр, дибез — Аллаһ бөек —
Ул бар һәм бер фәкать җиһанга;
Ул рәхимле, гадел, саф, шәфкатьле —
Һичбер нинди тиң зат юк Аңа.

Чөнки беркем Аны тудырмады,
Чөнки беркем Аннан тумады,
Ул гап-гади кеше заты сыман
Эзләп тапмады вә җуймады.

Фәрештәләр Аның әмерләрен
Армый-талмый йөри гел ташып,
Һәм Ул сеңгән безнең кальбебезгә,
Күкләр мөнбәреннән нур ашып.

Ул бар иткән барча Җирне, Күкне,
Утның, Суның барын бар иткән;
Ул җәннәттә Адәм атабызга
Хава анабызны яр иткән.

Ул кодрәтле — һәм шул кодрәт белән
Шыта орлык, үсә үләннәр,
Һәм шул кодрәт белән ургып чыга
Салкын чишмә тирән-тирәннән.

Һәм шул кодрәт белән Күк йөзендә
Яшен яшьнәр, күкрәү яңгырар,
Һәм шул кодрәт белән исәр җилләр,
Төшәр карлар, явар яңгырлар.

Ул кодрәтле, әмма һәрчак гадел:
Кат-кат сынап адәм баласын,
Белеп тора булган нигъмәтләрдән
Кемнең ничек, күпме аласын.

Ул теләсә генә пәйда була
Җир йөзендә барча бәрәкәт,
Ул теләсә генә гәүдәбезгә
Тылсым булып иңә хәрәкәт.

Пәйгамбәрләр Җиргә җибәргән Ул,
Гыйбрәт итеп сиңа һәм миңа,
Һәм иңдергән изге китапларын
Камил булсын өчен бу дөнья.

Ислам дине безгә насыйп булган —
Рәсүлебез безнең Мөхәммәд.
Ирештергән өчен Аллаһ сүзен
Без укыйбыз аңа мең рәхмәт.

Бер гөнаһсыз яшәп булмыйдыр ла,
Без бит фәкать адәм баласы;
Намаз укып, тәүбә итеп кенә
Гөнаһларны йола аласың.

Сират күперләрен кичәсе бар,
Ахирәт бар — шуңа җыеныйк;
Гомерләрнең һәрбер мизгелендә,
И Ходаем, Сиңа сыеныйк.

* * *

Әлмисактан алып шушы көнгә кадәр
Әллә нинди хикмәт эшләр кылган кеше;
Ә тарихта төп вакыйга — сугыш һаман,
Баш каһарман — җимерүче, үтерүче...

Иң беренче җан кыйган җан кандашына
Таш атканмы, әллә күсәк күтәргәнме?!
Хәтерләми анысын Вакыт Галиҗәнап,
Хәтерли тик илләр баштан үткәргәнне.

Җидееллык, Утызъеллык, Йөзьеллык, дип
Саный барган гыйбрәт өчен киләчәккә.
Булган тәре походлары,
Сугышканнар
Ак чәчәкләр белән хәтта Ал чәчәкләр.

Кешелекнең чәрдәкләнгән хәтерендә —
Карфагеннар, Орадурлар, Сонгмилар...
Тарих түрен яулап алган Ганнибаллар,
Чыңгызханнар әле һаман җан кыйныйлар.

Инде галәм гөмбәзенә менмәкчеләр,
Кешеләргә атмакчылар утлы уклар...
Кайчангача төзелгәнне җимерерләр,
Тарихыбыз кайчангача үлем чутлар?!

Бер гөнаһсыз нарасыйлар җанын алып,
Нигә заман безне болай кат-кат сыный?!
Күтәрергә иде тарих мөнбәренә
Кендек әби белән гади бакчачыны.

## *Рәсүлебез Мөхәммәд*

*(Мөнәҗәт)*

Хак Тәгалә бәндәләргә
Иңсен диеп иман нуры,
Җибәргән күп пәйгамбәрләр,
Булсын дип юллар туры.
Кыек атлап киткән ләкин
Бик тәкәббер кайбер кавем;
Пәйгамбәрләр җәберләнгән,
Аллаһ сүзен әйткән саен.
Бик күп гарәб ыруглары
Таш сыннарга табынганнар;
Бозыклардан бозык булып,
Тирә-юньгә танылганнар.
Югыйсә ул заманнарда
Заман инде барган алга —
Яһүдиләр, нәсарыйлар
Табынганнар тик Аллага.
Бозсалар да кайчакларда
Канунын Хак Тәгаләнең,
Хакыйкать дип таныганнар
Изге вәхиләрен аның.
Хак Тәгалә җир йөзендә
Гыйбрәтләрнең күреп барын,
Илче иткән Мөхәммәдне —
Иң сөекле пәйгамбәрен.
Рәсүлебез бу дөньяда
Иң дөрес юл эзләп йөргән;
Гарәфәт тавында аңа
Иң изге аятьләр иңгән.
Рәсүлебез кыен күргән
Мәккәдәге кяферләрдән:
Бар җаһилләр, ташлар атып,
Мөэминнәрне җәберләгән.

Ислам динен танучылар
Мәдинәгә киткән күчеп;
Мөэмин-мөселман өммәте
Шунда гына киткән үрчеп.
Тик кяферләр — дошман көчләр
Һөҗүм итеп торган һаман;
Ләкин инде моннан соңра
Исламныкы булган заман.
Булган Бәдәр сугышлары,
Аннан тагын яулар килгән;
Тик Мөхәммәд галәйһиссәлам
Дошманнарны җиңә белгән.
Чөнки Ислам байрагын ул
Иманына юлдаш иткән,
Аңа Аллаһ биргән куәт
Бар җиңүләр өчен җиткән.
Мәдинә вә Иерусалим
Аралары бик-бик ерак,
Мөхәммәдне әһ дигәнче,
Илткән анда җитез Бурак.
Яктылык баскычы буйлап,
Рәсүл җиде күккә ашкан;
Аллаһы Тәгалә аңа
Тиңдәшсез дидарын ачкан.
Җиденче кат күккә дә ул
Күз ачып йомганчы менгән;
Үзе менгәнгә кальбенә
Аять арты аять иңгән.
Фәрештәләр аңлатканнар
Нәрсә — ямьсез, нәрсә — ямьле,
Күрсәткәннәр Мөхәммәдкә
Җәннәтне вә җәһәннәмне.
Ходайдан бу җир йөзенә
Илче булып инде менә
Күкләрнең зур хакыйкатен
Төшендерә өммәтенә.

Төшендерә ничә гасыр
Күктән иңгән Коръән аша —
Ул сүрәләр яшәешнең
Барча хикмәтләрен ача.
Шуңа күрә пәйгамбәргә
Рәхмәт укып, әйтик зикер;
Аны безгә Илче иткән
Хак Тәгаләгә мең шөкер!

## *Бәйрәм мөбарәк булсын!*

Кайлардан бу курай моңы килгән җиргә,
Әверелеп мәңгелектән иңгән җырга? —
Юлдаш булып сылу кызга, кыю иргә,
Күңелләрне гел-гел әсир итәр имди.

Мирас булып гасырлардан гасырларга,
Килгән ул моң урманнарга вә кырларга;
Батырларның батырлыгын һәм зурларга
Бу дөньяда ихлас курай кирәк имди.

Кура гына, курай гына ул булса да,
Эчләренә кайгы-сагыш мул тулса да,
Татар халкы, башкорт халкы ни кылса да,
Үзе белән шул курайны йөртер имди.

Җыелдык без изге бәйрәм — рамазанга,
Дөньяларга иман иңгән бер заманда;
Исән әле, имин әле без һаман да,
Туар көн дә шулай имин булсын имди.

Картларны да, яшьләрне дә тәбриклибез,
Хак Тәгалә бар вә бер, дип йөрик, дибез,
Саф күңелдән аны якын күрик, дибез,
Күк авазы безгә шуны сөйләр имди.

Безнең язмыш — тирән язмыш, гыйбрәт тулы,
Борылмалы-сыгылмалы аның юлы.
Тугрылыкка юл күрсәткән Ходай кулы,
Гомер бакый без ышаныйк аңа имди.

Хуш килдегез бу түгәрәк якты залга,
Ышаныч һәм өмет белән карыйк алга,
Иман белән киләчәккә юл ярганда,
Изге бәйрәм, дуслар, котлы булсын имди.

## *Философлар хакында фәлсәфә*

Тагын кем бар бездән акыллырак —
Бөек затлар биләп күңелне,
Ничә еллар буе ятлап йөрдек
Фейербахны, Кантны, Гегельне.

Иптәш Маркс белән иптәш Ленин
Ачты, дидек, фәннең хак-чынын —
Материаль, җисми дөньяларның
Диалектик үсеш канунын.

Ул гынамы әле, ул гынамы —
Ераккарак китсәк бүгеннән,
Шыр наданнар сыман берни белми,
Агностиклар булып йөрелгән.

Гомер сөреп мичкә эчләрендә,
Буташтырып тәмам бу башны,
Элладаның мәшһүр диванасы
Безгә акыл биреп маташты...

Ә шулай да күршем Каюм абзый
Акыллырак бугай алардан, —
Фәлсәфәне махсус өйрәнми дә,
Әллә ниләр белеп алалган.

Аның өчен фәнни институт —
Телевизор атлы әкәмәт;
Бар дөньяның хәлен әйтеп тора —
Заманага әйтик мең рәхмәт.

Ул сәгатьләр буе сөйләп тора
Пневмония, СПИД хакында...
Каюм абзый, иртән көтү кугач,
Бер кычкырып ала хатынга:
— Бәрәңгедә Колорадо корты —
Сталинмы килеп чүпләсен!

...Һәм тетмәсен тетә генсекларның,
(Чөнки белә Себер китмәсен).

Коммунизм капка каккан чакта,
Чигенергә булгач кирегә,
Капиталны сүккән философлар
Безгә, ди ул, бүген ни бирә?!

Тагын кем бар бездән акыллырак,
Дип йөрдек тә, киереп бугазны,
Оныттыкмы әллә шул мәңгелек
Тормыш дигән бөек остазны?!

## *Фәлсәфи парадокслар*

Йөрәк белән йөрәк арасында,
Теләк белән теләк арасында,
Күңел белән күңел арасында,
«Мөмкин» белән «Түгел» арасында
Күзгә күренмәстәй күперләр бар.

Кемдер әйтер, тәңгәл килми, дияр,
Дөньядагы капма-каршылыклар,
«Мөмкин» диеп раслаганда Мөмкин,
«Түгел» диеп Түгел каршы чыгар —
Берсен берсе алар сугып егар.

Һәм Яктылык белән Караңгылык,
Ут белән Су инкяр итәр безне,
Туу белән янәшәдә генә
Үлем дигәне дә көтә безне —
Гел көрәштә гомер үтә безнең.

Фанилыкка дәвам Ахирәт бар,
Бүген иркен булса, иртәгә — тар,
Бүген яңгыр яуса, иртәгә — кар,
Абсолютның тиеп теңкәсенә,
Ташламыйлар ләкин дилеммалар.

Чөнки алар, игезәкләр сыман,
Җитәкләшеп йөри бер уй уйлап.
Гомер бакый озын сәфәрләргә
Озаталар безне дөнья буйлап,
Йә шатлык, йә хәсрәт көен көйләп.

Чиратлаша бара Көн белән Төн,
Яна бар җир — дөнья тоташ төтен —
Кемгә рәхәт анда, кемгә читен;
Каршылыклар бердәмлеге — Хәят,
Бүлеп булмый аны, ул — бербөтен.

Шифа була теләк белән беләк
Ике йөрәкнең дә ярасына,
Һәм салават күперләре сузып,
Күңел белән күңел арасына,
Бәхет килә адәм баласына.

Тукталырмы Өмет, упкын күреп,
(Карамаска кирәк фәкать аска!)
Иң мөһиме — Ышанычтан башка,
Мөмкин белән Түгел ярындагы
Күперләрне кирәк яндырмаска.

## *Бәхетсезләрне кызганып...*

Бу дөньяда иң бәхетсез җаннар —
Тоткын, әсир һәм кол җаннардыр;
Эчләрендә күпме адәмнәрнең
Дөрли-дөрли утлар янадыр.

Күкне иңләп оча азат кошлар,
Черки булып черки — иректә.
Ә адәмнәр ник соң газап чигә,
Ходай яшәр гомер биреп тә?!

Чәнечкеле тимерчыбыкларга
Җил кагылып моңнар тарата;
Өзеләдер лә, һай, үзәкләре,
Ерак йолдызларга карап та.

И бу дөнья, ник ул тәмуг кебек
Тоткыннарга, әсир-колларга?!
Елмаерга туган мескеннәргә
Туры килә үксеп еларга.

Иртән торсам, ихлас күңелемнән
Дога кылам сөенеп көн саен:
— Яраткансың мине азат итеп,
Мең-мең рәхмәт Сиңа, Ходаем!

## *Сәхәр вакыты*

Тиң булмас аңа дөньяның
Алтыны вә якуты.
Уяныгыз, мөселманнар,
Җитте сәхәр вакыты.

Бисмилла белән каршылыйк
Туасы таңнарны без —
Ходай Тәгалә алдында
Саф булсын җаннарыбыз.
Коръән сүрәләре булып,
Рамазан шәрифләрдә
Пәйгамбәргә вәхи иңгән
Мәгънәсен шәрехләргә.

Бар серен бер Ходай белә —
Илаһи сүз — изге ул,
Савапларны, гөнаһларны
Күрсәтүче көзге ул.

Сөйли ул безгә яшәүнең
Асылын вә җирлеген,
Сөйли ул безгә Аллаһның
Барлыгын вә берлеген.

Шуңа уразалар тотып
Олылыйбыз Аллаһны,
Чөнки ул көчле, кодрәтле,
Бар итүче дөньяны.

Ихластан булса намазлар,
Шифасы тияр җанга;
Ходай җәннәт насыйп итсен
Бар мөэмин-мөселманга.

## *И дөнья...*

Нух пәйгамбәр йоклаганда,
Шәрә тәнен күреп аның,
Хам шаркылдап көлгән, диләр,
Гаурәтеннән атасының.

Пәйгамбәрләр чорыннан соң
Күп су аккан, күп җил искән,
Әмма дөнья үзгәрмәгән,
Хамнар әле һаман исән.

Имансыз шул Хамнарга тиң
Җирдә бүген ничә бала;
Көлү түгел, атасының
Бугазына пычак сала.

Дөнья камил булсын өчен,
Җаннарын да аямаган
Пәйгамбәргә тиң адәмнәр
Кайда алар, кайда алар?!

Изге китаплар җитәрлек,
Гыйбрәт алыр хәлләр байтак;
Ләкин кемнәрдер тәм таба
Хакыйкатьне бутап, айкап.

Сүнә кояш, ай-йолдызлар
Караңгыга чума һаман.
Күңелдә шом — әллә чынлап
Җитте мәллә ахырзаман?!

## *Җаннан каннар тамганда...*

*Милли каһарман Гали Акышка*

Илләрдән аерылганда да,
Телләрдән аерылмаган,
Диннәрдән язган чагында,
Канаты каерылмаган,
Усал җилләр искәндә дә,
Иманын югалтмаган,
Гаяз Исхакый шикелле
Ак юлыннан чыкмаган
Бөек каһарманыбызны
Алкышлый бүген милләт,
Татарның олуг теләген
Алга илтергә теләп.
Империя заманында
Кемне сүктек, ни яздык?!
Без әйтәсе хакыйкатьне
Сөйләде тик «Азатлык».
Татарның изге кальбеннән
Тамганда кайнар каннар,
Сөйләде Гали Акыш һәм
Фидакяр бүтән җаннар.
Без бүген аңа рәхмәтле —
Күңелдә — якты балкыш.
Азатлык даулап татарга,
Яшәсен Гали Акыш!

## *Халык васыяте бит ул*

*Бөтентатар иҗтимагый үзәгенең беренче Президенты Марат Мөлеков ядкаре*

Без иман яңарттык көрәштә,
Җаннарны ялганнан тазарттык;
Иң татлы сүз шытты бәгырьдә:
— Азатлык! Азатлык! Азатлык!

Васыять-хыялын татарның
Чынлыкка ашырыр чакларда,
Кыюлар бик сирәк чакларда,
Беренче ул басты сафларга.

Парламент мөнбәре түреннән
Кем, дисәң, татарны яклаган,
Ул Марат Мөлеков иде бит
Иманын байлыкка сатмаган.

Бәгъренә ядрәләр аттылар,
Яралап керсез саф йөрәген;
Аудармак иделәр манкортлар
Халыкның бу затлы терәген.

Ә ул ник бирешсен, кальбендә
Себерләр куәте булганда,
Үз иде ул безгә мәйданда,
Ялкынлы сүз дөрләп торганда.

Кемнеңдер әле җир йөзендә
Көне юк, теле юк, иле юк;
Көрәшкә чакырып чаң суккан
Каһарман ул — Марат Мөлеков.

Без иман яңарттык мәйданда,
Тарихны гайбәттән тазарттык;
Иң садә уй иде күңелдә:
— Азатлык! Азатлык! Азатлык!

## *Ялгызлык*

Эчендә нәрсә янганын үзең бел,
Үзең кайгыр, үзең егъла, үзең көл.

*Г.Тукай*

Бу дөньяда гел ялгыз мин —
Чүлдә адашкан сыман;
Эчемдә бер өн... туктаусыз
Кабатлый: «Сынам... сынам...»

Сынарга минем хакым юк,
Ничекләр сынамасын,
Якын дип йөргән кешеләр
Ничекләр кыйнамасын.

Ышанып ихлас дуслыкка,
Бушатсам күңелдәген,
Башыма төшә таш булып,
Китереп моңлы чагын.

Югыйсә минме язмышка
Баш игән, җайга торган.
Озатты юлга олуг уй,
Ышанып ныклыгыма.

Җандагы хәтәр авазга —
Әүвәлге хәлгә кайтып —
Пышылдап кына эндәшәм,
Сынма, дип, сынатма, дип.

Пышылдыйм... ишетмәсеннәр
Җанымның йомшак чагын,
Сынаулар булыр — сер бирмә,
Биектә канат кагын.

***

Кар-буранлы тар хәятта
Үтә көнем-төнем;
Җиргә төшкәнче боз була
Күз яшьләрем минем.

И сабый күңелле шагыйрь,
Шуңа китә исең!
Елаудан соң, йә, ни мәгънә —
Кем юатыр, дисең?

Дөнья салкын. Тирә-юньдә —
Боз бәгырьле җаннар;
Шигырь булып ак кәгазьгә
Тик ал каннар тамар.

## Сонет

Дөньяның бар хикмәтләрен, гади генә —
Ике икең — дүрт, диеп тә санап була,
Ә зиһенең эшкә җиксәң, билгесезлек
Үрләренә менәр өчен канат була.

Уйлар да бер, буйлар да бер булса әгәр,
Әй күңелсез булыр иде безнең тормыш;
Бер-береңне үртәп, көлеп яшәр өчен,
Гомер җәдвәлләрен Ходай төрле кормыш.

Мин дә хаклы, син дә хаклы, ул да хаклы —
Нишләтик соң төрле-төрле бу дөньяны;
Җиргә туган икән, үзгә адәмнәрнең
Җаны-тәне, каны-саны вә вөҗданы.

Һәммәсен тик үзгәртергә кодрәтле Күк —
Безнең исә катышырлык мәлебез юк.

## *Күңел төшкәндә*

Язмышымны каргамыйча нәрсә әйтим —
Ятим кеше картайса да һаман ятим;
Сискәндерә аны хәтта моңлы җыр да —
Күз яшьләрем, тамам-тамам, диеп тора.
Миһербансыз бу җиһанга туганмын шул,
Туганмын да аңа ят зат булганмын шул,
Тантанада әнә каты бәгырьлеләр —
Алар тәти, алар илдә кадерлеләр.
Алар уңган, алар чибәр, алар зирәк,
Минем кебек елак ятим кемгә кирәк,
Бу дөньяның хадимнәре хаклылардыр,
Шуңа күрә көчлеләрне яклыйлардыр.
Дөнья шул бу!
Шулаен ул шулайдыр да,
Көчлеләргә куштан булу кулайдыр да;
Ләкин Ходай миңа да бит биргән йөрәк —
Кайчагында мине дә бит аңлау кирәк.

## *Мин үткәнгә кире кайтмас идем*

Яшьлегемә кайтыр идем, диеп
Җырласалар, әйдә җырласыннар;
Мин үткәнгә кире кайтмас идем —
Анда үзәк өзгеч мизгелләр бар,
Бәп-бәләкәч көе иңнәремә
Нинди генә кайгы сарылмаган?!
Кичте баштан, кичте төрле хәлләр —
Әле ничек йөрәк ярылмаган.
Һаман елап яшиммени инде,
Яралансынмыни кабат йөрәк?!
Язмыш тузанында казынганчы,
Алгы көнгә карау хәерлерәк.

* * *

Кайсы байга барып башым иим —
Кем аңлар да мине, ни дияр?!
Өстәлемдә, дөнья күрмимен, дип
Тилмерешеп ята шигырьләр.

Кемдер әнә спонсорлар табып
Һәм җайлашып кысыр елларга,
Өч тиенгә тормас такмагын да
Затлы китап итеп чыгара.

Мин әйтәсе олуг хакыйкатьләр,
Мин сөйлисе халкым үткәне
Мие тәмам түнгән адәмнәргә
Инде кирәк түгел микәнни?!

Мәнфәгате фани дөньяларның
Биегәндә кыргый тамтамга,
Кара, күпме асыл шагыйрьләрнең
Йөрәгеннән саркып кан тама.

Әрәм бит, дип, күңел җимешләрем,
Ялгыз янып шигырь утыннан,
Күктән сөрелгән карт пәйгамбәрдәй,
Авыр уйлар уйлап утырам.

## *Сукбай эт*

Акбаймы син, маэмай, Актырнакмы —
Оныткансыңдыр шул исемеңне дә;
Нинди гаеп табып, җылы өйдән
Чыгардылар куып картлык көндә?

Усал идеңме син, йә юашмы?
Хуҗаңа бит тугры булгансыңдыр;
Дерелдисең, күзгә мәэюс карап —
Боз өстендә ятып туңгансыңдыр.

Сезнең халык юкса горур җанлы,
Ә син коерык болгап һәркемгә дә,
Сынык-санак өмет итәсеңдер —
Төштеңмени инде мескен хәлгә?!

Без, кешеләр, бик еш мәрхәмәтсез —
Аш урынына кайчак таш атабыз;
Һәм игелек дигән изге хисне
Күңелләрдән сирәк кузгатабыз.

Дөнья кырыс. Җан асраулар авыр.
Мә, ичмасам, ал бу икмәгемне!..
Ничекләр соң тагын ярдәм итим?
Мин кызгана гына алам сине.

* * *

Керфегемә кунган күз яшем
Менә-менә тамар шикелле,
Күңелемнең бөтен сагышы
Дәрья булып агар шикелле.

Нигә хыялландым мин болай
Дөньяның тик ямен күрергә?!
Насыйп булган икән ич аның
Бары тик күз яшен күрергә...

## *Авыру язмалар*

Сорамагыз, хәлең ничек, диеп,
Кышлый алдым инде кышларын...
Гомерлеккә дигән исемлектән
Сызып ятам кайбер дусларны.

Ятагымнан ерак китми генә,
Урап йөри сары сагышлар;
Уйлар өермәсен сискәндереп,
Ник яңгырамый таныш тавышлар?!

Дөнья куа дөнья.
Бу дөньяга
Мәңгелеккә килгән шикелле,
Онытыла икән якын дуслар,
Ят язмыштан көлгән шикелле.

Бәла килә.
Килсә... китәр әле...
Ялгызым да, бәлки, җиңәрмен...
Бәйләр өчен йөрәк яраларын
Ертып була күлмәк җиңнәрен.

Йөргән чакта мәхбүс Туфаныбыз
Себер җилләрендә каңгырап,
Кем күзенә карап ышык тапкан,
Ялгыз калгач көзге яңгырда.

Даһилыкка дәгъва кылучылар
Белә микән иман бизмәнен,
Иң-иң авыр чакта җан дуслары
Хәтта Тукайдан да бизгәнне.

Өзгәләнеп шушы мизгелләрдә
Үткәннәрне искә төшерәм.
Кемнәр белән ниләр бүлешкәнне
Бәйнә-бәйнә уйдан кичерәм.

Дөнья кырыс.
Ләкин аңа карап
Бәгырьләр дә каты булсынмы?!
Читләп үтми бәла беркемне дә —
Кем булсаң да истә тот шуны.

Бөтен дөнья авырлыгы иңдә —
Тик бөгелмәм, гомер бөгелмәм;
Шуңа кайбер ялган иптәшләргә
Кул бирмәмен, ахры, бүгеннән.

* * *

Дошманнарым юк, дидем — алданганмын,
И хыялый, бар икән ул, бар дошман.
Мин бүген, бар дөньядан яшеренеп,
Яраларын ялап яткан эт сыман.

## *Ашыгыч ярдәм*

Менә шундый заман җитәр...

*Мөнәҗәттән*

Көннәр генә түгел, төннәрнең дә
Коты оча шомлы ул хәбәрдән —
Урамнар һәм йортлар аваз сала:
— Ашыгыч ярдәм кирәк, ашыгыч ярдәм!

Миенә кан сауган кемнәрнеңдер,
Кемнәргәдер автомобиль бәргән,
Кемнәрдәдер дөрес типми йөрәк:
— Ашыгыч ярдәм кирәк, ашыгыч ярдәм!

Калганым бар иде ат астында,
И акыллы хайван! Ул чагында
Сикереп кенә үтте минем өстән —
Тидермәде хәтта тоягын да.

Хәзер тимер заман. Тимер инде
Араламый безне андый хәлдән;
Бәреп екты мине — аямады:
— Ашыгыч ярдәм кирәк, ашыгыч ярдәм!

Ул гынамы?!
Килер шундый заман —
Җир йөзендә булмас һичбер тиңе!
Прогрессмы — алга барумы бу,
Әллә кыргый чорга чигенүме?!

Болай тормас һаман — килер заман —
Аерып булмас хәтта өстән асны,
Һәм шул чакта үзебез уйлап тапкан
Роботлар ук тотып кыйнамасмы?!

Әй, ул чакта өстен булып чыгар
Җанлы җаннар түгел, тимер җаннар;
Ә кыенын кемнәр күрер, дисез —
Җантимерләр түгел, Тимерҗаннар.

Сырхау җаннар, сырхау йорт-урамнар,
Кала, сала, мәмләкәтләр — бары да,
Җан ачысы белән аваз салыр:
— Ашыгыч ярдәм кирәк, ашыгыч ярдәм!

Таш та таяк иде элек кулда,
Камыр батырда да хәзер — тимер;
Мәрхәмәтне канун итәр заман,
Камил заман, белмим, кайчан килер.

Тимер заман бомба, пуля булып
Ява һаман, ява безнең өскә;
Күкләр каргыйлардыр, карый-карый
Гаҗиз калып мондый күренешкә.

Муенынннан гөнаһларга баткан
Дөнья гарык инде ул көннәрдән;
Көтә әле һаман, өзми өмет:
— Ашыгыч ярдәм кирәк, ашыгыч ярдәм!

## *Гыйбрәт алыйк*

Мин — милләтче.
Теге заманда да
Яшермәдем хыял-уемны.
Ләкин кемдер кебек беркайчан да
Уйнамадым «милләт» уены.

Уңышлардан башым әйләнмәде —
Мин мөкиббән китмим юк-барга,
Ләкин беләм: безгә, тынычланып,
Иртә әле, иртә йокларга.

Озын юллар әле үтәсе бар —
Офыклардан кояш күренсен;
Иртә әле, иртә бүлешергә
Ауланмаган аю тиресен.

Дәгъва итми генә һәйкәлләргә,
Эш эшлик без — мөһим шул нәрсә;
Ни мәгънә бар безнең татарлыктан,
Безгә дәвам татар үсмәсә?!

Ни мәгънә бар космополит уллар
Марҗа сөеп, урыс үстерсә,
Дөнья куган булып, без инанган
Иманнарны пыран китерсә?!

Ничә гасыр буе империя
Тоташ баштан сугып торсын да,
Мөмкинме соң, бер селтәнү белән
Бөтенесен кире борырга?!

Түбәтәең белән киңәш башта —
Хәрәкәт ит уйлап һәр сүзең;
Бүрек белән бәреп егып булмый —
Киртәләр бар алда. Бул түзем.

Сабыр төбе сары алтын, диләр,
Каршы куеп хәйлә-мәкергә,
Шуны корал итсәк көрәшләрдә,
Юл ачылыр азат фикергә.

Безнең кебек кенә көрәшкәнме
Исхакыйлар гомер буена!
Милләттәшен харап итәр өчен,
Таш йөртмәгән ләкин куенда.

Искә алыйк Зәки Вәлидинең,
Йомгак ясаганда гомергә,
Исхакыйны кочып елаганын,
Ник булмадык, диеп, гел бергә.

Ялгышлар күп.
Ә без сабак алыйк
Үткәндәге хәтәр хәлләрдән,
Тез буыны ләкин йомшамасын
Мәскәү әйткән һәрбер хәбәрдән.

Алда көрәш — каты һәм аяусыз,
Безнең сафка бассын — кем батыр!
Җиңү килер әле — сөенербез,
Татар өчен дә бер таң атыр.

* * *

Мин яшеннән, яшен ташыннан мин —
Күкрәүләргә гашыйк күңелем,
Чөнки беләм, күпне вәгъдә иткән
Бу дөньяның камил түгелен.

Мин дөньяга яшәр өчен килдем,
Пыску өчен түгел, янам дип,
Җәннәтле һәм җәһәннәмле Җиргә
Мин эндәштем, газиз анам, дип.

Кемнәргәдер гамьсез тынлык кирәк —
Яшәп калыр өчен яшәсен;
Миңа исә җилләр дулап иссен,
Күк күкрәсен, яшен яшьнәсен.

Ике кулым күккә таба сузып,
Шаулап яңгыр килгән уңайдан,
Мин җаныма, куәт җыяр өчен,
Гел яшеннәр сорыйм Ходайдан.

Менә тагын яңгыр явып үтте,
Ләкин никтер бик тын, җай гына.
Күлләвекләр генә калды җирдә,
Өстәлмәде берни җаныма.

Никтер хәзер күкләр сирәк күкри,
Никтер сирәк яшьни яшеннәр;
Запасымы әллә беткән күктә —
Ник ут чыкмый яшен ташыннан?

Яшәү белән үлем аралыгын
Кичкән чакта, кемдер чынлыкта
Яшен булып яшьнәр чакларда да
Изрәп йоклый гамьсез тынлыкта.

Яшьнә, яшен, яшьнә яшәү булып,
Синең ишең — миндәй кешең бар;
Бу битараф дөнья хәлләренә
Мәңге бетмәс изге үчем бар.

Мин дөньяны үзгәртергә телим —
Беләм, беләм җиңел түгелен.
Мин яшеннән, яшен ташыннан мин —
Күкрәүләргә сусый күңелем.

## *Шигырь бәйрәме — 2000*

Шагыйрь илне юатучы гына.

*Зөлфәт*

Мин көткән идем бу көнне,
Бик көткән идем;
Исте җилләр, кичте көннәр...
Һәм хаклык җиңде.

Сөенер иде, мөгаен,
Тукай үзе дә;
Чөнки дөнья карый һаман
Шагыйрь күзенә.

Алданган чакта өметләр
Язмыш җилендә,
Бар гавамны юатыр зат
Тик шагыйрь генә.

Илгә хаким һәм яугирләр
Ни бирә алды?
Табында гавам һәрвакыт
Өлешсез калды.

Дөньялар тулы зилзилә,
Бар илләр утта;
Ни генә булмыйдыр хәтта
Ошбу минутта?!

Кылыч күтәрсенме шагыйрь
Җаннарны кыеп?
Шигырен кылыч итә ул,
Уйларын уеп.

Һәм изге антын яңартып
Йөрәге аша,
Мазлумнарның башын сыйпап,
Яшәүгә дәшә.

Чын-чынлап аңласын өчен
Йөрәкне йөрәк,
Бу камил түгел дөньяга
Шагыйрьләр кирәк.

## II

*Кайсы кыйтгаларга күз салсаң да,*
*Моңаеп һәм яшереп ярасын,*
*Күпме чит-ят кавем арасыннан*
*Карап торыр татар баласы.*



## *Мөһаҗирләр*

Кирәк чакта гел-гел соңга калдык,
Кирәкмәгән чакта ашыктык;
Тәкъдирләргә ниләр язылса да,
Без тормышка мәңге гашыйктыр.

Гүзәллеген, камиллеген эзләп,
Камиллеге качкан дөньяның
Кайсы кыйтгасына сугылмадык,
Урый-урый аның бар ягын.

Иңгә сарган Гоби тузаннары,
Саванналар кергән йөрәккә,
«Сибелә чәчәк» җырын көйли-көйли
Сибелгәнбез ерак-еракка.

Мөһаҗирлек мәллә канга сеңгән,
Ризык мәллә шулай йөретә?!
Ата-баба каберләрен сагынып
Уфтанабыз ләкин кич-иртә.

Ят итсә дә кайчак туган туфрак,
Ят итмәдек татар уйларын —
Амазонка ярларына барып
Бәйрәм иттек сабан туйларын.

Кайсы кыйтгаларга күз салсаң да,
Моңаеп һәм яшереп ярасын,
Күпме чит-ят кавем төркеменнән
Карап торыр татар баласы.

Кая барсаң да бер кояш түгел,
Чәчәк үсмәсә дә юлында,
Солтан булмаса да, олтан булмас —
Татар өчен канун шул гына.

Кояшлардан ары кояшлар бар,
Туган илдән ерак илләр бар,
Язмышларны сукбай дүңгәләктәй
Тәгәрәтеп йөрткән җилләр бар.

## *Без — бар*

*Алтын Урданың 750 еллыгына*

Кануны бар илнең, йоласы бар,
Күпме гамәл җирдә кыласы бар,
Тарихларга гыйбрәт калсын өчен,
Тимучинның Чыңгыз буласы бар.

Без киләбез ерак дәверләрдән,
Кайдан, кемнән, дисәң, нәсел очы —
Тамырларда безнең бүре каны
Һәм Ашина — аның башлангычы.

Легендалар сөйли — ничек Аны
Юк булудан бүре коткарганны,
Без мең үлеп, мең кат терелгәнбез —
Алалмаган беркем безнең җанны.

Без бүреләр сыман далаларны
Йөгереп үттек айкап чиктән чиккә;
Әллә ниләр кылдык, үзебезне
Танытырга теләп Мәңгелеккә.

Безне юаш, күндәм, буйсынучан
Итмәкчеләр иде әллә кемнәр —
Юк, бүреккә сыймый бүре башы,
Әллә кемнәр әллә нишләсеннәр.

Болгар булдык, кыпчак, хазар булдык,
Кушамат күк тактык татарлыкны,
Тик барыбер, чорлар кичә торгач,
Белде дөнья Җирдә без барлыкны.

Бүре генә түгел, арыслан күк
Ташландык без дошман өсләренә,
Алар безнең ашкын җиңүләрдән
Килә алмый һаман исләренә.

Гайбәт сатып, кыек сүзләр сөйләп,
Үч алмакчы бүген шулар өчен,
Яуда гына түгел, тынычта да
Татыр әле дөнья татар көчен.

Безнең әле килер заманнарда
Әллә нинди эшләр кыласы бар.
Үз иманын, үз йоласын тотып,
Татарның чын татар буласы бар.

# *Без — татарлар*

*(Поэма)*

*Гомере буе татар халкын ихтирам итеп яшәгән намуслы һәм гадел тарихчы Лев Николаевич Гумилевның якты истәлегенә багышлыйм*

— Әти, без татарлармы?..
— Әйе, улым, татарлар без...
— Ә нишләп без татарлар?..

Биш яшьлек улым Искәндәрне балалар бакчасына илткәндә, безнең арада шундый сөйләшү булган иде.

## I

Ни дип җавап бирим сабыема —
Чынлап та шул, нишләп без татарлар?
Нигә поляк, якут, әрмән түгел,
Нигә татарлар дип атаганнар?

Кушаматмы, сүгенү сүземе ул?
Кем алмакчы бездән каргыш-үчен?
Ул ямаулык төсле өстебездә —
Гүя безне гел-гел үртәр өчен.

Сабыем да шуңа рәнҗегәндер —
Ниндидер бер маңка малай анда,
Үзен өстен күрсәтмәкче булып:
«Әй, кәләпүш... татар...» — дигән аңа.

Улым исә, телләшмичә генә,
Ирек биреп милли ачуына,
Борын чөеп йөргән «зур расаның»
Шәпләп кенә төрткән касыгына.

Их, кыйнашып кына җиңеп булса...
Ул малайның, беләм, атасы да
Вәхшиләрчә бер җәһәтлек белән
Ябышыр иде татар якасына.

Әлмисактан бирле килә шулай
Кемнәрнеңдер пычрак васыяте;
Гел-гел шул хис төртеп, бүсеп чыга —
Бардыр, бәлки, берәр хасияте?!

Тар дисәк тә җирне, тар түгел бит —
Дөнья мәрхәмәтле, юмарт, нәфис;
Ләкин ничек, кайдан килә икән
Кемнәргәдер шундый бетмәс нәфес?

Ни күрсә дә, гел «минеке?» дияр,
«Минекенең» хәрәм өлешенә
Кушыла бит читләр җир-суы да,
Асылташ вә алтын-көмеше дә.

Җиде диңгез артларына барып
Таланган мал бәхет китерәме?
Фани дөнья өчен нигә алар
Кәсеп иткән кеше үтерүне?

Әэҗүз белән Мәэҗүз заманасы
Җитмәгән ич, нишләп шаша-шаша,
Кемсәләрдер бу җир нигъмәтләрен
Кимереп бара кызыл балчыккача?!

Мин кем — белмим. Бабаларым узган
Тузан тузган озын юллар хәтәр;
Тарихның бер сәер мизгелендә
Мине татар диеп атаганнар.

Никтер кытай, япон, йә һинд түгел...
Ватан исә — Идел аккан илдән;
Булган — булсын. Ә мин һич кимсенмим —
Горурланам татарлыгым белән.

II

Ә шулай да... нишләп татарлар без —
Шул төп сорау борчый мине һаман;
Ачык кына җавап табалмыйча
Бәхәсләшә заман белән заман.

Курганнардан чыккан сөякләрме,
Чүлмәк китегеме иң зур дәлил,
Үткәннәрнең хәтәр хәбәрләрен
Җиткерәме безгә чишмә һәм җил?!
Архивларда яткан фолиантлар,
Хәтерләрдән җуелмаслык моңнар,
Сөйләгезче миңа — ул бердәнбер
Дөрес фараз кайчан, ничек чыңлар?!

Галим әфәнделәр, минем өчен
Һәркайсыгыз Әбугалисина;
Моңа кадәр мин белмәгән серне
Яшермичә сөйләгезче миңа.

Мин беләсем килә бөтенесен —
Яхшысын да, яманын да бергә;
Нинди хәлләр булып үтте икән
Бүген без көн күргән ошбу җирдә?

Мин кош булып урап кайтам Җирне,
Эзли-эзли ул борынгы эзне;
Бик күп язмышларга шаһит юллар
Онытмагандыр бит әле безне?

Мин мөлдерәп карыйм — чагыла күк
Бабамнарның йөзе һәр чалымда;
Әлмисакның бар мизгеле шулай
Җанланадыр кебек хыялымда.

«Да-да» булып, «та-та»[1] булып та без
Йөртелдек микәнни күпме гомер?
Чин[2] чигендә сөңге чыңлаткан сөн[3]
Бәлки, миңа баба тиешледер?!

Хыялымда кинәт давыл булып
Килеп керә мәллә кадим дөнья —
Күз алдымнан уза вакыйгалар —
Алар нидер сөйли сыман миңа.

Көннәр, төннәр үтә — хыялымда
Атлар чаба — хөр җайдаклар чаба;
Безме соң бу? Нигә чабабыз без
Көн иленнән төн иленә таба?

Арттан безне кояш куа килә,
Узып китә аннан көлә-көлә,
Без чабабыз. Алда — билгесезлек,
Байрак кына җилфер-җилфер килә.

Кызыл байрак җилдә җилфер-җилфер,
Кан төсеме анда, таң төсеме?!
Хәвеф-хәтәрләрдән саклый-саклый
Дәртләндереп бара бар кешене.

---

[1] Да-да, та-та — Кытайның төньягында яшәгән кабиләләр.

[2] Чин — Кытай.

[3] Сөн — сөннәр яки һуннар тарихта киң билгеле халык.

Күп гасырлар кичәр — байракларда
Шул кызыл төс тагын кабатланыр —
Ул, рейхстаг түбәсеннән торып,
Зур җиңүнең данын сөйләп яныр.

Гази Заһитовның[1] дан-шөһрәтен
Әллә кемнәр урламакчы иде,
Корыч бабай фәкать урыс белән
Үз гөрҗиен[2] зурламакчы иде.

Ләкин хаклык бит ул без шикелле —
Төртеп тишә ялган капчыкларын;
Татар халкы Алтын Йолдызсыз да
Баһадирын танып алкышлады.

Мин бүгенне ялгап борынгыга,
Тарихлардан эзләп дәлил көчен,
Яшәешнең бөек хикмәтләрен
Ачыкламак булам үзем өчен.

Җилдән җилеп үтә җитез вакыт —
Дала иңләп хөр җайдаклар чаба;
Безме соң бу? Нигә чабабыз без
Көн иленнән төн иленә таба?!

III

Сау бул, Зур Су — синдә дөнья чиге,
Дулкыннарың ялый ялгыз ярны,
Икенче яр бездән ерактадыр —
Эзләп табасы бар, шиксез, аны.

---

[1] Гази Заһитов — рейхстаг түбәсенә иң беренче булып Җиңү байрагы кадаган каһарман.
[2] Гөрҗи — грузин.

Нинди көч бар безне туктатырлык —
Киртә булса, гайрәт чәчә-чәчә,
Картларга яшь көчләр алмаш булып
Җитәрбез без соңгы диңгезгәчә.

Торгын тормыш безгә иш булырмы,
Тамырларда кайнап торса каннар?!
Узасы юл озын — узар аны
Фәкать дәртле пассионар[1] җаннар.

Күк гөмбәзен ябып өстебезгә
Черем иткән чакта (Кем дә арый!).
Юл турында гына уйладык без,
Ерак йолдызларга карый-карый.

Чөнки безгә, язмышлардан узып,
Гыйбрәт өчен кирәк сүз әйтәсе,
Егерменче гасырны да узып,
Үзебезне кабат күрсәтәсе.

Мәйданнарга чыгып, «Азатлык!» дип,
Йодрыкларны чөеп һаваларга,
Яулыйсы бар ирек вә хөррият
Безгә дәвам булыр балаларга.

Баш иярме татар җиде ятка,
Кол була ул фәкать бер Аллага;
Чөнки Ашинадан васыять булып,
Тамырларда ярсу каннар ага.

Без чабабыз. Янар таулар кала,
Сәлам әйтеп без барасы җиргә;
Гейзерлардан күтәрелгән томан
Кызганмыйча фатихасын бирә.

---

[1] Пассионарлык — Л.Н.Гумилев билгеләмәсе буенча, кешеләрдә биосфера белән бәйләнешле тере матдә энергиясенең гадәттәгедән күбрәк булуы.

Төрки кавем исем биргән күлләр,
Елгалар һәм үзәнлекләр кала,
Ә офыклар һаман ымсындыра,
Безнең күзләр явын ала-ала.

Сау бул, Бай Күл[1], сау бул, Әни Суы[2] —
Без китәбез инде ерак-ерак;
Ни өчендер соңгы диңгезгәчә
Ашкындыра безне шашкын йөрәк.

Ясак түләп Җуҗань[3] ханнарына
Интеккәннәр булды заманында;
Йә үзебез өстен чыга идек,
Йә изелдек читләр табанында.

Чөй язулы — әлифбалы булдык,
Уйгур белән тату торган чакта,
Чәлпәрәмә килде зур хаканлык,
Яуларга бик артык йөргән чакта.

Сугышкан да булды, килешкән дә —
Үтте инде баштан төрле хәлләр,
Без илгизәр икәнлеккә шаһит
Далаларда калган таш балбаллар.

Күлтәгиннәр, Төнъюкоклар[4] рухын
Уятырлар беркөн, заман узгач —
Танулары авыр ташлардагы
Тамгаларны җил һәм яңгыр югач.

---

[1] Бай Күл — Байкал күздә тотыла.

[2] Әни Суы — Енисей елгасы.

[3] Җуҗань — төрки кабиләләрне кыерсытып яшәгән дала юлбасарлары (IV—V гасырлар).

[4] Күлтәгиннәр, Төнъюкоклар — төрки хаканлыкның VII—VIII гасырларда яшәгән тарихи шәхесләре.

Ә шулай да хәбәр җитәр килеп,
Килеп җитәр, гасырларны кичеп;
Сөйләр безгә ерак дәверләрдә
Бабайларның яшәгәнен ничек.

Комда яки суда эз калмый, дип
Сөйләмәгез юкны — кала эзләр;
Шул эзләрдән узар һәр яшь буын —
Ул үзенең чын тарихын эзләр.

Ә әлегә кадим заманнардан
Юлга чыккан хөр җайдаклар чаба —
Иярләрдә без бу! Без чабабыз
Көн иленнән төн иленә таба.

## IV

Артта кала чүлләр — ком барханнар,
Елга-күлләр елап кала артта;
Кулда таң билгесе — кызыл тулар[1],
Җитез атлар ак күбеккә баткан.

Ашыгалар Хазар[2] диңгезенә —
Чаба-чаба сусаганнар суга;
Без эзләгән соңгы диңгезме бу,
Омтылдыкмыни соң фәкать шуңа?

Сәламләде аннан Каф[3] таулары,
Йолалары якын икән җанга,
Болгар дигән иллә дәү мәмләкәт
Төзештек без анда Кубрат ханга[4].

[1] Т у — байрак.
[2] Х а з а р  д и ң г е з е — Каспий.
[3] К а ф  т а у л а р ы — Кавказ.
[4] К у б р а т — Азов буе Болгарстанының VII гасырда яшәгән ханы.

Тик җәнҗаллы иде тормышыбыз,
Атламадык никтер туры юлдан,
Үз туксанын туксан, дияр өчен
Тартыштылар туган белән туган.

Бүре көтүе күк бер булмады,
Байлык туплау иде бар эшләре,
Һәм дөньяның төрле кыйтгасына
Таралышты Кубрат варислары.

Ә без карап шималь йолдызына,
Башка тарафларга юл алганбыз;
Ак каенлы, чал имәнле якта
Урманнарга кереп югалганбыз.

Идел белән Урал арасында
Калкып чыккан бөек шәһре Болгар,
Иле Болгар... Илне болгатмаган —
Чөнки ил тотардай ныклы кул бар.

Ә шулай да кем без? Болгарлармы?
Кыпчаклармы? Бәхәс җитди һаман;
Хазар, дисә, ул чор яугирләре,
Сез — мөселман, дияр ибне Фадлан[1].

Бик акыллы булып кайберәүләр
Безнең каннан бүген геннар эзли,
Болак күперенә шигарь язып,
Фәкать болгар, димәкчедер безне.

Дөнья бит ул ике икең түгел,
Бергә-бергә гомер сөргәннәр дә
Кан кардәшләр безгә, кан кардәшләр
Бүген татар булып йөргәннәргә.

---

[1] Әхмәт ибне Фадлан — Болгар иленә ислам дине алып килгән Багдад илчелегенең рәсми вәкиле юльязмачысы.

Туганнардай якын күреп мине
Кунак итә якут, алтай, кыргыз...
Балкар Кайсын[1] әкә белән икәү
Чөкердәшеп чәйләп утырабыз.

Без — төркиләр, нәсел-ыру бер үк,
Тылмачсыз да аңлашабыз җиңел,
Кан юлында бер үк амплитуда,
Бер үк уйлар белән тулган күңел.

Заман белән заман — игезләр күк,
Кичә белән бүген бер үк җептә;
Булганы да, буласы да бергә
Җитәкләшеп бара мәңгелеккә.

Ничек кенә бизәп язылмасын,
Тарих әкияте арзан тора.
Син, шовинист бәндә, белмәгәнең
Әнә галим Гумилевтан сора.

Ә ул әйтер, Русь иленең бездән
Һич бернинди «иго» күрмәгәнен,
Татарларның, ушкуйниклар[2] кебек,
Башкаларны талап йөрмәгәнен.

Худяковтан сора, Баскаковтан[3] —
Алар белә кемнең кем икәнен;
Көн иленнән төн иленә килеп,
Татарларның ничек көн иткәнен.

---

[1] Кайсын Кулиев — атаклы балкар шагыйре.
[2] Ушкуйниклар — Идел, Чулман, Ука елгалары буйлап җирле халыкны талап йөргән урыс юлбасарлары.
[3] Худяков, Баскаков — тарихчылар.

«Кыргый халык» диеп һаман әле
Сата тарих безнең яманатны,
Югыйсә бит күпме татар иде
Башкаларның иң-иң асыл заты.

Шагыйрь булып, яугир булып та ул
Дан өстәгән аңа — хәерсезгә;
Тик барыбер моңа карап кына
Кара караш үзгәрмәгән безгә.

...Космик заман. Татар егетенең
Очар көнен көттек, озак көттек;
Ул Марска очар Марс[1] иде —
Юк кына бер нәрсә харап итте.

Бөтен яктан килгән иде дә бит —
Космик киңлекләргә очалмады;
Җандай күрә иде дус-ишләре,
Түрәләргә никтер ошамады.

Янәсе, ул марҗа хатынына
Авыр сүзләр әйткән кызып китеп;
Янәсе, без шундый милләтчене
Ничек инде тотыйк үрнәк итеп.

Әлмисактан бирле килә шулай
Кемнәрнеңдер пычрак васыяте —
Әллә кайдан ул бүселеп чыга,
Кирәк булса берәр хасияте.

Хәзер менә искә төште әле:
Күптән түгел генә, шуның ише
Еларлык та, көләрлек тә түгел —
Тормышның бер гади күренеше.

---

[1] Марс Рафиков — космонавтларның беренче группасындагы татар кешесе.

Шаляпинга һәйкәл ачкан чакта,
Янәшәмдә ике урыс иде,
Берсе ишарәләп Президентка:
«Татарларның Чыңгызханы», — диде.

Ярар ла, дип, сүзе булмасын, дип,
Кем соң хәзер кемдер көен көйләр?!
Әйе, әйе,
Болгары да, Алтын Урдасы да,
Казан ханлыгы да... — безнекеләр.

Татарстан, якты көнгә карап,
«Азатлык» дип язды байрагына;
Үткәнен дә алды арсеналга,
Киләчәк тә... якын ара гына.

Ак каенлы, сайрар сандугачлы
Үзебезнең ил бу — җанга якын,
Чишмәләре яшәү җырын җырлый,
Йөрәкләрдә дөрли сүнмәс ялкын.

Илбашына дәлил кирәк булса,
Аңлатырга безгә ил хәлләрен,
Кашгариның «Лөгать»[1] еннән ала
Меңәр яшьлек татар мәкальләрен.

Без бар җирдә чишмә ургып чыга,
Без бар җирдә чәчәк ата гөлләр,
Без бар җирдә кошлар канат кага —
Шундый ямьле безнең торган илләр.

---

[1] Мәхмүд Кашгариның «Диване лөгатет-төрк» дигән кульязма сүзлеге күздә тотыла.

Иле гүзәл, җире-суы юмарт,
Кешеләре дә бит алтын аның,
Яңгырата шундый баһадирлар
Бар дөньяга Татарстан данын.

V

Каенлыкта бүген сабан туе,
Яше-карты алды аны көтеп,
Җыелыштык менә, калдырдык та
Кырны тургайларга сәхнә итеп.

Әйдә, алар анда бәйрәм итсен,
Безнең өчен мәйдан монда гөрли,
Белик әле, нинди үзгәрешләр
Булды икән үткән яздан бирле?

Былтыр кемнәр батыр булып калган,
Һәм кайсы ат килгән иң-иң алдан,
Хезмәттәге батырлыгы өчен
Кемнәр-кемнәр нинди бүләк алган?

Котлау ява уңган егетләргә,
Уңган киленнәргә котлау ява,
Күңелләр көр — бүген сабан туе,
Тылсымлы моң — чыңлап тора һава.

Ерак заманнардан күчкән бәйрәм —
Кыза, кыза милли Олимпия,
Олимп тавы исә күңелләрдә —
Ул үзенә каһарманнар җыя.

Антейга тиң Алыплар бар монда,
Ахиллары исә җитез җилдәй;
Сөлгеләрне бәйлә югарырак —
Сөйләп торсын, бәйрәм, диеп, илдә.

Тантаналар әнә бар тарафта:
Калаларда бәйрәм, салаларда;
Бабайларның асыл йолалары
Мирас булып күчә балаларга.

Бер сөйләгән иде Тәминдар карт[1],
Мәйдан итеп Амазонка буен
Бар дөньядан җыелып милләттәшләр
Үткәрүен татар сабан туен.

Татар иле генә бәйрәм итми —
Кан кардәшләр, шөкер, һәммә җирдә;
Җир шарында ничә кыйтга булса,
Барча милләттәшләр бергә-бергә.

Гөрләп үтә икән сабан туе
Хәтта ерак Көньяк ярымшарда,
Аделаидада милли җанлы
Ирек Гариф[2] кебек ирләр барга.

Истә әле. Ирек мәйданында
Ул ялкынлы сүзләр сөйли иде,
Халкыбызга милли ирек даулый,
Маңкортларга ачы телле иде.

Онытмаган икән идеалларын,
Яшәсә дә Аделаидада,
Җир шарында һәммә татарның да
Милли уты янсын иде җанда.

---

[1] Тәминдар Мөхит — Япониядә яшәүче татар эшмәкәре, җәмәгать эшлеклесе.

[2] Ирек Гариф — Татар милли азатлык хәрәкәте җитәкчеләреннән берсе. Хәзер Австралиянең Аделаида каласында яши.

Без күптәннән — кадим заманнардан
Гүзәл сыйфатларны саклый-саклый,
Шәҗәрәне дәвам иттерәбез
Инде менә шушы көнгә чаклы.

Җуҗаньнар да безне, Иваннар да
Юк итмәкче иде җир йөзеннән,
Явызлыкны авызлыклар куәт
Бирде Ходай хәят диңгезеннән.

Явыз көчләр илгә янаганда,
Сугыш кырын ташлап качмадык без,
Тыныч гомер сөргән адәмнәрнең
Өсләренә үлем чәчмәдек без.

Без — татарлар: иген игүчеләр,
Корыч коючылар, төзүчеләр,
Мөгаллимнәр, җыру әйтүчеләр,
Бәхет эзләп дөнья гизүчеләр.

Без күкләрдә, океан төпләрендә,
Шахталарда яки кыяларда.
Тынгы белмәс иман иңгән җанга
Тик изгелек мөмкин ояларга.

Гадел бәһа бирер өчен тарих
Күзебезгә текәп кат-кат карар;
Йөзебез ак булгач, без үлемсез,
Без — мәңгелек халык,
Без — татарлар.

## *Империя, ач күзеңне!*

Кулың сузма, Мәскәү, көчең җитмәс,
Якалардан безне алалмассың;
Үз хәлең хәл — дөнья халыклары
Күз алдында инде тараласың.

Чечня әнә бер кат сабагыңны
Укытты бит шәпләп, үче ташып;
Утыра күр артың кысып кына —
Кычытмаган җирең йөрмә кашып.

Танклардан көчле ант барында,
Ракетадан җитез боерык булыр,
Акча өчен кеше үтереп йөргән
Контрактникка йодрык булыр.

Очкычың хет бомба төяп очсын,
Солдатың хет ятсын җиргә сеңеп,
Байрагына «Азатлык» дип язган
Горур халыкларны булмый җиңеп.

Империя, тарих хөкеме бу —
Хакыйкатькә кара — ач күзеңне!
Безнең хакта гайбәт салып кына
Юатырсыңмыни үз-үзеңне?!

Син сагынып элек булганнарны,
Яшь түгәсең һаман зарый-зарый;
Синең заман инде күптән үткән —
Дөнья бүген алгы көнгә карый.

## *Китап — хикмәт*

И китап, кайсы гасырның
Серләре эчләреңдә?
Өлешең зурдан тарихның
Бар изге эшләреңдә.
Кемнәрдер, надан халык дип,
Татарны хурлаганда,
Кадими чорлар артыннан
Китаплар сөрән сала.
Китсә дә татар баласы
Сөрелеп илдән-йорттан,
Иң элек газиз китабын
Коткарып калган уттан.
Иң авыр еллар кичкәндә,
Ул безгә юлдаш иде.
Ул боек чакта юатты,
Акыллы киңәш бирде.
Үз итте ул рун тамгасын
Һәм гарәп «әлифен» дә,
Кирәк булса, таный ала
Һәм әрмән хәрефен дә.
Матенадараны юк та —
Җай тапмый әле аңа,
Шулай да китап иң түрдә
Кадерле урын ала.
Киләчәк көннәр катында
Татар да булсын, дисәк,
Китаптан алыйк сабакны,
Китапка тотыйк исәп.

## *Колшәриф мәчете**

*(Җыр)*

Колшәрифкә атап мәчет салдык —
Манаралар башы көмеш ай;
Тәкъдирләргә ниләр язылгандыр
Язмышларны белә бер Ходай.

Биек-биек манарага менеп
Яңгыратыйк моңлы азанны.
Колшәриф лә дигән и изге зат
Шәһит китте саклап Казанны.

Гасыр арты гасыр үтә торды —
Зилзиләләр, җилләр уйнады;
Әмма хәтер илнең асыл ире
Колшәрифне оныттырмады.

Ул бүген дә әле безнең белән —
Сөеклесе изге затларның;
Күңелләргә якты уйлар салып,
Киләчәккә әйди татарны.

---

* Луиза Батыр-Болгари музыкасы.

## *Корбан бәйрәме*

*(Мөнәҗәт)*

Мөбарәк Корбан гаете —
Исламда изге бәйрәм.
Ходайның хикмәтләренә
Калырлык тәмам хәйран.

Сынамак булып иманын,
Ибраһим пәйгамбәргә
Җәбраил аркылы Аллаһ
Шундый әмер җибәргән.

Күргән Ибраһим пәйгамбәр
Өч төн рәттән бер үк төш;
Имеш, ул бердәнбер углын
Корбан чалырга тиеш.

Кызганыч бит, и нарасый,
Ике күзе карасы,
Һаҗәрдән туган баласы,
Аның йөрәк парәсе.

Ләкин Аллаһның сүзе бер —
Үтәми калып кара;
Гәрчә ул, инде картайгач,
Көттереп туган бала.

Алды кулга пычак вә бау
Ибраһим галәйһ-сәлам —
Аллаһка тугры икәнен
Бәян ит безгә, каләм!

Баралар дала буйлатып,
Әл-Бәшир дигән тауга;
Ибраһим галәйһ-сәламның
Күзеннән яшьләр ага.

— И атам, нигә еглыйсың? —
Дип сорау биргәч углы,
Әйтте Ибраһим пәйгамбәр:
— Аллаһтан әмер булды.

— И атам, үтә кушканны —
Аллаһтан узмас балаң... —
Дип әйткән шулчак аңарга
Исмәгыйль галәйһ-сәлам.

Бала дип үзәк өзә бит,
Шикне читкә куйса да,
Тик пычак кисми бугазны,
Никадәр ышкыса да.

Исмәгыйль галәйһ-сәлам гел
Кабатлый:
— Кылмыйк хата;
Аллаһның үтә әмерен —
Бугазла мине, ата...

Күк капулары ачылган,
Фәрештәләр Җир тулы —
Бер пәйгамбәр икенчесен
Бугазлый дип зар елый.

— Бәйләмә аякларымны —
Шикаять бирмәсеннәр,
Исмәгыйльне бугазлады...
Көч белән, димәсеннәр.

Шулай дип әйткәч Исмәгыйль,
Ибраһим галәйһ-сәлам
Пычакның үтмәслегенә
Инанды бугай тәмам.

— Йөземә текәп карама,
Аллаһның тыңла сүзен, —
Ди аңа углы Исмәгыйль,
Гаепле санап үзен.

Юк, кисми, кисми пычагы —
Чара юк аннан башка...
Һәм Ибраһим галәйһ-сәлам
Пычагын орды ташка.

Телгә килде шулчак пычак:
— Син киткәч таута таба,
Кисә күрмә, диде Аллаһ
Миңа җитмеш мәртәбә.

Сине Нәмруд утка салгач,
Аллаһ шул утка фәкать
«Янма!» дип бер әйткән иде —
Булмады бит һәлакәт.

Һәм аваз иңде күкләрдән,
Олылап ислам динен:
— Пычагың үтмәс булуы
Рәхимем сиңа минем.

Ибраһим, тәхкыйк, төшеңне
Расладың эшең белән,
Бергәләп гомер итегез
Сөекле кешең белән.

Хак Тәгаләдән вәхи бу,
Ибраһим, тауга кара:
Корбан чалу өчен аннан,
Күрче, куй төшеп бара.

Шат булды аның күңеле,
Шат булды барча галәм,
Аллаһ әкбәр, диде шунда
Җәбраил галәйһ-сәлам.

Тау итәгендә, бергәләп,
Куйны корбан чалдылар;
Аллаһ та разый, алар да
Исән-имин калдылар.

Ибраһим белән Исмәгыйль —
Рәсүлләр ата-уллы;
Изге гамәлләр кылганга,
Ходайга якын булды.

Шул заманнардан башланган
Бу гүзәл, олуг бәйрәм;
Ходайның хикмәтләренә
Калабыз тәмам хәйран.

## *Динебезне зурлап**

*(Җыр)*

Сызылып ла таңнар аткан чагында,
Изге җаннар шәһит киткән җирләрдә
Колшәрифкә атап мәчет салыйк, дип,
Фәрештәләр әйтте бөтен илләргә.

Аллаһ бар һәм ул бер, диеп йөрдек без,
Сөенәбез шуңа моңлы азанга;
Әллә кайдан балкып тора ул мәчет,
Нурлар чәчеп бөтен шәһри Казанга.

Иман утын ничә гасыр сүндерми
Саклап йөрттек без күңелләр түрендә;
Колшәрифкә һәйкәл булсын бу мәчет
Хөр мәмләкәт — Татарстан җирендә.

Манаралар очында, һай, алтын ай,
Манаралар Казансуда чагыла;
Татар иле, азатлыкка барганда,
Колшәрифле заманнарын сагына.

---

* Ганс Сәйфуллин музыкасы.

## *Таптыңмы?*

*Россия шовинистларына*

И ватансыз кавем, әрсез кавем,
Җанда яман уйлар уятып,
Кая барып бәрелергә белми,
Йөгерәсең дөнья буйлатып.

Варяглардан грекларга барган
Олы юлда талап йөрсәң дә,
Византия таҗын кимәкчесең,
Шөкер итми башың исәнгә.

Дәгъва итеп Тмутараканьга,
Скиф курганнарын актарып,
Өлешенә кереп башкаларның,
Язмакчысың үзеңә ак тарих.

Оныклары бүген Урартуның —
Кавказ җире тырный эчеңне:
Акылын җуйган илсез илбасарлар
Кол итмәкче горур чеченны.

Җитмәгәнме яулап алганнарың?!
Җитмәгәнме талап җыйганың?!
Килер бер көн... тотмас дисең мәллә
Күз яшьләре ярты җиһанның?!

Белми дисең мәллә Хак Тәгалә
Һәрбер гамәл, һәрбер актыңны?!
Бәхет эзләп җир читенә чаптың —
Бәхетеңне әмма... таптыңмы?!

## *Мәйдан көтә*

Сәгадәте өчен йодрык булып
Төйнәлергә тиеш заманда,
Ике татар өч партия булып
Тарткалаша әле һаман да.

Беркатлы да инде безнең халык —
Яулар чакта даулап, давайлап,
Суверенны кайчан бирәләр, дип
Сорый миннән кайбер агайлар.

Тот капчыгың — бирделәр ди сиңа —
Эт авызыннан сөяк ал, юләр!
Хәер генә сорап алып була,
Азатлыкны сорап бирмиләр.

Әле чак-чак булыр җан талашып,
Корбан бирә-бирә алсак та;
Шуңа күрә килер көнең өчен
Көрәшкә чык форсат бар чакта.

Ә утырсак шөкер итеп кенә,
Бәлеш ашап туйгач кикереп,
Суверенын түгел, хәтта суын
Бирмәс безгә беркем китереп.

## *Уяныгыз, гладиаторлар!*

Төннәр буе күзгә йокы керми,
Төннәр буе уем — дөньякүләм;
Төннәр буе шулай сөйләшәм мин
Хыялдагы Спартаклар белән.

Син, дим аңа, үзең уяудыр да,
Матурдыр да синең хакта җырлар,
Ник уянмый батыр яудашларың —
Ник уянмый гладиаторлар?!

Күрәсеңме: дөнья тулы коллар...
Богауланган куллар, хәтта телләр;
Һәр таң саен чыгып мәйданнарга,
Зарый-зарый елый азат җилләр.

Дөньяларны урыйм җилләр булып,
Кыйтгалар һәм заманалар кичеп,
Эзләп йөрим ерак тарихлардан
Бабайларның көрәшкәнен ничек.

Мин каңгырап йөрим җилләр белән —
Бу җырымны, бәлки, алар тыңлар.
Тәрәзләрен шакыйм батырларның:
Мондамы дип гладиаторлар?

Бу — замана шакый тәрәзләрне,
Тор, Колшәриф, Канкай, Гаяз, Муса!
Ирешербез олуг максатларга,
Ил өстендә фәкать таңнар туса.

Мин каңгырап йөрим төннәр буе...
Тынычланып бер көн ятармын да,
Ләкин бүген, һава һәм су кебек,
Ирек кирәк минем татарыма.

Ирек кирәк мазлум милләтләргә —
Үлгәннәргә түгел, исәннәргә;
Шамилләре булган Тау иленә,
Дудайлары булган чичәннәргә...

Син, Спартак, үзең мактаулы да,
Һәм матур да синең хакта җырлар;
Нигә уянмый соң варисларың,
Нигә йоклый гладиаторлар?!

Гаҗиз булып мең-мең сорау бирәм:
Нигә караңгылык, нигә томан?!
Бик макталган гомер юлыбыз да
Нигә шомлы... Аппий юлы сыман?!

Дөньякүләм кыргый шоу-тамаша.
Чырайлардан качкан елмаюлар...
Аренага арысланнар түгел,
Чыга гориллалар һәм... аюлар.

Ложа тулы сәрхуш патрицийлар,
Бәйрәм ясый бүген җырлап-биеп...
Сөенәләр әле, безнең аю
Гладиаторны җиңде, диеп.

Кол булырга безнең хакыбыз юк,
Хакыбыз юк безнең кол булырга!
Уяныгыз, гладиаторлар,
Кабат безнең сафка кушылырга!

Иртә әле тынычлану өчен —
Богауларда куллар, телләр, илләр...
Уянсын дип илдә каһарманнар,
Тәрәзләрне шакып йөри җилләр.

Җил — хәбәр ул. Хәбәр — киләчәктән,
Ихлас кына аны кемнәр тыңлар?!
Яуга чыгасы бар «Азатлык!» дип —
Уяныгыз, гладиаторлар!

# *Офыклар аръягында*

*(Поэма)*

1

Офыкларга тиеп рәшә чыңлый —
Көн кызуы җәйрәр мәл җиткән;
Күзем капшый ерак офыкларны —
Аръягында ниләр бар икән?

Күз ымсына нидер күрмәк булып,
Белмәк булып сәер серләрне.
Миңа таныш түгел кешеләр дә
Минем кебек гомер сөрәме?

Ә офыкта никтер хәрабәләр —
Узган мәллә заман давылы?!
Менә-менә таралырга тора
Офыктагы урыс авылы.

Кайчандыр бер үткән идем аннан —
Алабута баскан бар чатын;
Ник качтылар икән ташлап болай —
Идел дә бит юкса бик якын.

Ник, алайса, теге заманнарда
Бабамнардан талап алганнар?
Ник сөйрәлеп килә бүгенгәчә
Әрсез тарих язган ялганнар?

Ул кыйшаеп беткән тәреләрдә
Әллә чынлык бардыр дисеңме?
Бабаларым тире тамган җир бу —
Безнең телдән килә исеме...

Ярар инде, үткән — беткән, дим дә
Уем күчә кабат бүгенгә,
Шул ташландык авыл басуында
Дача салып ятам бит менә.

Кеше куян куа диеп кенә
Җир алдым да, гөнаһ шомлыгы...
Тик катлаулы, хәтта аңлаешсыз
Булып чыкты тормыш чынлыгы.

Ташы кирәк, бүрәнәсе кирәк,
Тактасы юк — кайдан табасың?!
Такташчалап сүгенеп җибәрәбез:
«Чемберленның сатыйм анасын...»

Эшләгәндә эшләр хөрти барса,
Көтелмәгән берәр хәл туса,
Ык-мык килгән чакта, сүзне сүзгә
Ялгар өчен Такташ булыша.

Шушы кырда йорт салырга исәп.
Хет Сарай сал — хәзер юк киртә...
Эх, ичмасам, дустым озаклады —
Киләм дигән иде бит иртә.

Аның белән бүген эш планы —
Ташлар тезеп нигез саласы,
Шагыйрьләргә Сарай кирәк түгел —
Ярар шунда берәр алачык.

Бөтен тараф чаж-чож, шак-шок килә,
Бер мизгел дә эшләр туктамый;
«Бакча» дигән бакча ширкәтендә
Балта-чүкеч куя ноктаны.

Күршеләрем Гыйльман белән Иван
(Алардагы малны кем саный?!)
Икесе дә коттедж җиткерделәр —
Бассейнлы, сауна, фонтанлы...

Ә без менә — ике юләр шагыйрь —
Әллә хак без, әллә хатабыз,
Егерменче гасыр азагында
Берәр куыш корып ятабыз.

Бу ташларны ничек кузгатырга? —
Бәлки, берәр әмәл чыгар дип,
Алай этеп, болай төртеп карыйм
Һәм кул селтәп кабам сигарет.

Машиналар уза алмый китә —
Күршеләр дә сүгенә башлады;
Таныш шофер нәкъ юл уртасына
Ташлап киткән зур-зур ташларны.

Ахыр менеп кунам таш башына —
Барыбер, дим, булмый кузгатып,
Утырам чумып төрле уйларыма,
Ерак офыкларга күз атып.

Карыйм, карыйм ерак офыкларга,
Офыкларда рәшә тирбәлә;
Рәшәләргә карап алданырга
Туа мәллә җиргә ир бала?!

2

Рәшә каймалаган офыкларның
Хикмәтләрен уйла иң элек;
Аръягында аның — яңа гасыр,
Аръягында — яңа меңьеллык.

Егерменче гасыр китеп бара —
Хушлашуның башы шушыдыр;
Ямансулап йөрәк кысылыр да,
Тарихларга тарих кушылыр.

Китеп бара егерменче гасыр...
Китеп бара яхшы-яманы...
Китеп бара ахмак сугышлар һәм
Бөек ачышларның заманы.

Елъязмага күчә Хиросима,
Ядкарь булып кала Гагарин,
Кеше әле һаман фараз итә
Алгы көндә бәхет табарын.

Ул һаман да изгелекләр тели,
Ул һаман да көтә таң гына,
Тик кемнәрдер һич тә көтмәгәндә
Китереп суга сугыш чаңына.

Егерменче гасыр туганда да,
Якты иде уе халыкның,
Тик нишләптер тормыш чоңгылыннан
Зобанилар өскә калыкты.

Ике сугыш — дөнья күләмендә...
Түнтәрешләр дисәң... бихисап:
Язмышларны төйде килеләрдә
Тормыш атлы усал зур кисап.

Кемнәр нинди исәп тоткандыр да,
Кем оттырып, кемнәр откандыр;
Тәти погонлылар орден алса,
Гадиләрне кабер йоткандыр.

Мин бабамны ишетеп кенә беләм,
Һәм балам да белми бабасын;
Буын белән буын — ара өзек,
Ялгар җаен ничек табасың?

Илләр белән илләр арасында
Илче булып никтер ут йөрде;
Кем гаепле минем ятимлеккә —
Сталинмы, әллә Гитлермы?

Без СССР дигән илдә үстек —
Нинди илдер хәзер — кем белә?!
Коммунизм төзеп яткан җирдән
Әйләндек тә куйдык кирегә.

Каберләрдән кубарылганнардыр
Кампанелла, Маркс ишеләр,
Коммунизм өчен шәһит киткән
Һәм шул денгә тугры кешеләр.

Диваналар көндәлеге — тарих,
Фаҗигаләр тулы һәр бабы;
Исәбенә күрә хисабы шул,
Килесенә күрә кисабы.

Кемнәргәдер һаман патша кирәк —
Тиз үзгәрә дөнья. Ник алай?..
Иң акыллы булды Столыпин,
Изге булды канлы Николай.

Мир үгезе Распутинга кемдер
Чыгарганда катгый карарны,
Сөембикә нәселеннән килгән
Юсуповлар эшкә ярады.

Тик титулы бездә килеш калды —
«Князь» булды һәммә татар да —
Әйтерсең ул иң зур гаеп иде
ГУЛАГларда безне атарга.

Күнегелгән иде патшаларсыз,
Тик булмаган икән отыры;
Генсек дигән яңа император
Безнең башка менеп утырды.

Ничек кенә мактасак та аны,
Җитеп хәтта «Алла» диюгә.
Йота торды безне берәм-берәм,
Әкияттәге ачкүз диюдәй.

Канга сусап, җанга сусап суйды
Ата улны, улы атаны;
Шул аяусыз вәхшәт эчләрендә
Туган иде Совет ватаны.

Күрде безнең башлар. Күрмәгәнен
Безнең ата-баба татыган.
Хәвеф-хәтәр кабат килмәсме соң
Офыктагы рәшә артыннан?!

3

Ул, ниһаять, килде.
Хет үпкәлә?..
Үпкәләмәсәң дә, тап җаен;
Авыз ерык (берни булмагандай!),
Биштәрендә — «урыс малае».

Кесәсенә кермәс сүзләр эзләп,
Бер сорауга — туксан җавабы;
Әфләтун күк хөкем чыгара да
Үзләштерә бөтен савабын.

Бу юлы да бәхәсләшми генә
Кырт кисте дә куйды нык әйтеп:
— Таш, таш диеп башлар катырганчы,
Әйдә әле, тамак чылатыйк.

Кыярлар да үскән тәгәрәшеп...
Кирәкмәгән бакча йорты да...
Югыйсә бу карт көнеңдә сиңа
Бакча йорты нинди чуртыңа!

Малаең да барыбер кадерен белмәс...
(...Чыннан да шул ерак басуда
Ник чиләнеп йөрсен! Бакча-фәлән
Кирәкмәс тә яңа гасырда!)

Минем малай ЮМК[1] да укый —
Кибернетик зиһен аңарда;
Тик җәдвәлен белми тапкырлауның,
Компьютерга куша санарга.

Бәрәңгене дә ул пробиркада —
Яңа ысул белән үстерер,
Ясалма ит, икмәк, шалкан ашап,
Ясалма сөт эчеп көн күрер.

Бәхәс куертабыз (Сүзне сүзгә
Шайтан суы ялгый һаман да!),
Күчә-күчә иске заманнардан
Яңа гасыр туар заманга.

Син:
— Еракка китеп кара, дисең, —
Офык шул ук — кара, карама;
Чынга ашмый калган хыял кебек,
Рәшә ята ике арада.

Мин бит, дустым, комсомоллы чордан.
Ундүрт яшьтән...
Кердем инанып...
Без нигезен төзибез дип йөрдек
Коммунизм дигән бинаның.

[1] Югары математика һәм кибернетика факультеты.

Комсомоллар башлыгы да булдым —
Райкомнарда түгел, класста,
Тик барыбер иптәш коммунистлар
Үткәрмәде мине властька.

Большевиклар никтер үз итмәде —
Номенклатурага кертмәде;
Альберт Фәтхи белән мине әле
«Милләтчеләр» дип тә үртәде.

«Милләт», «Милләт» диеп йөрүчеләр
Хәзер генә буа буарлык.
Бик аз идек, шуңа күрә безгә
Бүгеннән үк һәйкәл куярлык.

Аклана дип уйлыйсыңдыр инде...
Тик каралсаң... кирәк аклану.
Ул чорда бит һәммә шигырьдә дә
Партийный сүз генә якланды.

Кара төндә күрше карчыгының
Ак әтәчен кереп урлаган
Такташка бит гашыйк идек ул чак —
Совет булды аны зурлаган.

Искелеккә бомба итеп санап,
Комсомоллар дигән халыкны,
Иманлы да, имансыз да булып,
Яңа буын җирдә калыкты.

...Һәрнәрсәгә бәя бирә-бирә,
Мактап җәйнең матур мәлләрен,
Төшә-төшә шешә төпләренә
Сөйләшәбез дөнья хәлләрен.

Без искеләр инде — күңел күптән
Оя корган заман кортына;
Коммунизм төзи алмаган күк
Төзи алмабыздыр йортны да.

4

Без искеләр инде. Иске заман
Исе сеңгән безнең һәр җырга;
Динозаврларга караган күк
Карар безгә яңа гасыр да.

Мәтәштермә, син дә суфый түгел,
Язганыңда — бик еш шул чорлар,
Мин дә, башкалардан калышмыйм, дип
Калыпладым кызыл шигырьләр.

Әүлиялык бездән читтә йөрде —
Сүнә язды иман утлары;
Инде тәмам дәһри булып җиткәч,
«Бисмилла»быз гына коткарды.

Бу дөньяның барча хикмәтләрен
Нострадамус белсә белгәндер;
Минем дә бит, күрәзәче булып,
Нәрсә әйтәседер килә бер.

Мин, әлбәттә, мәңгелек зат түгел —
Анысы ахмак хыял — гел бушка;
Соң, алайса, ниләр фараз итим —
Кайсы ашар аның тормышка?!

Марс атлы планетага менеп
Сындырырбыз, бәлки, «ярты»ны?
Фест дисбесен укып карарга дыр
Латин хәрефләре аркылы?

Ноноробот, бәлки, робот ясар,
Ә тамагы җирнең туярмы?
Әллә дошманлашып соң чиккәчә,
Адәмнәрне адәм суярмы?

Ничә хатын назлап торыр безне —
Иң гайрәтле егет-ирләрне?
Ниләр белән дәвалар лар икән
Безнең чордан калган чирләрне?

Суверенлык безнең сакланырмы?
Ирек куелырмы чечнга?
Русия гел күсәк күтәрерме,
Таянып шул кыргый көченә?

Егерменче гасыр мәлләрендә
Корыганын күреп тамырның,
Әллә аңлап яңа вазгыятьне,
Үткәннәрдән сабак алырмы?

Сорау...
Сорау...
Сорау...
Җавапларын
Нострадамус хәтта табалмас;
Үз тарихын һәр чор үзе яза,
Офыклардан томан таралгач...

Егерменче гасыр китеп бара —
Хушлашуның башы шушыдыр;
Вакыт йөрәк кебек кысылыр да,
Тарихларга тарих кушылыр.

Иске гасыр белән яңа гасыр
Бер-берсенә текәп караган;
Нинди хикмәт ул караш та, дисәм,
Фәкать рәшә ике арада.

## *Юксыну*

Актарам куен дәфтәрен —
Исемнәр дә саннар;
Ә аларда минем өчен
Күпме газиз җаннар.

Телефонын берәрсенең
Җыйыйм әле, дисәм,
Кайчакта китәм имәнеп:
Кемнәрем соң исән?!

Мәҗлесләрдә шау-гөр килеп
Утырганда дуслар,
Кемнәрне соң якын итеп,
Кемнәр әйтер тостлар?!

Югалтулар читләп үтмәс
Сине, мине генә;
Кайсы абый, кайсы апа,
Кайсы эне генә.

Үзем дә мин карт түгел дә,
Никтер миннән алдан
Япь-яшь күе күпме дуслар
Җирдән китеп барган.

Сөйләшәсе, серләшәсе
Килгән чаклар байтак —
Гаҗиз булам, күңел тулып,
Хәтерләрне айкап.

Үзем дә яшь түгел дә бит,
Җил искәндә илдә,
Өлкәннәрнең куенына
Сыенасы килә.

Миңа сабаклар өйрәткән
Остазларым кайда?
Хәзер мин күп беләмдер дә,
Тик аннан ни файда?

Кайда Нәкый, кайда Бакый,
Туфан, Нури, Бәшир?![1]
Инде кемнәр сөеп безне:
«Шәкертләр», — дип дәшер?!

Куен дәфтәрем битләре —
Некрологтыр сыман;
Аңа күпме язмыш сыйган,
Күпме сагыш сыйган.

Дога белән искә алам
Изге хисләремдә;
Ак каеннар үссен иде
Кабер өсләрендә.

## *Күңелдә кинә калды*

*Гомәр Бәширов истәлегенә*

Көфер сүз әйтсәм әйткәнмен,
Гомәр ага, тиргәмә;
Телемне тыеп булмады
Хәтта шундый җирдә дә.

Ни җитте җир түгел, беләм, —
Зур Кремль Сарае;
Дивардагы сурәтләргә
Карале син, карале…

---

[1] Халкыбызның мәшһүр зыялылары.

Рәсемдә, имештер, безнең
Кысык күзле бабалар
Урыс баһадирларына
Коты очып караган.

Имештер, татар яугире
Дошманның соңгысы ла —
Каршы торалмый Мәскәүнең
Угына, сөңгесенә.

Күреп китсеннәр, диләрдер,
Көчен урыс үченең...
Ник килдек соң без бирегә —
Шуңа карар өченме?!

Язучылар корылтае
Дип җыелган бар кеше
Әсәрләрдә тик дөресен
Сурәтләргә тиешле.

Ник, алайса, Мәскәү үзе
Сөйләми чын дөресен,
Бабамнарны мыскыл итеп
Сукалый ник киресен?!

Әйтергә иде бит шуны
Корылтай мөнбәреннән...
Ә анда алтын медальле
Югары чиннар гына.

Аларга дөрес, ялганны
Аеру кирәк түгел;
Бәйрәмгә диеп килсәм дә,
Рәнҗүле шуңа күңел.

Көфер сүз булса да, әйтим,
Гомәр ага, тиргәмә;
Телне тешләп калып булмый
Хәтта шундый җирдә дә.

«Ләббәйкә!» диеп торырга
Халык әллә сарыкмы?!
Әллә кемнәр мыскыл итә
Безнең затлы тарихны.

Гасырларны бизәп узган
Безнең батыр бабалар —
Васыять дип алсын иде
Шуны варис балалар.

Яшәсеннәр кимсенмичә,
Туган җир өчен әрнеп,
Ир булсыннар суын эчеп
Җидегән чишмәләрнең.

## *Шагыйрь дигән исем картлык белми...*

*Әхмәт Исхакка*

Әхмәт абый, сиңа сиксән, диләр —
Хакмы шул сүз, әллә түгелме?!
Мөгаен, әз генә арттыру бардыр...
Әле кайчан гына күңелне
«Таш урамнар җыры» белән назлап
Ишеттердең шигъри сүзеңне;
Син халыкны зурлап иҗат иттең,
Хәзер халык зурлый үзеңне.
Ап-ак чәчле мәшһүр аксакаллар
Карәхмәткә бүген карасын;
Кара кашлы, кара чәчле көе
Атлап уза еллар арасын.

## *Әллә?.. Әллә?..*

*Илһам Шакировка*

Кайдан килде әле үзәк өзгеч бу җыр?!
Кемнәр салды әле йөрәкләргә яра?!
Кайда кайтавазы изге шат җырларның?!
Гомер үтеп бара, гомер үтеп бара...
Өзгәләнә күңел, җырчы ник моңлана:
«Әллә яңгыр ява... әллә йолдыз яна...»

Нигә чыкты әле үзәк өзгеч бу җыр?!
Алсу түгелмени язмышларның таңы?!
Юатасы иде, юатасы иде
Җыр җырлаган саен өзгәләнгән җанны.
Бәргәләнә күңел, һаман җан сызлана:
«Әллә яңгыр ява... әллә йолдыз яна...»

Нигә җырлыйсың син үзәк өзгеч җырны?
Бәгырь уртасына күз яшьләре тама:
Кемгә гаҗәп бу җыр, кемгә газап бу җыр,
Кемгә яңгыр ява, кемгә йолдыз яна.
Өзгәләнә күңел һаман, һай, сызлана:
«Әллә яңгыр ява... әллә йолдыз яна...»

## *Сәхнәләрнең иң түреннән*

*СССРның халык артисты Азат Аббасовка*

Халык сине үз иткәнгә,
Алкышлары — дәлилле;
Син сәхнәгә алып мендең
Ил батыры Җәлилне.

Син уйнаган Булат, Самат,
Батырҗаннар — хәтердә.
Сагынып искә алабыз
Без аларны хәзер дә.

Тамашачы әйтә әнә:
Син башкарган өчен, ди,
Каварадоссиның кулын
Кысар иде Пуччини.

Эзләдең син, Фауст булып,
Яшәешнең асылын,
Күңелләрдә яз иттең син
Һәр елның дүрт фасылын.

## *Саклыйк дусларны*

*Композитор Фасил*
*Әхмәтов истәлегенә*

Үтә гомерләр дөньялар куып —
Гөлләр үстереп һәм илләр гизеп;
Китә җан дуслар беркөн арадан,
Китә җан дуслар, үзәкне өзеп.

Үтәселәр бар карурман аша —
Әйтүдән элек соңгы «Хуш!»ларны,
Гомер юлына маяклар итеп
Саклыйк дусларны, саклыйк дусларны.

Рәхәт тә бит ул җирдә яшәве —
Офыкта рәшә, җанда җыр бетми;
Килә ләкин көн — серләшер өчен,
Киңәшер өчен чын дуслар җитми.

Җырлыйсы җырлар җырланмый кала,
Әйтәсе сүзләр әйтелми кала;
Искә төшә дә бергә вакытлар,
Газиз башларны уйларга сала.

Үтәселәр бар карурман аша —
Әйтүдән элек соңгы «Хуш!»ларны,
Гомер юлына маяклар итеп
Саклыйк дусларны, саклыйк дусларны.

## *Ул диңгезнең кайсын гына күрмәгән*

*Диңгезче-әдип Миргазиян Юныска*

— Нинди шау-шу, ыгы-зыгы әле бу?!
Җир бетереп эзлисез соң сез кемне?!
— Котлау өчен тотып булмый һичничек —
Юбилее үтеп китә бит инде...

— Миргазиян Юныс кайда? — дисезме. —
Занзибарда, ят кавемнәр катында.
— Ә Занзибар кай тарафта? — дисезме. —
Занзибар зәңгәр болытлар артында.

Ул «Ямәнгә сәяхәт» итеп, аннан
Бүләккә дип «Тимер фил» алып кайткан,
«Зәңгәр дөнья», «Янар таулар» күргән дә
«Теләп алган давыл»га да шаккаткан.

Әдипнең теләп «Биектә калу»ын,
«Шәмдәлләрдә генә утлар яна»дыр.
«Таңда Босфор аша» үткән чагында,
Уйларында аның газиз анадыр.

Ул һавалар иңләп очкан укчы да,
Ул диңгезнең кайсын гына кичмәгән.
Җитмеш һөнәр дә аз егет кешегә,
Дигән дә ул, әллә ниләр эшләгән.

Ул — күптәнге диңгезче-язучыбыз,
Ул — талантлы һәм кадерле кешебез.
Очратсагыз, зинһар, сәлам әйтегез,
Ике кулын каты итеп кысыгыз.

## *Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗан истәлегенә*

*(Мәрсия)*

Язлар килә... кабат язлар килә...
Зәңгәрләнә бара аяз күк...
Бар тарафны назлап кояш көлә —
Дөнья матур... бары Рәшит юк.

Мәйданнарда кайнар чакырулар —
Йөрәкләрдә, димәк, сүнми ут;
Татар өчен мөстәкыйльлек даулап,
Көрәш дәвам итә... Рәшит юк.

Шигарь булып яңгыраса шигырь,
Күңел таша, шаша шактый ук;
Илдә сирәк кунак — шатлык та бар,
Тик сөенеп булмый — Рәшит юк.

## *Соңгы юлга озатканда*

Үлгәннәрдән ирләр үч алмый!!!

*Рәшит Әхмәтҗанов*

Ул көлми дә, еламый да инде —
Чыраенда салкын битарафлык;
Китеп бара теге дөньяларга,
Бу дөньядан инде тәмам арып.

Ул утлар һәм сулар кичкән иде,
Байтак иде орден-медальләре —
Мендәрчекләр ягына карый-карый,
Күккә чөеп мактадылар аны.

Рәнҗеткәндер, бәлки, кемнәрнедер,
Кемнәргәдер гадел булмагандыр —
Изге гамәлен дә, гөнаһын да
Нәнкир белән Мөнкир язып алыр.

Тормыш юлын искә төшерәләр,
Табут тирәсендә тып-тын калып:
«Яхшы кешеме?..» — дип сорадылар,
«Яхшы иде...» — диде килгән халык.

Безнең хөкем — безнең хөкем инде —
Үлгәннәргә бәя һәрчак уңай.
Онытабыз кайчак бер чынлыкны:
Соңгы сүзне әйтә фәкать Ходай.

## *Камышлы*

*Зиннур Мансуровка*

Хәтерлимсең, Зиннур, кышкы юлны,
Хәтерлимсең, Зиннур, Камышлыны?! —
Шундый суык көнне һичберкемнең
Чыкмас кебек иде тавыш-тыны.

Капкаларны бикләп җылы өйдә
Тыныч кына ятар, дисәң, халык,
Ә ул әнә залга сыя алмый
Шигъри аваз көтә, тып-тын калып.

Хикмәтле сүз көтә, гыйбрәт көтә.
Шагыйрь өчен алкыш — иң зур бүләк;
Бу мәхәббәт өчен кешеләргә
Гомер белән генә була түләп.

Авыл безгә итек бүләк итте,
Алкышына кушып, истәлеккә;
Ничә еллар буе рәхмәт укыйм,
Ул салкын кыш һаман истә дип тә,
Якташларын искә төшереп тә. —
Әнвәр абый[1], их, шәп кеше иде,
Төн утырып шигырь тыңлаганга
Сөенүче ирләр ише иде.

Ә ул көнне бары бергә булды:
Шигырь, суык, итек, Әнвәр абый…
Менә шуңа тагын Камышлыны
Искә алам еллар саный-саный.

---

[1] Шагыйрь Әнвәр Давыдов.

Үз һәм якын булыр икән шундый —
Җырлагангадыр ул алар хисен;
Ым гына как, йөгереп килерләр күк
Яман сүздән безне саклар өчен.

Гел күңелдә йөри, гел күңелдә
Сөенечле җыры, сагыш-моңы;
Хәтерлимсең, Зиннур, кышкы юлны,
Хәтерлимсең, Зиннур, Камышлыны?

## Рәхмәтләр килә төяп

*Татарстанның халык артисты*
*Наил Шәйхетдиновка*

Тарих мең дә тугыз йөз дә
Кырык бернең язында
Наил ибне Шәйхетдиннең
Метрикәсе язылган.

Сөлчә суы буйларында
Буй үстерде бу егет,
Кем уйлаган, ул халкыбыз
Артисты булыр диеп.

Осталыгы сокланырлык —
Торды Наил сүзендә;
Уйнады ул хәтта Хуҗа
Насретдиннең үзен дә.

Ә башка рольләр хакында
Әйтеп тә торасы юк,
Картаясың инде дип тә
Кәефен кырасы юк.

Лашман халкы гына түгел,
Бөтен бер Җөмһүрият
Рәхмәт әйтә аңа бүген
Һәм килә котлау төяп.

## *Яралган ул ялкыннан...*

*Татарстанның атказанган артисткасы, радио дикторы Фәйрүзә Мәсгутнең туган көненә*

Фәйрүзәне кем дисәгез —
Асылташлар затыннан;
Яралган ул алкын судан
Һәм сүрелмәс ялкыннан.

Яралган ул мәхәббәтнең
Иң татлы мизгелендә.
Былбыллар белән ярышып
Үскән туган илендә.

Тавышы шуңа моңлыдыр,
Матур уй уйлатадыр,
Дәртлегә дәртләр өстидер,
Күңелне юатадыр.

Туган көннәр үтәр-китәр
Аккан сулар шикелле,
Бул, Фәйрүзә, һәрвакытта
Бүгенгедәй сөйкемле.

Кыш тусаң да, җәйне уйла —
Ак булыр киләчәкләр,
Җәй көнедәй көлеп торсын
Өегездә чәчәкләр.

* * *

*Рахмай Хисмәтуллага*

Ватаны була күңелнең,
Ватаны була җырның;
Нурлы як, Нур Баянлы як,
Җырлы як — туган җирең.

Талгын җилләр исеп тора,
Гомерләр кичеп тора,
Әнәктән Түбән Камага
Моңнары күчеп тора.

Ата да «Кама таңнары»,
Каланы бизи нуры;
Чылтырап сеңә күңелгә
«Җидегән чишмә» җыры.

Җыр булса — икмәк игелә,
Икмәк бар — илләр имин;
Гигантлар туган тарафта
Илһамың туды синең.

И әйбәт кеше икәннәр
Җирдәш һәм җырдашларың —
Китапларың сөйли безгә
Ак уен чордашларның.

Илгә тугры хезмәт итү —
Бәхетнең ул иң зуры.
Алда юллар, еллар, җырлар —
Тот руленне, тот туры.

## Ә йөрәктә милли хисләр...

*Журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Римзил Вәлиевкә*

Сорасаң ул кайсы яктан, дип —
Талантлар күп туган төбәктән;
Аны бу тормышның чынлыгы
Хакыйкать фәненә өйрәткән.

Озаткан Бишбүләк үз улын
Дүсәннән еракка-еракка;
Тик милли хисләре кайда да
Сүнмичә сакланган йөрәктә.

Ишетсәң «Азатлык» тавышын,
«Дөнья»да вазгыять агышын,
Үз итеп һәм көтеп, шулай, дип
Тыңлыйбыз без аның тавышын.

Бу ярты гасырлык гомернең
Зур итеп бәялик кадерен;
Татарның чын сүзе, чын моңы
Иңләсен дөньяның бар җирен.

## Киек казлар кайткан чакта

*Эшче-журналист Равил Шәрипов ядкаре*

Сине салкын гүргә иңдергәндә
Кайта иде илгә киек казлар;
Яшисе дә, тик яшисе идең —
Килә иде чөнки матур язлар.

Киек казлар үтте каңгылдашып —
Карап калдык шуңа хәйран калып.
Сулкылдады йөрәк, моңсу иде
Җеназаңа килгән һәммә халык.

Кем уйлаган... сине — җан дустымны
Ләхеткә мин иңдерермен диеп,
Күпме хәсрәт сеңгән йөрәгемә
Тагын берне сеңдерермен диеп.

Без, татарның ятим балалары,
Ничә еллар гел-гел бергә идек;
Шатлык-кайгыларны уртак итеп,
Бергә үстек... бергә кызлар сөйдек.

Күңелгә син яшьлек таңнарында,
Иң тугры дус булып үтеп кердең —
Мин юк чакта әрсез егетләрдән
Сөйгәнемне хәтта саклый идең.

Әй ул безнең туймый сөйләшкәннәр,
Безне якын иткән милләт хисе;
Сагынып кына уфтанырга калды —
Үткәндә шул инде бөтенесе.

Киек казлар илгә кайткан чакта,
Безне ятим итеп, гүргә кердең...
Югыйсә бит тормыш сөя идең,
«Без — яшәүчән халык», — дия идең.

Китә дуслар... китә берәм-берәм,
Уя-уя җанга яңа яра.
Дуслар киткән саен күңелемдә
Гел ялгызлык хисе арта бара.

## *Заман белән бәхәстә*

*Шагыйрь дустым Рәшит Шиһапка*

Еллар сызган юллар үткән чакта,
Без кичәсе күпме үрләр бар.
Шул юлларда заманалар белән
Бәхәсләшә алган ирләр бар.

Чал чәчеңә Поэзия атлы
Гүзәл туташ килеп кагылса,
Дәва таба җаның шул шигырьдән —
Сихри моңнар аннан агыла.

Картаерга әле иртә безгә —
Яшисе бар тагын шул чаклы.
Төшермә син кулдан «Хакыйкать» дип,
Бөек шигарь язган байракны.

Еллар булсын, үрле юллар булсын —
Нәрсә алар синдәй егеткә;
Шигъри таңың һәрчак алсу булсын —
Без һәммәбез шундый өметтә.

* * *

*Сабакташым академик Фоат Гарифуллинга*

Бу гармунның ни тылсымы бардыр? —
Уйнаганда Фоат, бер тынып,
Шушы телләренә бас син, диеп,
Бармаклары тора ымсынып.

Йөрәгенең кайсы кылларыннан
Өзелеп тама икән бу моңнар?
Уйный гармун, уйный, ул уйнаса,
Тыныч кына аны кем тыңлар?!

Без яшәгән гомер, ни гаҗәптер,
Шушы гармун моңы шикелле.
Чыңлап куя, инде ерак калган
Яшь чакларның соңы шикелле.

## *Җырлар сәламе*

*Фольклорчы Илбарис Надировка*

Илбарисның ил каршында
Йөзе ак, эше күркәм.
Үз итеп хезмәттәшләре
Сәламли һәр көн иртән.
Сәламли «Кара урман»нар,
Сәламли «Иркен кырлар»,
Сәламли ил авызыннан
Төшмәскә тиеш җырлар.

Ул җырлар җыеп ил гизде,
Бөртекләп йөрде җыеп,
Аларны газиз халкыбыз
Мәңге җырласын диеп.

Җыр картаймый, ил картаймый,
Чөнки җанда утлар бар.
Җыр илчесе Илбариска —
Шуңа безнең котлаулар.

## *Мәзәктәй мәзәкчән, мәкальдәй мәгънәле*

*Фольклорчы Хуҗи Мәхмутовка*

Кем дип әйтик бу Хуҗины?! —
Табышмактай серле дә,
Мәзәк кебек мәзәкчән дә,
Мәкаль кебек төрле дә.

Китаплары томлап-томлап,
Тагын кыра ни, дисәк,
Газета вә журналларга
Язганы да бихисап.

Өстәвенә радиодан
Сөйләмәгән көне юк.
Ким түгел ул Насретдиннән —
Үзе тапкыр, үзе шук.

Инде тәмам балигъ булгач,
Илһам килеп бер чорда,
Хатыныннан качып кына
Яза, диләр, шигырь дә.

Профессор, академик,
Атказанган, лауреат...
Инде хәзер тынычланып,
Мич башына мен дә ят...

Тик бүген ул тынып торсын —
Безнең дә сөйлисе бар,
Тынгы белмәсен һаман дип,
Теләкләр телисе бар.
Вәт!

## *Әкиятче турында әкият*

*Фольклорчы Ленар Җамалетдиновка*

Әкиятче карт бабайлар
Сөйли безгә һаман да,
Шундый хәлләр булган диеп,
Борын-борын заманда.
Могҗизалар, маҗаралар
Булгандыр, ди, борында,
Исләр китеп торам менә
Бүгенгеләр турында.
Әкият ул әкият инде —
Чынын, белмим, кем әйтер.
Хәзер пәйда булган, диләр,
Ленар атлы бер батыр.
Таңбатырга сердәш, ди, ул,
Камыр батыр —кордаш, ди,
Тагын да ничәмә-ничә
Батырларга чордаш, ди,
Ул — гаделлек сакчысы, ди,
Хаксызлыкка түзми, ди,
Авылдан йөреп авылга,
Албастылар эзли, ди.
Диюләрнең, гыйфритләрнең
Иманын укыта, ди,
Һәм хәтта карганың күзен
Каргадан чукыта, ди.
Ул кызганып Үги кызны,
Чәчләрен тараган, ди.
Аннан Убырлы карчыкның
Паспортын караган, ди.
Шуңа аңа бүләк биргән
Лично үзе — Шүрәле.

60 яше белән котлап
Кул кыса бит — күр әле.
...Заман — авыр, тормыш — чыр-чу,
Тик боекмый яшә син;
Күңелләрне юатырдай
Әкиятләр яшәсен!

## *Туплар тынып торганда*

*Сугыш ветераннары истәлегенә*

Таң эленгән каен башларына,
Яңгыратмый бүген туп җирне;
Тик былбыллар сайрый үзәк өзеп,
Тик кәккүкләр саный гомерне.

Тынлык кирәк миңа, тынлык кирәк —
Уйлар кочагында калыйм бер,
Еракташы газиз туганнарны
Сагынып ла искә алыйм бер.

Яу кырында дуслар ятып калды
Әле кичә генә, таң тугач;
Йөрәгемдә әллә ничә яра —
Юат мине, юат, сандугач.

Тынлык кирәк миңа, тынлык кирәк —
Тынлык тансык шомлы юлларда.
Сана, кәккүк, сана гомеремне,
Тик кайгылы хәбәр юрама.

Кайтасым бар туган якларыма —
Көтә мине газиз кырларым;
Исән калсам, илдәшләрем белән
Шатлык көен генә җырлармын.

Тынлык кирәк миңа, тынлык кирәк —
Җиңү көнен күрер җир кайда?
Сагынадыр мине, сагынадыр
Кырлар алиһәсе тургай да.

## Уртак җыр

Әйдә җырлыйк, дуслар,
Һәммәбезгә бер җыр —
Яңгырасын бар Җир шарына;
Урман-кырлар чыңлар,
Диңгез-таулар тыңлар
Безнең теләкләрнең барын да.

Күктә кояш көлсә,
Җиргә муллык килсә,
Җан сөенә, илләр сөенә;
Чыккан чакта юлга,
Кул тотынсын кулга —
Яшибез бит Җирдә бер генә.

Һәрчак тату яшәп,
Җир йөзендә яшьнәп,
Җырлыйк матур таңнар турында.
Яңгырасын шатлык,
Бәхет, сөю, сафлык
Халыкларның күмәк җырында.

## *Исемем шундый минем*

*Үзбәк шагыйре*
*Нормурад Норзуллаевка*

Бервакытны кызык карап йөргән чакта,
Һиндстан дип дан казанган гүзәл якта,
Тиктомалдан сүзләр китте автобуста
Ни өчендер мин йөреткән исем хакта.

Без Бомбейдан Калькуттага бара идек —
Әллә инде, сүз юктан сүз булсын, дидек,
Кыскартырга теләдекме озын юлны,
Ташкенттагы шагыйрь дустым сорау куйды:
«Карагыз сез бу һиндларны: кайчан да бер
Татарларның зур шагыйре килер диптер,
Бер үзенә атап салган ике шәһәр —
Әхмәдабад белән... тагын Әхмәднаһар».

Шаян сүздән һәммә кеше көлеп алды,
Тик бер адәм, йөзен чытып, җитди калды;
Аннан әйтте: «Соң, алайса, син җавап бир —
Ни аңлата Николаев? Владимир?..
Шундый ук бит олуг мәгънәләргә ия
Русиядә безнең исем-фамилия;
Иван исемен йөрткәннәрне әйткән дә юк —
Аны йөрткән калалар күп, салалар күп».
Бер якташым: «Ат аягын дагаласа,
Бака ботын кыстыра», — дип әйтеп куйды,
Ә Нормурад, дәвам итеп шул ук сүзне,
Шулчак «көфер сүз» әйтергә хәтта кыйды:
«Русия дә Русия дип сөйлибез дә,
Ни биргән ул безнең милли телебезгә?!
Ә Әхмәтләр, әнә кара, дөнья тулы —
Әхмәт атлы һәр атаклы халык улы.

Ул Сукарно, Бен Белла һәм Секу Туре,
Ни хикмәттер Әхмәт атлы булып йөри.
Һәм җәннәттә рәсүлебез Мөхәммәт тә
Әверелгән һаман да бит шул... Әхмәткә».

Безнең барча «гөнаһларны» язып барган
Теге абзый теш аралаш әйтте аннан:
«Тел сөяксез, әйләнер, гел бер сүзне сөйләр —
Сез — төркиләр, һәммәгез дә милләтчеләр...»

Кызып алды минем якташ:
«Без кемнән ким?!
Бармы сездә йә Вил, йә Нил, йә Рим, йә Ким...
Бәйнәлмиләл булыйк, диеп йөрисез дә,
Ни өчен соң Николай да Иван сездә?!
Казынырга кирәк түгел тиреслектә.
Милләтченең чыны сездер дөреслектә.
Бездә бирәү әнә, сезгә ярар өчен,
Үз улына биргән Иван дигән исем».

Сиксән күз һәм туксан колак сизгер заман —
Дилбегәдән ычкындыкмы монда тәмам,
Каһәр суккан шул телебез аркасында
Бу сөйләшү алуы бар башка дәвам...

Ә шулай да горурландым исемемә —
Гомер буе туры килсен җисемемә;
Мәгънәле дә, әйтүе дә ансат, җиңел,
Өстәвенә Вил дә түгел, Нил дә түгел.

Бик күпләрне Әхмәт дигән исем бизи —
Гарәпләрнең «иң мактаулы» дигән сүзе.
Мин көн саен үз-үземә теләк телим:
«И Ходаем, исемемә лаек булыйм!..»

## Һәйкәл

Көнләштереп мәшһүр адәмнәрне
Тормаса да мәйдан киңлегендә,
Һәйкәлем бар минем, һәйкәлем бар,
Минем һәйкәл — халкым күңелендә.

Өзелгәнмен аның бәгыреннән
Килер көнгә корбан каны булып,
Өзелгәнмен шигъри җаны булып,
Өзелгәнмен ак вөҗданы булып.

Бер илаһи таңда вәхи инде —
Гаҗәеп моң күңелемә сеңде,
Фани дөнья туфаннары аны
Мәңге-мәңге юа алмас инде.

Кемсәләре кыләп сарып йөрсә,
Алла белән Иблис арасында,
Халкым өчен хәтәр мизгелләрдә
Иелдем мин аның ярасына.

Ул ярада уклар эзе иде,
Заманнарның яман сүзе иде,
Ул сызланып нәзер әйтте миңа:
«Якла мине, акла мине», — диде.

Кемдер аны вәхши санаса да,
Рәнҗүләрдән җаны канаса да,
Ул минеке иде, ул минеке.
Мин — аныкы... үлем янаса да.

Карурманнар моңын җырга кушып,
Хәсрәт дәрьясыннан сулар эчеп,
Ак байракка язып хак сүзләрне,
Барам менә гомер юлын кичеп.

Моңлы гына ул җыр, зарлы гына,
Ис китми тик дөнья тарлыгына,
Мин ышанам татар күңелендә
Хәтер-һәйкәл миңа барлыгына.

## III

*Бакый дөнья гомерләрнең*
*Фанилыгын — әйе! — сөйләр.*
*Тик барыбер онытылмый*
*Күңелдә калган мизгелләр.*



## *Хәтер*

Еракта, еллар артында
Моңаеп, еламсырап,
Үткәннәргә үпкә сымак
Бер малай карап тора.

Ул сугыш өермәсендә
Этисез калган малай,
Бәрәкәт качкан табында
Иписез калган малай.

Ничекләр итеп юатыйм,
Нинди сүз әйтим аяп;
Кызларга күз төшәр чакта,
Бичарам — яланаяк.

Чакырам аны янымa,
Чакырам бүгенемә:
— Туңгансың, әйдә, җылын, — дим, —
Ни хөрмәт куйыйм сиңа?!

Әйдәле, җитеш бәлештән,
Казыннан, йөземеннән...
(Инде ул елларның үчен
Кайтардык йөзе белән!)

Кисәң, дим, әнә чөйдәге
Киемнең затлыларын,
Кызларның иң кәттәләрен
Каратыр идең, парин...

Ул миңа карый мөлдерәп,
Тын гына еламсырап,
Бүгенге рәхәт заманга
Үпкәсе булган сымак.

Нигъмәтләр тулы табында,
Үзара дәшми бер сүз,
Малайчак белән икәүләп,
Чәй эчеп утырабыз.

## *Чорлар чатында*

Декабрьнең озын шыксыз төне —
Нидер кыса, нидер буа мине;
Сыек төтен чыга морҗалардан,
Чыкмый бугай ләкин илнең тыны.

Кышкы кичтә әкият тыңлый-тыңлый,
Сәрхуш булып ул йокыга талган;
Тик бәхеткә генә юллар ерак,
Тигән өлеш кенә — тәти ялган.

Ә апрельгә әле шундый ерак —
Кар-бураннар аша үтәсе бар,
Бозлы тәрәзәгә «күзләр» уеп,
Кояш чыгар көнне көтәсе бар.

Бу зәмһәрир суык Соловкидан,
Колымадан шулай килде мәллә?
Бар чорларның зарын ул берьюлы
Искә төшерсеннәр, диде мәллә?

Кара көздән язны сагына башлыйм
Һәм ялварам көн дә шәфкать сорап;
Ничек кичим соң шул декабрьне,
Апрельгә бит әле шундый ерак...

Ә апрельгә әле шундый ерак...

## *Атам кабере кайда — кем әйтер?!*

*Күмелми калган солдатлар язмышын ачыклау максатында «Үлем үзәне»нә экспедицияләр оештыручы фидакяр эзтабарларга багышлыйм*

Кай илләрдә ятып калды икән
Асыл сөякләре атамның?
Үги улы иде микәнни соң
Рәсәй дигән юньсез ватанның?
Яз кайтмасак, көз кайтырбыз, диеп,
Яулык болгый-болгый китте дә...
Шуннан бирле күңел заманага
«Сәер сорау» биреп интегә.
Сугыш та юк... җиңдек тә бит инде...
Һәм исәннәр алды орден да...
Тик нигә соң адәм сөякләре
Җирдә аунап ята бүген дә.
Рәнҗиләрдер каберләре юкка...
Көтәләрдер варис ирләрне...
Нинди игелексез ил соң бу ил?! —
Батырларын хәтта җирләми.
Исемсезләр, билгесезләр булып,
Миллионнар калган яуларда...
Үлгәннәргә кабер һәм кадер юк —
Җиңдек диеп нигә шауларга?!
Әле ярый, рәхмәт, эзтабарлар,
Кемнәрнедер мыскыл язмыштан
Йолып алып сала каберләргә,
Намусына илнең кага чаң.
Ә Рәсәйгә ракеталар кирәк,
Кайгысы юк билгесезләрдә.
Кем тиеш соң чиксез киңлекләрдә
Газизләрен өзелеп эзләргә?!
Уртак каберләрне чукындырып
Ләззәт тапкан поплар эзләрме?

Еллар үтә тора — кем табар соң
Үткәннәрдә калган эзләрне?
Ә колакта чыңлый... Сорау чыңлый...
Чыңлар... чыңлар... — җанны кыйратыр.
Кай җирләрдә газиз әтиемнең
Асыл сөякләре — кем әйтер?!

## *Минем шәҗәрәм*

*(Поэма)*

### **Һәйкәл**

Урам уртасында һәйкәл тора —
Үлгәннәргә соңгы истәлек.
Салган аны авыл агайлары,
Кырык бернең җәен искәреп.
Моңсу гына карап шушы ташка
Яшь йотулар әллә җиңелме?
Таш булып таш кайчак телгә килә,
Таш түгел бит кеше күңеле.
Чытылса да кайчак нурлы йөзләр,
Таш түгел бит безнең бәгырьләр;
Ул һәйкәлнең тирән тамырлары —
Европада калган каберләр.
Тантаналы тынлык сарган аны —
Сагышын ул эченә яшергән.
Йөз унсигез газиз исем анда...
Өчтән бере безнең нәселдән.
Дошман явын, канлы юллар буйлап,
Көнбатышка таба куганда,
Тереләргә җанлы калкан булып
Ятып калган бик күп туганнар.
Алсу гөлләр җилдә тирә-юньгә
Хуш ис бөркеп талгын тирбәлә.

Нәселдәшем булган Ильяс абый
Шәһит киткән ерак илләрдә.
Гариф абый, туган илне сагынып,
Сугышларның үтеп дәһшәтен,
Кайткан да, гел элеккечә итеп,
Әй годуклар, диеп дәшә күк.
Кемне генә искә төшерсәм дә,
Әрнү булып баса юлыма.
Нәселем агачының ботаклары
Ботарланган сугыш елында.
Бәхтиярым сәерсенеп карый —
Аңа бабай тиеш кеше дә
Кайта алмады туган якларына,
Янып калды утлар эчендә.
Ике буын (гүя чылбыр өзек!)
Берсен берсе күреп белмәде,
Оныгының, бабай, дигәне юк,
Бабасының, улым, дигәне.
Күпме ләгънәт, күпме каргыш сүзен,
Күпме ачыну, күпме күз яшен
Эченә җыйнап тып-тын басып тора —
Туган якның изге ак ташы
Урам уртасында ялгыз тора.
Үлгәннәргә соңгы истәлек —
Һәйкәл салган авыл агайлары,
Җиңеп кайткан елны искәреп.
Зур исемлек анда.
Утлы юллар
Тезелеп киткән тәртип-җай белән,
Миһербансыз көндәлеге сыман
Һәрбер йортта йөргән кайгының.
Сагайгандай
Тора тып-тын гына,
Уйдан кичереп илләр шаулавын,
Шөбһәләнеп тавышын тыңлый сыман,
Еракларда биргән яуларның.

## Әтием истәлеге

Нигә моңсу әле җырның башы?
Аһ-зарларым юкка түгелме?
Югалту һәм юксынулар хисе
Гомер буе борчыр күңелне.
Моңайтырга түгел исәпләрем,
Әрнетсә дә бу җыр күңелне,
Олы сүз алдыннан үлгәннәрне
Санлау әллә кирәк түгелме?!

Ата-бабаларны хөрмәт итү,
Өлкәннәрдән алу фатиха
Борынгыдан күркәм гадәт булып
Яшәп килә безнең халыкта.
Нәсел-нәсәпсез бер ир дә тумый,
Тик оныта аны кайберәү;
Белми алар җирдә бар икәнен
Бар нәрсәдән кыйммәт әйберләр.
Ә аталар узган данлы юллар
Бүгенгегә килеп тоташкан —
Алар каны хәзер безгә күчкән,
Җир нур җыйган кебек кояштан.
Халык хәтерендә бүгенгедәй
Исән алар,
Исән,
Абайла,
Һәйкәл яннарында сүз башланса,
Шул елларны сөйли агайлар.
Алар сөйли...
Колагымда минем
Габдулла абый әйткән сүз чыңлый:
«Әхмәт энем, укыдың-укыдың инде,
Атаң хәтле әле булдыңмы?
Ай-һай, башлы иде Габделәхәт,
Булмаса да диплом-фәләне,
Шул дүрт сыйныф белем белән дә ул
Аңлый иде дөнья хәлләрен».

Ул давыллы еллар канатында
Югарыга менгән, яңага.
Егермебишменче Зыятдиннар
Дус һәм сердәш булган аңарга.
Ул финагент булган,
Эшен белгән,
Оста ачкан байлар ялганын;
Кызык итеп сөйли авыл халкы
Бер комсызга налог салганын.
Сарык тиресе япкан бүре сыман,
Бөеренә яшереп ачуын,
Ул ялагай, мескен чырай белән,
Сельсоветка килгән баш иеп.
— Артык түләр хәлем юк, ди икән —
(Заманалар авыр, янәсе) —
Тагын күпме налог?..
Әти исә:
— Двадцать пять, — дигән кырт кисеп.
— Син бигрәк инде, Габделәхәт...
Туган телне онытып барасың.
Бер мөселман белән икенчесе
Русча сөйләү ничек ярасын...
— Ә, алаймы?..
Ә соң теге елны,
Становой тентеп бар йортны
Недоимка җыеп йөргән чакта,
Туган телне нишләп оныттың?..
Гаепсезгә ярлы-ябагайны
Тал чыбыгы белән суктырдың.
«Ничә тапкыр сугыйк?» — дип сорагач,
«Двадцать пять!» — диеп утырдың.
Татарчаны белми идеңмени?
Син онытсаң, безнең хәтер шәп.
Дөнья куласа ул,
Әйләнә дә баса...
Менә «опять двадцать пять!»

...Исемен әйтеп тормыйм, ярар инде,
Туганнары рәнҗер, дус-ише —
Ул атаклы Чүти карагына —
Шәкүр картка кардәш тиешле.

...Аннан сугыш.
Ул фронтка киткән.
Ачуы килеп еллар авырга,
Өлгермәгән йорты матчасына
Сүгенү сүзе язып калдырган.
Сагына идек аны өчәүләп без —
Аз килде шул сәлам хатлары,
Әллә кайтыр юлын кар каплады,
Әллә язар вакыт тапмады.
Кызу чак иде шул.
Ил кырлары
Кургаш белән тулган чак иде.
Сугыш учагында яшь гомерләр —
Алсу гөлләр сулган чак иде.

## Медаль

Мин хәтерлим әле ил халкына
Сөенеч алып килгән ул язны.
Әтиләре кайтты кемнәрнеңдер,
Ә без алдык кайгы кәгазе.
Ә без алдык кара пичәт белән
Тамгаланган хәбәр һәм...
аның
Командиры истәлеккә салган
«За отвагу» дигән медален.
Әллә балачакның мавыгуын
Даулы еллар җиле урлады,
Тик медальне күкрәгемә тагып
Мактанырга насыйп булмады.

Карамыйча йөрәк ай-һаена,
Сыйланырга теләп чак кына,
Бирдем аны күрше малаена
Ярты сынык икмәк хакына.
Аның атасының медале юк —
Таксын әйдә.
Күрсен игелек...
Һәм еладым аннан үксеп-үксеп,
Кимсенүле иде күңел бик.
Нәни рәхәтләрен балачакның
Икмәк белән алдап саттырган
Усал еллар һаман эзен саклый
Бүгенгәчә чыкмый хәтердән.
Мин ашамый калган шул бер сынык
Фашист башына, бәлки, җиткәндер.
Ир-ат исемем белән шәҗәрәмне
Алга таба дәвам иткәнмен.

## Өзек чылбыр

Авыл уртасында һәйкәл тора —
Исем арты исем тезелгән;
Дәвамы юк инде күпләренең —
Шәҗәрәләр тәмам өзелгән.
Бердәнбер ир бала булганнар да
Кайсы кая китеп югалган.
Ә аларның туган туфрагында
Нәселен дәвам итәр кем калган?!
Әй сибелгән Чәчкап, әй сибелгән —
Җилдә тузган чәчәк шикелле.
Чит-ят җирдә яшәп нәсел җебен
Саклаулары, ай-һай, икеле.
Кайсын туган җирдән ачлык куган,
Кайберләрен авыл каргаган...
Үксез йортлар... Салам түбәләрне
Тараган да җилләр, тараган.

Кемдер күмер чапкан шахталарда —
Кайберләрен шунда таш баскан,
Уран базларында руда чукып,
Ерак кыйтгаларда адашкан.
Сәер инде — хәзер кемнәрнеңдер
Малайлары Иван исемле,
Казакъ, кыргыз, үзбәк, яһүдтән дә
Әллә татар туган дисеңме?!
И бу безнең язмыш! Ачы язмыш
Никтер артык каты каныккан;
Хәтәр җирдә һаман татар булган —
Күпме корбан безнең халыктан.
Утызынчы еллар өермәсе
Тими үтте, дисең, кемнәргә;
Иртәгәдән килен булыр кызлар
Елап чыккан шыксыз төннәрдә:
— Ишегалдым гына сары салам,
Сараема сибереп саламын.
Сөеп йөргән ярым Себер киткәч,
Тилмереп лә карап каламын.
...Сөрелделәр, яманатлар алып,
Ил терәге булган ир-атлар.
Сез әйтегез миңа: ул затларның
Нәсел дәвамлылыгын кем саклар?!
Еллар кичкәч, җылы җилләр искәч,
Аклап маташудан ни файда?!
Каберләре бармы ул ирләрнең —
Юкка чыккан кайчан, ник, кайда?!
Ике мәчет иде авылыбызда —
Күңелләргә инде изгелек;
Мин хәтерлим әле мәчетләрнең
Манарасыз калган мизгелен.
Ике мәхәлләдән ике туган —
Мортазиннар читтә үлделәр.
Бер гаепсез. Гәрчә икесе дә
Ярлыдан да ярлы иделәр.

Иман бар да, ләкин имана юк —
Асрап булмый хәтта сарык та...
Бөтен керем — аз-маз садакадан —
Ни аласың гидай халыктан.
НКВД зинданнары илнең
Ак уйларын йота торганда,
Мулла Ибраһимның карт карчыгы
Хәер эстәп йөрде урамда.
Иман уты сүнгән дәһри заман
Әй таптады илне, таптады;
Мәчет манарасын кисүчеләр
Сугыштан ук кире кайтмады.
И хикмәти Хода! Каргышлары
Төште мәллә авыл халкының?!
Хәер, алай дисәң, беркемне дә
Аямаган сугыш ялкыны.
Һәйкәлдәге озын исемлектә
Аларга да урын бирелгән;
Гөнаһларын алар юган инде —
Яман сүзләр төшәр бер телдән.
Авыл уртасында яңа мәчет —
Ярлыкасын Алла һәркемне;
Намаз вакытында шәһитләргә
Дога кыла авыл һәр көнне.

## Нәсел агачы

Без бер бүген тумаганбыз,
Әле кешелекнең таңында
Бүгенгене көтеп яшәгәнбез
Бабайларның ерак канында.
Алар дәрте безнең җилекләргә,
Алар акылы безнең миләргә,
Гасыр фильтрларын үтә-үтә,
Тормыш өчен куәт җибәргән.

Алар алган яра бездә юк, дип,
Тарихчылар борчак сибәләр!
Бер дуслашып, янә дошманлашып,
Буталганнар тел вә шивәләр.
Яшәү өчен көрәш аяусыз ул,
Андый чакта инде, билгеле,
Әлләниләр була,
шуңа күрә
Бик томанлы кемнең кемлеге.
Ерак бабам, белмим, юлыкканмы
Сарматларга[1] яки һуннарга[2]?
Һәвәс булгандырмы һөнәрләргә,
Оста булгандырмы сунарга?
Мин белмимен, ерак бабамнарны
Күргәндерме Мәхмүд Кашгари[3],
Орхон-Енисейда[4] ятадырмы
Чөй язулы кабер ташлары.
Шәҗәрәмнең башын башлаганда,
Кандашларны күңел сагына.
Аспарухка[5] батыр җайдак булып
Китмәгән ул Дунай ягына.
Идел-Чулман илен ватан итеп,

---

[1] Сарматлар — безнең эрага кадәр алтынчы гасырдан башлап Идел һәм Урал тирәсендәге далаларда яшәгән һәм фарсы телендә сөйләшкән кабиләләр.

[2] Һуннар — башта Үзәк Азиядә, Хуанхэ елгасыннан төньяк-көнбатыштарак яшәп, соңрак «Халыкларның бөек күченүе» вакытында Рим биләмәләренең көнчыгышын басып алган күчмә халыклар.

[3] Мәхмүд Кашгари — унберенче гасырда төрки сүзлеген төзегән галим.

[4] Орхон-Енисей — Монголия, Себер һәм Җидесу төбәкләрендә яшәгән төрки халыкларның язма истәлекләре турында сүз бара.

[5] Аспарух — җиденче гасырда Азов буенда яшәгән болгар кабиләләренең бер өлешен Дунай елгасына таба алып киткән һәм анда дәүләт төзегән хан.

Тарих итеп яңа елларны,
Алар пайтәхетебез булсын диеп,
Нигезен салган Бөек Болгарның.
Мин белмимен, ерак бабаларым
Колдан тугандырмы, бидәнме,
Кәрван башы булып йөргәндерме,
Ауда ханга шоңкар чөйгәнме?
Ак сөякме бездә, зәңгәр канмы,
Затлымы без, әллә тупасмы —
Анысы ачык түгел, ачылса да,
Элитага ярап булмастыр.
Болгавыр чор барын буташтырган —
Кемдер көрәк булган сәнәктән;
Һәммә адәмнән дә өстенлекне
Дәгъва итмим нәкъ шул сәбәптән.
Идел-Йортта туган бабамнарның
Уникесе миңа билгеле;
Гасыр арты гасыр уза торган —
Безнең ватан булган Гөл иле.
Әзгәриләр суккан Әтрәч[1] аша
Иравыллар[2] булып бу якка,
Килгән алар Кайбыч тирәсеннән,
Һөнәрчеләр авылы Чәчкаптан[3].
Яңа Чәчкап[4] авылы шулай туган.
Иген иккән монда бил бөгеп,
Кылый, Бүре, Мыек кушаматлы
Әзмәвердәй таза өч егет.

---

[1] Әтрәч — Тәтеш районындагы бер авыл. Тарихи мәгълүматларга караганда, биредә шәһәрчек булган һәм анда әзгәри дип йөртелгән озынча көмеш тәңкәләр сугылган.

[2] Иравыл — гаскәрнең алды, авангарды.

[3] Кайбыч районындагы Иске Чәчкап дип йөртелгән бу авылның исеменнән күренгәнчә, анда хатын-кыз бизәнү әйберләре эшләп чыгарганнар булса кирәк. Башка төрле фаразлар да бар.

[4] Хәзерге Буа районының Яңа Чәчкап авылы күздә тотыла.

Миңа Мыек Йөркәй баба тиеш —
Шәҗәрәмнең ул иң түрендә.
Аннан соңгы буын аралары
Артык сирәк булып күренә.
Гаҗәп түгел ара ерак булса,
Сирәк туган булса ир-уллар;
Безнең бабайларга килен бирми
Йөдәткәннәр күрше авыллар.
Йөркәй Мыекның да ятим йорты
Озак еллар буе буш торган.
Улы тугач исә, аңа сәер
Чуртый дигән исем куштырган.
Ә анысы, санлап шәҗәрәсен,
Үрнәк алып газиз атадан,
Чура батыр кебек булсын диптер,
Улын Чурай диеп атаган.
Аннан — Бикмәт,
Аннан — Ишмәт туган.
Катлаулана барган замана;
Туры килгән иген игәргә дә,
Аннан торып яуга чабарга.
Бикмөхәммәт улы Ишмөхәммәт,
Ишмөхәммәт улы Вәлиша
Кылычын, гөрзиләрен әзер тоткан,
Язмышына карыша-карыша.
Нинди давыл дулап үтмәгән дә,
Нинди җилләр улап исмәгән,
Ләкин авылым үзбаш булып калган,
Нәсел-ыру һаман ишәйгән.
Танысаң да хәләл икмәк тәмен,
Томананы китап мактамый,
Белем кирәк илгә,
Белем — нур, дип,
Мәдрәсәсен ачкан, мәктәбен.
Дөньяви фән анда булмаган да,
Бирелмәгән дә бит зур исем,

Тик әлифне таяк диеп белгән
Бабамнарны ничек хурлыйм соң?!
Кол Гали дә безнең дипломсыз бит —
Тик ул язган «Йосыф китабы»
Күңелләрдән күңелләргә сеңеп,
Гасырларны ерып үтә алды.
...Ераклардан килә таныш аваз,
Колагымда чыңлый моңлы саз:
«Кара гына ур-ма-а-ан,
ка-а-раң-гы-ы тө-ө-өн...»
Кылганнарга кагылып йөгерә яз.
Тапкыр сүзле бабам Бәхтияр ул,
Өне килә сыман үткәннән;
Күңелләргә ак нур өстәсен дип,
Юллар аны читкә илткәннәр.
Бөктәрдәге бәет, дастаннарга
Думбыралар чыңы кушылган;
Арык атын илгә куа-куа,
Ул язмышын уйлап пошынган.
Кайтасы иде тизрәк туган якка —
Җир куены орлык сорыйдыр;
Ил картлары намаз арасында
Бәрәкәтле еллар юрыйдыр.
Ара-тала кыргыз даласына
Барып чыкты икән нилектән?
Чөнки безнең Акмуллалы халык
Бәйнәлмиләл элек-электән.
Пугачевлар чорын искә төшер
Һәм телгә ал батыр Канкайны.
Бабайларның булат кылычлары,
Хөрлек даулап, байтак айкалды.
...Читкә киттем, ахры, сүз җаеннан,
Эзгә кире кайтыйк —
Ярый соң!
Хәер, шәҗәрәңне ничек инде
Илдән, көннән аерып карыйсың.

Ир язмышы — ил язмышы икән,
Тарихны да санлау кирәктер.
Башкаларга әйбәт сабак булыр —
Туар буыннарга өйрәтер.
Бәхтиярдан туган Батырша да,
Батыршадан туган Гаделша
Бабалардан күчкән акыл белән
Яшәгәннәр хәле-хәленчә.
Аннан васыяте итеп аны —
Бабасы һәм үзе белгәнне
Улларына биргән...
Менә шулай
Алга илткән тормыш җилкәне.
Гаделшадан туган Габдерәшит —
Соңгы бабай безгә —
һәм шуңа
(Хәзер инде бераз кыскартылып)
Фамилия безнең буынга.
Кабере аның ерак туган җирдән.
Язмыш кагып, читкә этәргәч,
Унҗидедә,
Башкаларга кушылып,
Патшаларга күсәк күтәргән.
Питер шаһит аның язмышына —
Сайлаган ул авыр юлларны,
Ә авылда сагынып
Еллар буе
Көткән аны ятим уллары.
Каюм абыем көткән...
Әтием көткән...
Ул кайтмаган...
Янган давылда;
Ике ир һәм ике имән үскән
Аңа дәвам булып авылда.
...Урам уртасында һәйкәл тора —
Үлгәннәргә соңгы истәлек,

Салган аны авыл агайлары
Кырык бернең җәен искәреп.
Йөз унсигез газиз исем анда...
Сагыш саркый һәрбер юлыннан.
Нәселем агачының ботаклары
Ботарланган сугыш чорында.
Зур агачның кайбер үрентесен
Куырса да еллар кыравы,
Илгә баһадирдай ир бирерлек
Исән калган нәсел-ыруым.

## Төш

Мин әтине төштә күрдем бүген —
Яшел чирәм, имеш, өй алды.
Кырыс кына сорау бирә әти:
— Кая куйдың минем медальне?..
Мин үзем дә әле такканым юк,
Һәм булмады хәтта күргән дә...
Сугыш каты иде — аны миңа
Үзем һәлак булгач биргәннәр...
И әтием, нишлим, ач идем шул...
Бик кайгыра идек син юкка;
Еллар авыр булгач, син булмагач,
Интектек бит тәгам-ризыкка.
Ачуланма инде, әти җаным, —
Бик «шикарный» туның бар иде;
Бирдек аны бер пот бәрәңгегә —
Ач үлмәскә шул да ярады.
Ә беркөнне әни дәшеп алды,
Йомшак кына әйтте, җай гына:
— Әллә, улым, барып кайтасыңмы
Соранырга чуаш авылына...
Анда, улым, сине кем дә белми,
Кем дә булса үртәп торамы?

Әнә мулла бабаң карчыгы да
Йорттан йортка йөри сораныш.
Шулчак үксеп елап җибәрдем мин —
Кимсенүле иде күңелем.
Күз яшьләрем, борчак-борчак булып,
Әни итәгенә түгелде.
Ачуланмый гына башым сыйпап:
— И, елама, — диде, — түз генә...
Ничек тә бер Ходай бирер әле...
Елый иде әни үзе дә.
Исән калсын өчен мин һәм сеңелем
Авызыннан өзеп бирде ул.
Түзде әни, тешен кысып түзде —
Гомер күрмәгәнне күрде шул.
Җиңү көне инде килде, дигәч,
Бер елмаер, дигәч, көн аңа,
Сугыш чорындагы газаплардан
Китеп барды теге дөньяга...

## Киләчәккә карый замана

Кичте баштан ачлык, авырулар,
Кичте баштан хәтәр чорлары,
Ил табыны бүген бәрәкәтле,
Ил түрендә шатлык җырлары.
Нәселем корый диеп сукранмыйм мин,
Юк, бирелмим мескен хисләргә:
Йөз илле йорт идек сугышкача,
Хәзер тагын йөзләп өстәлгән.
Кырларыма чыксам — тургай җыры.
Көләч басуларга моң сирпеп,
Ул сөенә, ул елмая төсле...
Күр, бу кырлар нинди киң, иркен!
Тургай елмайганга ил елмая,
Ил елмайса, ирләр шатлана,

Илгә яңа баһадирлар үсә,
Баш бирмәслек булып ятларга.
Гасырларны иңләп атлап киләм,
Үлми,
Сүнми,
Армый,
Ялыкмый.
Бабамнарны барлыйм.
Мин — бер улы
Татар дигән батыр халыкның.
Без — Тукайлы,
Без — Җәлилле халык;
Тарихыбыз меңәр еллардан
Дөнья алдында йөзне кызартмаган.
Мәйданнарга батыр чыгарган.
Авылым минем — илнең бер терәге,
Бердәм атлый кешелек язына;
Кичәгесе, бүген, иртәгәсе
Олы язмыш булып языла.
Еллар кичә,
Ирләр үсә тора —
Тарих дәвам итә һаман да;
Малайларның ал хыялы аша
Киләчәккә карый замана.

## *Илаһи моң булып...*

### *(Цикл)*

### 1

Чәч кабымы, Чәчкә биме
Исем булган авылга;
Ахыр чиктә харитага
Чәчкап диеп язылган.
Кемдер әйтә, Чәчкә атлы
Бер бидән башланган, ди,
Кемдер әйтә, калфак сымак
Чәч кабы ясалган, ди.
Бәхәсләшә ике фикер —
Телчеләр, тарихчылар...
Бәхәсләрнең очы — белмим —
Нәрсәгә барып чыгар?!
Харитада ике Чәчкап —
Искесе бар, Яңасы;
Кайбыч ягындагысы бар,
Буанықын санасы.
Юк, шәҗәрә юктан гына
Ерактан тезелмәгән —
Авылдан авыл бүленеп,
Аралар өзелмәгән.
Менә ничә йөз елдан соң
Серләрен ачып булды —
Борынгы Чәчкапта мәчет
Ачарга насыйп булды.
Очрашуда сүзләр китте
Нәсел-ыру хакында;
Бабаларым бабай икән
Һәм бу яклар халкына.
Чәч кабымы, Чәчкә биме —
Башлангычы авылның?!

Пыр туздырган бар нәрсәне
Заманалар давылы.
Әйе, булган Чәчкә би дә —
Ил бәладә чагында,
Дусларын җыйнап карышкан
Ул Грозный явына.
Бу тарихлар күптән үткән —
Анда түгел бәхәсем...
Чәчкап исемен Чәчкап алган
Һәм иманын саклап калган,
Татар угылы татар туган —
Шәҗәрәгә дәвам булган...
Шунысы алтын бәһасе!

2

Кай яклары белән гүзәлдер ул,
Ни тылсымы белән тартадыр;
Туфрагына аяк басу белән,
Күкрәкләрдә куәт артадыр.
Булмаса да калын урманнары,
Булмаса да биек таулары,
Илаһи моң булып чакырып тора
Кырларында иген шаулавы.
Бу җирләргә башлап аяк баскан
Бабайларны барлыйм кай ара —
Шәҗәрәләр серен чишә-чишә,
Әллә нинди уйлар яңара.
Заманалар белән бәхәсләшеп,
Иманнарын саклап күңелдә,
Язмышларның яңа сәхифәсен
Сырлап язган алар биредә.
Саклап калган алар Чәчкап исемен,
Яңа диеп кенә өстәгән,
Шөкер итеп Ходай биргәненә
Бүтән җиргә кабат күчмәгән.

Үсмәсә дә хөрмә агачлары,
Тисә дә җил-суык үзәккә,
Ни өчендер сап-сай елганы һәм
Япан кырны алар үз иткән.
Ата-бабам тире тамган җирләр
Тылсым булып шуңа тартадыр,
Бәрәкәтле туфрак тудырган мул
Икмәкләрдән куәт артадыр.
Чакырадыр айлы манарасы —
Бу чорларны ул да сагынган;
Читтә йөреп кайткан якташларны
Көтә һаман сыйлы табыннар.
Кем булсаң да ерак тарафларда,
Син барыбер ятим диярлек;
Гомер биргән өчен генә дә бит
Туган җиргә башлар иярлек.
Җанга якын изге шул туфракта
Аунап үскән авыл баласы
Хыялланып яши.
Килми аның
Заманадан артта каласы.
Атар таңнар матур булсын өчен
Туплап бергә бар көч, бар рухын
Варисларга атап яза алар
Яңа Чәчкап авылы тарихын.

3

Саумы, мәктәп! Ятим көннәремдә
Син атам да идең, анам да...
Урый-урый ерак дөньяларны,
Сиңа кайттым әле яңадан.
Сиңа кайттым — балачакка кайттым,
Инде язмыш кырыс түгел дә,
Тик нигә соң, нигә бу мизгелдә
Мөлдерәмә сагыш күңелдә?!

Бу — үткәнне шулай сагынумы?!
Бу — үткәннән шулай качумы?! —
Анысын белмим. Әмма туган мәктәп
Өр-яңадан бүген ачылды.
Кыңгыраулы мәктәп елларының
Истәлеге истә һаман да;
Элеккечә тик укучы булып
Кайтыйм әле үткән заманга.
Искә алыйм әле бөтенесен —
Укытучыларны, дусларны,
Беренче кат алган «5» леләрне,
Беренче кат сөйгән кызларны.
Укытучылардан гафу сорыйм —
Кадерләрен белә алмадык;
Шаярыштык дәрес вакытында —
Әй ул безнең бала-чагалык!
Еллар үткән — тормыш инде бүтән,
«Заграничный» кием өс-башта.
Ә без укыганда «Әлифба» да
Бирәү генә иде класска.
Без корымнан кара ясый идек,
Каурый каләм булды кулларда,
Ә шулай да тырышып укый идек,
Рәнҗемичә авыр елларга.
Сезгә инде — безнең дәвамнарга
Истәлекле көндә ни дисе?..
Сезгә инде «5»кә генә түгел,
Хәтта «6»лыга укыйсы.
Мәктәбебез — безнең язмышларның
Гомер тутыкмаслык көзгесе.
Ә бу очрашуда теләкләрнең
Барчагызга иң-иң изгесе.
Мәктәбебез — һаман күңелләрдә,
Рәхмәт сүзең җитмәс әйтергә;
Язсын Ходай, очар кошлар кебек,
Тагын-тагын сиңа кайтырга.

4

Чәчкап белән Норлат арасында
Такыр микән юллар, юк микән?
Күрше авылдагы чибәр кызның
Биргән вәгъдәләре нык микән?
Юлга чыга егет, ә ул миңа
Тиздән, тиздән әти булыр зат,
Әни булыр ул кыз, аны көтеп,
Юлны күзләгәндер ничә кат.
Туйлар узган — туннар тузмаса да,
Тузаннары юлның тузмаган,
Бәхет тапкан ике күңел никтер
Афәт киләсене сизмәгән.
«Сугыш» дигән коточкыч сүз шулай
Сызып аткан язмыш биргәнен;
Мин ул чакта инде урамнарда
Чатыр-чатыр чабып йөргәнмен.
Сеңелем исә төшеп бишегеннән
Тәпи-тәпи йөреп киткәндер;
Безгә тиеш рәхәт тормыш кына
Шул каһәрле көндә беткәндер.
Әти дә юк инде, әни дә юк —
Икесен дә сугыш ялмады;
Безне «ятимнәр» дип кимсетсә дә,
Зарыбызга колак салмады.
Җитәкләшеп үттек ике сабый
Чәчкап белән Норлат арасын,
Мөлдерәмә яшьле күзләр генә
Сөйли иде йөрәк ярасын.
Ә яшәргә кирәк иде безгә,
Барча үлемнәргә үч итеп —
Үрләдек без тормыш чоңгылыннан,
Белмим, белмим, нинди көч җитеп.
Инде тауның түбәсенә җиттек —
Хыял чынга ашты дигәндә,

Сеңелкәем — бердәнберем генә
Китеп барды җирдән... түбәнгә.
Кара кабер каерып алды аны —
Юкка чыкты соңгы таяныч;
Хәйран калам — ничек түзелгәндер! —
Бер йөрәккә күпме хәсрәт ич.
Өчесе дә утыз ике яшьтә —
Серле бу сан сөйлиниләр дип;
Бер кешенең яшәр гомерен дә
Өч кешегә бүлеп биргән бит.
Әти белән әни яшәгәнне
Кичтем бугай — инде ни дисең?!
Хәзер исә, дөньяга үч итеп,
Сеңелем өчен калган яшисем.
Чәчкап белән Норлат арасында
Такыр юлда торам уйланып.
Язмыш, язмыш, нигә рәнҗеттең син,
Бу йөрәккә сагыш-моң салып?!
Ул бит әле һаман кичергәннән
Күчә алмый тора — чара юк;
Уяна да хәтер, шәүлә булып,
Күзләремә карый ялгызлык.
Дәва эзләп йөрәк ярасына,
Хәер-дога кылып барысына,
Әти белән әни тора сыман
Шушы ике авыл арасында.

## *Җанга якын Норлатым*

Ямьле авыл безнең Норлат,
Чишмәләре ага җырлап
Таллыклар арасыннан;
Егетләрнең йөрәгенә
Ут кабына яшь кызларның
Назлы күз карашыннан.

Җирең юмарт, җилең җылы,
Табыннарың һәрчак тулы —
Кунаклар күреп китсен;
Туган ягым, и Норлатым,
Гомер буе җанга якын
Бәллүр бишегем бит син.

Язлар саен сабан туе,
Гөрли бәйрәм көннәр буе
Киң мәйданнар түрендә;
Бил алышыр батырлар бар,
Сөлге чигәр матурлар бар
Безнең Норлат җирендә.

Кайда торса да мактала,
Кая барса да дан ала
Норлатта туган ирләр;
Җырлыйбыз шуңа шатланып,
Илкүләм матур ат алып
Яшәсен туган җирләр.

## *Карт өянке*

Әйа, йыгач, яшең күпме?..

*Г.Кандалый*

Исәнме, йөзьяшәр өянке, исәнме,
Җилләр соң рәнҗетеп йә назлап исәме?!
Ә минем йөрәккә кирт булып уелган
Боегып яшәгән ул еллар исәбе.

Син минем әнинең яшьлеген күргәнсең,
Син аны әтигә кияүгә биргәнсең;
Бердәнбер шаһит син ул туйга Норлатта —
Сөйлисең шул хакта елап та, җырлап та.

Әти дә, әни дә күптәннән юк инде —
Тәннәре күптәннән туфракка төренде;
Күптәннән гөл үсте каберләр өстендә,
Хәсрәтле ул еллар башлардан кичте дә.

Еш килә идем мин син үскән бу җиргә —
Күңелләр тулганда, еладык гел бергә;
Иң ачы күз яшем шушында төшкәндер —
Тамырлар буенча кәүсәңә күчкәндер.

Елама, өянке, ул еллар еракта —
Яралар төзәлми... төзәлмәс елап та...
Нык булыйк, нык торыйк — башкача ярамый,
Үскәнбез бит әле, җилләргә карамый.

Исән бул, йөзьяшәр өянке, исән бул —
Тимәсен, кисәм дип, кәүсәңә усал кул.
Синнән гел таңнарда яфраклар җырында
Сөйләнсен бәхетле язмышлар турында.

## *Билгесез партизан кабере*

*(Поэма)*

### I

Юл буенда чардуганлы кабер,
Юл буенда ялгыз ак каен.
Ниләр сөйли алар еллар аша?
Ниләр сөйли безгә көн саен?
Мең сорауга ник бер җавап булсын,
Йә ишарә, йә ым, йә бер сүз!
Кем кабере? — исеме язылмаган,
Кай якныкы? — ул да билгесез.
Дөньяларны урап йөри торгач,
Туган якка кайтсам шул юлдан,
Бөдрәләрен сузып каен миңа:
«Җирдәниләр бар соң?» — ди сыман.
Җир хәтере булып тамырлары
Теге дөньяларга тоташкан;
Һәй, катлаулы тарих катламнары —
Ахыргача серен кем ачкан?!
Ә шулай да моннан узганда син
Заманнарның моңын, гамен сиз;
Гади ташта бары дүрт гади сүз:
«Рәхмәт сиңа, иптәш билгесез!»
Каберләрнең күрдем һәйкәллесен,
Пантеонын күрдем, курганын...
Тик күрмәдем арыш басуында
Ялгыз каен булып торганын.
Бәрәкәтле, тыныч еллар өчен
Рәхмәт әйтеп җиргә, кояшка,
Бар җилләргә каршы күкрәк ачып
Басып тора бугай бу таш та.
Ә дөньялар — киерелгән җәя,
Ә хәтерләр — уяу чакматаш.

Үткәннәрнең изге васыяте
Кыйтгаларда һаман — сак маташ!
Юл буенда миллионнарның берсе —
Ялгыз кабер...
Ялгыз ак каен...
Ниләр сөйли алар еллар аша?
Ниләр сөйли безгә көн саен?

## II

— Тәгәри лә китте, әй йомгагым —
Серле йомгак булып үткәнгә...
Очы кайда безнең гомерләрнең?
— Күптән инде, балам, күптәннән.
Бик күптәннән...
Әле ул чак син юк...
Бала иде әле атаң да...
Елын хәтерләмим —
Унсигезме,
Унтугызмы шунда?! —
Бер таңда
(Көтмәгәндә, уйламаганда бит!)
Шул ак чехлар керде авылга...
Янгын чыкканмыни! — сикереп тордык,
Малай-шалай чаптык зур юлга.
Мылтык-кылыч күргән халыкмы без,
Белгәнебез — абзар, кыр, урман...
Атлар килә атлап, туплар килә —
Мәхшәр көне төсле бар урам.
Юкка гына әйтмәгәннәр инде
«Томана» дип, безнең якларны.
Авыз ачып гаскәр каршылыйбыз —
Кызыллар ни безгә, аклар ни?!
Ярар. Күрдек. Әзрәк тынычландык.
Өйлә вакыты җиткәч...

Җан-фәрман
Атлы казак оран салып үтте:
— Собираться всем на ма-ай-да-ан!
Җыелдылар. Җыелмыйча кара!
Күндәмлеккә халык күнеккән;
Сарык көтүе кук таптанабыз,
Күзләр түбән, һәркем бил бөккән.
Аргы очтан ике атлы чыкты —
Күз ачкысыз тузан эченнән
Бер адәмне сөйрәп китерделәр...
— Кем?.. Кем?.. — диләр, —
кемен кем белгән?!
Кием ертык, үзе канга баткан —
Чыраена түгел карарлык...
Ак әфисәр алга чыгып басты,
Кул селтәде — имеш, зарар юк.
Вәкарь белән генә сүз башлады:
— Әфәнделәр! Сезгә сабакны
Шулай өйрәтербез...
Кызылларның
Шпионы бу йолкыш сабакы...
Безгә каршы чыккан һәр болванны
Шундый язмыш көтә...
Понятно?..
Халык гөжләп куйды.
(Төн иде бу —
Караңгы төн үтми таң атмый!)
Кибет бурасына терәтелгән
Мескен әсир, дибез, ни дәшәр.
Ул тын гына башын күтәрде дә
Әкрен генә әйтте:
— Иптәшләр!..
Аяз көнне яшен суктымыни! —
Чымырдашты тәннәр бу сүзгә...
Ак әфисәр кинәт ап-ак булды,

Нидер ырылдады һәм, кизәнеп,
Йодрык белән манды әсиргә.
Минем әти кызу канлы кеше —
Түзалмады:
— Тукта, кабахәт!..
Күрә торып кеше үтертәбез,
Бу нәрсә соң инде, җәмәгать?!
Аны кемдер тотып калды бугай —
Ахырын-соңын анда кем белгән?!
— Йә, сөйләсен инде, — диде картлар, —
Әйтеп калсын үләр алдыннан...
Әсир кеше караш йөртеп чыкты
Һәм:
— Иптәшләр! — диде. — Сез мине
Бер юлбасар диеп уйлыйсыздыр...
Ялгышканнар бары сезмени?..
Урламадым... Кеше таламадым...
Бай баесын өчен көч түктем...
Ләкин беркөн...
Безне яклый торган
Кешеләр дә барын ишеттем.
Балаларга сынык икмәк даулап,
Бәхет даулап хезмәт халкына,
Кызыл гаскәр керә ялкыннарга
Иртәгәге көннәр хакына.
Яшисе дә килә, ләкин нишлим —
Сезгә рәхәт тормыш телим шул,
Шуның өчен чыктым көрәшләргә.
Мин — партизан. Иң зур серем шул.
Ә сез... — Кинәт аны залп бүлде...
Ул нәрсәдер теләп әйтергә
Тураймакчы булды... һәм сыгылып
Барып төште шунда бер җиргә...

...Күзләр яшьле... Киттек...
Беркем дәшми...
Эчтән нидер уйлый-кичерә...
Бура турысында канлы гәүдә
Ятып калды тузан эчендә.

III

— Сезнең өчен хәзер бар да гади:
Һәркем — иптәш!
Менә ничек бит.
Ә без «иптәш» һәм «партизан»
сүзен
Беренче кат шунда ишеттек.
«Кара халык — карак сарык» идек,
Заманалар ипләп өйрәтте, —
Зәйдүк бабай авыр сулап куйды, —
Йә, булмаса берне көйрәтик!..
Ул карашын текәп басуларга
Тынып калды —
Уйлар билидер;
Ерак калган кырыс хатирәләр
Аңа әле һаман тередер.
Үзе инде җитмеш аръягында,
Хисаплашмый ләкин яшь белән;
Баштан кичкәннәрен җыерчыклар
Арасына җыеп яшергән.
Колхоз төзегән, тракторчы булган,
Фашистларга каршы сугышкан,
Ак-караны, «уң»ны-«сул»ны белгән —
Уйлы булган чөнки тумыштан.
Юл буенда үскән ак каенның
Бөдрәләрен йомшак җил тарый;

Күләгәдә йөри истәлекләр —
Үлгәннәрдән юкса кем карый?!
Хакыйкатьнең үзе, күзе булып,
Әйе, карый, карый икән шул;
Фидаиләргә дә бүгенгедән
Хисап бирү ярый икән шул.
Төш вакыты. Кояш ләззәт чигә.
Печәнчеләр ялга туктады.
Зәңгәр тынлык. Шундый рәхәт!
Җирдә
Борчу-сагыш әллә юк тамы?!
Аргы кибән ышыгыннан килә
Таныш тавыш,
Бер сын калыккан;
Агитатор иптәш Буреевның
Әйтер сүзе бардыр халыкка.
Ә без читтән генә күзәтәбез —
Күзәтәбез еллар ярыннан.
Зәйдүк бабай бик канәгать булып
Әйтеп куя:
— Үндык париннан...
Гаҗәп түгелмени:
Ул-бу булса,
Аңа килә халык — киңәшкә,
Акыл эзләп килә,
яклау эзләп...
Яраттылар үзен... килгәч тә...
...Ул чакта да печән өсте иде... —
Сизгән төсле минем уйларны,
Ул өзелгән сүзне ялгап китте:
— Хыялларга гына сыярмы?!
Кем уйлаган дөнья куласасы
Китерер дип, шушы чорларга;
Һәм шул адәм уяу часовой күк
Торыр диеп безнең кырларда.

## IV

— Төнлә шулай бик сак кына итеп —
Сизеп торам — әти уята:
«Тор әле, ди, улым, бер эш бар ди»...
Әти әйткәч инде кем ята?!
Куак ышыгына поса-поса
Киттек...
Белмим кая икәнне.
Йөрәк дөп-дөп тибә...
Абайладым
Халик абыйларга җиткәнне.
Капка төбендә үк көтә икән.
«Әйдә!» диеп әти ым какты.
Яр аслатып кына үрмәләдек.
Әти никтер тоткан пычакны.
Бура турысына килеп җиттек.
Күрәм — теге әсир гәүдәсе.
Тиз-тиз генә алып кире шылдык —
Әй, гәүдәсе бигрәк дәү дә соң!
Хәйран авыр!
Киттек су буйлатып —
Эз бутыйбыз була, янәсе;
Сизмәделәр бугай —
тирә-юнь тын,
Изрәп йоклыйлардыр һәммәсе.
Шарты, бәлки, килеп җитмәгәндер
(Хөрмәт кирәк тә бит кешегә!) —
Вакыт кысан.
Тиз-тиз генә казып
Куйдык аны кабер эченә.
Гомерендә әти беренче кат
Бисмилласыз гына сүз әйтте:
— Син, партизан иптәш, рәхмәт яусын,
Сүзең белән безне кузгаттың.

Сугыш бетәр — (Безгә нигә сугыш!)
Бу аклар һәм чехлар китәрләр...
Үпкәләмә безгә...
тыныч йокла...
Бүгеннән соң булыр иртә дә...
Йомшак булсын яткан урыннарың...
Көрәшкәнең — бөтен ил өчен...
...Печән чүмәләсе өеп аннан
Каплап куйдык кара җир өстен.
...Иртәгесен мәхшәр! Өй борынча
Тентү, допрос —
олы-кечедән.
Кыйнап, сынап, янап карадылар —
Сүз чыкмады сыңар кешедән.
...Кызылларны үзебез көтеп алдык —
Дөнья башка якка болганды;
Кайберәүләр качты аклар белән —
Ил гарипсез булмый —
Булгандыр.
Халик абый белән безнең әти
Язылдылар кызыл фронтка...
Дәшеп алып әти нәзер әйтте:
— Теге абыеңны онытма...
Төенчеген асып чыгып китте.
Шул китүдән кире кайтмады...
Ә мин аның изге васыятен
Гомер буе истә сакладым.

V

Юл буенда чардуганлы кабер,
Юл буенда ялгыз ак каен.
Ниләр сөйли алар еллар аша?
Ниләр сөйли безгә көн саен?

Тылсым эзләгәндәй текәп карыйм —
Чорлар уза йөгереп уемнан;
Нәкыш төсле гарәп хәрефләре
Тирән итеп ташка уелган.
Хәрефендәмени аның хикмәт?! —
(Бәйләнүче булган аңа да!) —
Иске дөньялардан килеп чыгып
Юл ярган бит әле яңага.
Гыйбрәт алып кичәр заманнарга,
Бергә туплап көчне, акылны,
Киләчәккә китеп барышыбыз
Билгесез бер язмыш аркылы.
Юк, билгесез түгел,
Билгелеләр
Шикелле үк ул да чор ачкан:
Каберләргә күмеп булмый торган
Якты хыял калган мираска.
Дөньяларны урап йөри торгач,
Туган якка кайтсам шул юлдан,
Бөдрә каен күзләремә текәп:
«Илдә ниләр бар соң?..» — ди сыман.

## *Вахитов мәктәбе хатирәләре*

Хәерле көн, газиз сабакташлар,
Кайттыгызмы исән-сау гына;
Без кабаттан бергә — очрашмый бит
Тау белән тик җирдә тау гына!

Кызганмаган икән язмыш безгә
Шактый гомер, саулык, кыюлык;
Без, илле ел элек аралашып,
Бүген менә тагын җыелдык.

Туксан егет һәм кыз укыдык без —
А, В һәм С булды класслар;
Кыңгыраулы мәктәп еллары гел
Эзсез уза диеп кем раслар?!

Онытмадык— гел кайткалап йөрдек
Берәм-берәм, төркем-төркем дә;
Мәктәп безгә очар канат бирде —
Оныта алмас аны беркем дә.

Онытылмас Гөлсем Галләмовна —
Шәфкатьле һәм кырыс директор;
Дөресен әйтик — усал, әмма гадел,
Гаделлектә аңа тиң юктыр.

Өстәвенә әле тарихның да
Белдек аннан күпме тылсымын,
Үзләштереп яшәү сабакларын,
Хакыйкатьнең ачтык чын-чынын.

Һәм Галимҗан абый онытылмас —
Киңәш биреп һөнәр сайларга,
Географик карта буенча ул
Йөртте безне әллә кайларда.

Рәхилә апа Дарвин тәгълиматын
Шундый ачык итеп өйрәтте,
Дөнья көтәр өчен маймыл түгел,
Кеше булу безгә кирәкне.

Математик Роза Сәләховна
Ничек тапкан диген җай-юлын,
Төшендерә иде җиңел генә
Күп буынлы Ньютон биномын.

Катыштырып «-лаш, -ләш» кушымчасын,
Искәндәров абый турында
Без, шаяннар, мәзәк сөйли идек —
Әлбәттә ки, үзе югында.

Лирик җанлы Мәрдән Мәрдәнычның
Кем үзгәрткән, дисәң, йөрәген,
Аңлаткандыр Роза Сахаповна
Физикка да шигырь кирәген.

Вера түтәй Алексеевнаны
Сагынып искә алмый кайсыбыз?!
Русча белгәч, вузга кергән чакта,
Һич булмады борчу-кайгыбыз.

Немецчәне начар аңласак та,
Ипи-тозлык белдек без аны;
«Гутен таг!» дип каршы ала идек
Валентина Михайловнаны.

Сахаб абый гаярь батырларны
Җиргә ега иде бик җиңел,
Чапса Ахилл иде, ә сикерсә —
Брумвельдән бер дә ким түгел.

Кызганыч, юк тагын Гобәй абый —
Искә алып аны җан сызар;
Коперникның үзен көнләштереп,
Эзләр иде күктән йолдызлар.

Бу мәҗлестә инде бик күпләр юк,
Дөнья шул ул — нихәл итәсең?!
Югалтулар хисе, ай-һай, авыр —
Тик йөрәкләр генә күтәрсен!

Кабатланмас шушы мизгелдә дә
Күңелләрдән китми моңсулык;
Котлыйм әле җан дустымны, дисәң,
Яки анысы, яки монысы юк.

Яшәлде шул инде, күп яшәлде —
Шатлык күрдек, кайгы кичердек;
Шуңа, дуслар, башта арабыздан
Киткәннәрне искә төшерик!

Аннан инде, йола үтәлгәчтен,
Мажор тонга күчеп тагын бер,
Үткәннәрнең әйбәт көннәрен дә
Хәтерләргә форсат табылыр.

Онытмагансыздыр, сабакташлар,
Без бит бала-чага ул чакта;
Өлгергәнлек аттестаты алдык,
Әле өлгермәгән булсак та.

Әкияттәге Камыр батыр кебек,
Кавырсыннар әле катмаган.
Без бит әле ул чак, тик сүз тыңлап,
Мисал чишкән, шигырь ятлаган.

Тик йөрмәдек борын салындырып,
Каргамадык кара язмышны,
Алдагы көн ниләр буласыны
Чөнки мәктәп үзе язышты.

Уку каты иде, шуңа күрә
Мактау булды иң-иң көчлегә,
Башка мәктәпләрнең «5»лесе дә
Тормый иде безнең «3»легә.

Кемдер инде бүген атказанган
Һәм лауреат дигән исемле,
Безнең сабакташлар арасыннан,
Микроскоп аша карасаң да,
Табалмассың юньсез кешене.

Кемдер инде бүген академик,
Юрист, табиб, шагыйрь, инженер...
Һәркайсы да, тырыш хезмәт куеп,
Шушы мәктәп тапкан энҗедер.

И, кайда сез, яшьлек елларыбыз —
Вахитовта укып йөргән чак,
Киләчәккә илтер хыялларны
Ал гөлләргә генә төргән чак?!

Без онытыр өчен борчуларны,
Шаярыша идек үзара...
Һәм мәхәббәт хаты яза идек
Күз кыздырып йөргән кызларга.

Артта инде, артта шаянлыклар,
Чик-чаманы белмәс көләчлек...
Хәзер әнә безгә күз салыгыз —
Кемдә — чал чәч, кемдә — пеләшлек.

Борын асты ярым юеш килеш
Башласак та кырыс тормышны,
Һәммәбез дә, авыр юллар үтеп,
Кеше булыр өчен тырышты.

Кыен чакта уйлар уртак иде,
Бер-беребезгә терәк булдык без...
Байтак әле тормыш сынаулары —
Бер-беребезгә кирәк булыйк без.

Кирәк булыйк, киңәш кирәккәндә,
Бәла-казаларга тарганда,
Кирәк булыйк, дуслар, кемнәрнедер
Соңгы юлга озата барганда.

Ахыргача икән — ахыргача...
Бергә булыйк, бергә кичерик.
Якалардан картлык тота, диеп,
Алай бик үк күңел төшермик.

Агарасы чәчләр агарсыннар,
Коеласы тешләр коелсын,
Ләкин бүген безгә барыбер дә
Унсигез яшь кебек тоелсын.

Без тормышны кабат башласак та,
Көч җитәр күк юлны үтәрлек;
Әйдәгез, без бөтенесе өчен
Бергәләшеп тостлар күтәрик!

---

Буа шәһәре М.Н.Вахитов исемендәге урта мәктәпнең элекке укытучылары телгә алына.

## *Тостка чакыру*

Мәҗлесебез булсын мөбарәк,
Табыныбыз тагын түгәрәк,
Җыен дуслар бергә берләшеп
Утырабыз кабат гөрләшеп.

Дуслар кирәк мондый заманда —
Еллар ябык әле һаман да,
Авыр чорны әмма үтәрбез,
Бергә-бергә тормыш күтәрбез.

Туар көннәр матур килсен дип,
Әйдәгезче, берне төшерик,
Төшерсәк тә, күңел төшермик,
Төшерсәк тә, артык исермик.

Еллар үтәр... һәм шул чагында,
Очрашканда уртак табында,
Бер тутырып тагын салырбыз,
Бу салганны искә алырбыз.

## *Сабакташлар бергә җыелгач...*

Кәефләр иллә дә шәп иде —
Шаулашып чәркәләр күтәрдек;
Шәраб та мул иде — аз эчтек,
Бары тик арыслан тотарлык.

Сөйләштек риясыз, хәйләсез —
Юнаннар әйткән сүз килде рас:
«Хакыйкать — шәрабта», — дидек без,
Латинча: *«Ин винас — веритас!»*.

*«Ин винас — веритас!»* — шулай дип
Башланды теләкләр һәм тостлар;
Сөйләшеп сүзебез бетмәде —
Җыелган иде шул җан дуслар.

Сабакташ дуслардан кемнәрдер
Бу якты дөньяда инде... юк.
Без инде — бабайлар, әбиләр...
Без инде оныклар үстердек.

Без гөрләп яшәдек — күңелгә
Бар дөнья гамьнәре сыялган.
Яшәдек җилләргә баш бирми,
Хыянәт итмичә хыялга.

Тиргәмик заманны — безгә дә
Яшьлектә шук уйлар булды хас;
Әйдәгез, хәтерлик шуларны,
Әйдәгез, *«Ин винас — веритас!..»*

## *Изге Болгар җирендә*

*(Җыр)*

Илемнең изге җире бу—
Мәңге күңелдә.
Шанлы Болгардан ник бүген
Моңнар түгелә?
Хәрабә белән хәрабә
Ниләр сөйләшә —
Ерак еллар аръягыннан
Безгә кем дәшә?

К у ш ы м т а:

Изге Болгар күңелдә гел,
Тарих сызган бормалы юл —
Ничек аны онытыйк.
Дан-шөһрәтле халкым исән,
Йөрәкләрдә ялкын исән.

Яулар үткән бу җирдән,
Шомлы җил искән.
Ни булса да, көн булган,
Әмма без исән.
Борынгы ил Болгарны
Онытмый халык;
Үткәннәрнең авазын
Тыңлый таң калып.

К у ш ы м т а.

Дәвам булып дәверләргә
Ядкарьләр калган.
Бабайларның васыяте
Хәтердә һаман.
Кол Галинең җырларын
Чыгармыйк истән.
Болгарларның дәвамы —
Татарлар исән.

К у ш ы м т а.

## *Селәү авылы бәетләре*

Селәү авылында сөлекле күл —
Бер коену анда ни тора;
Тәннәренә кунса сөлекләре,
Җилекләргә хәтле суыра.

Кешеләрне нужа дигән нәрсә
Пенза базарына китерә —
Селәү халкы авыр заманнарда
Сөлек сатып кына көн күрә.

Кемгә дәва, кемгә шифадыр да,
Кызганыч бит кеше хәле дә —
Шул чорларны искә төшерептер,
Бәетләре елый әле дә.

## *Бизнә*

*(Җыр)*

Бизнәләрне сагынып кайтасым бар —
Исләремнән чыкмый гел генә,
Истәлеге булып чәчәк ата
Тәрәз төбемдәге гөл генә.

Чишмәләре суы шундый татлы —
Зәмзәм суларыннан тәмлерәк;
Чит җирләрдә сагыш басылсын, дип,
Моңаеп ла җырлар җыр кирәк.

Бергә-бергә үскән җан дусларым
Искә алалардыр мине дә;
Очрашасы иде алар белән
Җанга якын Бизнә җирендә.

## *Карман истәлеге*

Истә икән әле, истә икән
Карман авылының зәңгәр таңы;
Каршы ала мине шаулый-шаулый,
Балачакның сихри карурманы.

Ул чордан соң күпме сулар аккан,
Ничә давыл кичкән икән баштан;
Татлы хыяллары балачакның
Тик барыбер инде чынга ашкан.

Бик күрәсем килгән иде сине —
Яшь тезелә шуңа күзләремә;
Урамнарын буйлыйм баса-баса,
Балачакның кайнар эзләренә…

Сагындыра Карман, сагындыра —
Ул гомерләр калган үткән чорда;
Мин адашкан идем урманында —
Һәм бүген дә әзер адашырга.

## *Арча читекләре*

*(Җыр)*

*Татар дәүләт җыр*
*һәм бию ансамбленә*

Кая барсак, кайда булсак,
Алкышлый безне халык,
Җырыбызга, моңыбызга
Сокланып, хәйран калып.

К у ш ы м т а:
Читегемнең бизәкләре
Ерактан көлеп тора;
Арча читекләрен кисәң,
Биисе килеп тора.

Түбәтәйләр түгәрәк лә,
Калфакларда — бизәкләр,
Арча читекләрен күрсәң,
Өзеләдер үзәкләр.

К у ш ы м т а.

Торалар гел дәшеп кенә
Безне ерак илләргә,
Сокланып кала һәммәсе
Безнең нечкә билләргә.

К у ш ы м т а.

Җырлыйбыз да, биибез дә,
Гармун кулларыбызда;
Милли моңнар сибелеп кала
Йөргән юлларыбызда.

К у ш ы м т а.

## *Республикам**

*(Җыр)*

Син — минем Татарстаным,
Ал булып атар һәр таңым,
Намусым, вөҗданым, даным,
Сөекле республикам.

Кушымта:
Табыннар мул, күңелләр хуш,
Халыкларың тату һәм дус,
Йөрәкләрдә бер изге хис,
Иркле республикам.

Бай кара алтын иле,
Киң кырлар буйлый таң җиле,
Канатлы, кояшлы, язлы
Баһадир республикам.

Кушымта.

Мең яшә, Татарстаным,
Тиң булсын җырга зур даның,
Батырлар тусыннар тагын
Бизәргә тарихыңны.

Кушымта.

Син — минем Татарстаным,
Ал булып атар һәр таңым.
Намусым, вөҗданым, даным,
Сөекле республикам.

Кушымта.

---

* Лима Кустабаева музыкасы.

## *Кайту*

Колагымда тынлык чыңлый,
Чыңлый зәңгәр тынлык;
Әллә төш бу, әллә шундый
Бер тылсымлы чынлык.

Авылыма кайтып киләм
Арыш арасыннан —
Туган кырларым сөенеп
Каршы ала сыман.

Бар башаклар тантанадан
Бермәл тынып калган;
Алар өчен юк сугышлар,
Рия, мәкер, ялган.

Бөртек булып бөреләнгән
Шатлык-сагышлары.
Тиздән уятыр аларны
Мотор тавышлары.

Ә әлегә рәхмәт әйтеп
Бу кояшлы көнгә,
Нәни тургай җирнең җырын
Күккә алып менгән.

## *Юлчыларга теләк*

Бураннарда, җилле яңгырларда,
Булмаса да кайгы-борчулар,
Бик еш кына, туган якка карап,
Озын юлга чыга юлчылар.

Ераклардан дәшеп төннәр буе
Тәрәзләрдә утлар яналар;
Читтә йөргән газиз балаларын
Сагынып көтәләрдер аналар.

Сагынып көтәләрдер сөйгән ярлар —
Вәгъдәләре һаман күңелдә;
Урап-урап яуган карлар аша
Кавышыр чаклар балкып күренә.

Матур хыяллары, монда шытып,
Башлаган саф гомер чишмәсен;
Тик бураннар юлны капламасын,
Тик каршыга җилләр исмәсен.

## *Дога*

Бу болыт җирдә туган иде,
Ул җирдә ак кар юрган иде.
Эреде, ташты, күккә ашты —
Бисмилләһир-рахманир-рәхим!

Бу орлык гүзәл чәчкә иде,
Җил аны җиргә чәчкән иде.
Көн үтте, тагын чәчкә шытты —
Бисмилләһир-рахманир-рәхим!

Бу бөркет таугa оя корды,
Бөркеттән янә бөркет туды.
Ул — ирек кошы, хозур — очу —
Бисмилләһир-рахманир-рәхим!

Бу бабай сабый бала иде,
Атадан сабак ала иде.
Оныгы туды — варис булды —
Бисмилләһир-рахманир-рәхим!

Мин күкне күзлим, җирне күзлим,
Дөньядан асыл мәгънә эзлим.
Ул нинди камил! —
Ходай гадел —
Бисмилләһир-рахманир-рәхим!

## *Ялгыз ана җыры*

*(Җыр)*

Сахраларга чыгып кошлар чөйдем,
Балаларга сәлам илтсен дип.
Артларыннан җырлар җырлап калдым,
Сагышларым барып җитсен дип.

К у ш ы м т а:
Сахраларда ефәк чатырлар,
Балаларым кайчан кайтырлар?

Балаларым йөри ят җирләрдә,
Бәхетләре генә бар микән?
Күңелләре тулы шатлык микән,
Күңелләре тулы зар микән?

К у ш ы м т а.

Төннәр буе карыйм тәрәзәгә —
Сагышымны тыңлый таң җиле.
Туган якка Киек Каз Юлыннан
Балаларым кайтыр шикелле.

К у ш ы м т а.

## *Казан*

*(Поэма)*

1

Утырам Казансу ярында,
Дулкыннар тәгәри Иделгә —
Аларның шул гамьсез җырына
Бик теләп кушылыр идем дә,
Нигәдер ямансу күңелдә.

Шуңамы керфекләр чыланган —
Югыйсә көн шундый кояшлы;
Мин бүген мең яшен тутырган
Казаным хакында сүз башлыйм —
Нигә соң тыелмый күз яшем?!

Югыйсә барабан кагарлык,
Ил күзе күрмәгән тантана!
Бу көндә һәртөрле мактаулар —
Данлаулар гына да аз аңа,
Ә җанда барыбер ут яна.

Күрче, дип юатам үземне —
Син чынын белергә зарыккан.
Бар, сораш белүче халыктан —
Җиләкле аланнар артында
Пәһлеван заводлар калыккан.

Сана да чагыштыр чорларны —
Иң якты хыяллар чынга ашкан;
Мең яшьлек элекке тын Казан
Дөньяви тизлеккә тоташкан —
Тылсымлы сандыгын кем ачкан?!

Үтте баш өстеннән очкычлар —
Эзләре аяз күк йөзендә,
Ясалган Казанның үзендә!
Боргалак фырлады аннары
Һәм күздән югалды тиз генә.

Күрегез, борынгы бабайлар,
Бу сезнең туруннар — варислар,
Куркытмый аларны ярышлар —
Акылны акылга тапкырлап,
Әнә бит җай алган бар эшләр.

Мактаныр нәрсәбез күп, диген,
Данлыклы ул, диген, дөньяда —
Йөзе ак Җир шары каршында,
Ул әзер иң җитди сынауга —
Мәдхиян кызганма син аңа.

Син үзең яшәгән йорт та бит
Шул ерак заманнар дәвамы.
Тик алар ярага — дәвамы?
Әллә соң хәтерне болгатып,
Йөрәккә кан булып савамы?

Хәтерлим беренче мәртәбә,
Эчемнән укып бар белгәнне,
Ашкынып калага килгәнне,
Балакны сызганып тезгәчә,
Казансу буенда йөргәнне.

Сай идең, сай идең ул чакта,
Кемнәрдер хәтере шикелле,
Мин дә бит дүрт диеп йөргәнмен
Икегә тапкырлап икене,
Бәясен кәтмичә һичкемнең.

Ә ярда, биектә Кремль —
Манара артында манара;
Җилкенде тынгысыз хыялың —
Инде дә күр барын, йә кара —
Әнә ич алдыңда — башкала.

И сабый, и авыл малае —
Урысча дәшәрлек юк сүзең.
Кемнәндер сорарга кыймыйча,
Адашып йөрдем мин көнозын...
Эсседә... ач килеш... берүзем...

Дөньяны күрмәгән малай шул,
Зиннәтен карыйсым килгәндер:
Кызыгып, ниләр бар икән дип,
Мәчетне эзләүдән элгәре,
Чиркәүгә сугылдым нигәдер.

Әй, малай, башыңнан сал, диләр,
Ә кызык — мин алга үрмәлим:
Һәммәсе җыр суза иделәр —
Мин юньләп берни дә күрмәдем,
Бары тик кот очып шүрләдем.

Ярлыка, и Аллам, ярлыка,
Гөнаһка батылды... гөнаһсыз;
Болай да бит инде аларны
Дөньяда бихисап җыйнасы...
Һәммәсе замана зинасы...

Гыйбадәт беткәнен көтмәстән
(Күзгә бит ак-кара күренми —
Тораташ булып тик торыйммы?!),
Кысылып көч-хәлгә чыкканда,
Ишеккә бәргәнмен борынны.

Күлмәктә кан эзе. Чепуха!
Бабайлар аны аз күргәнме?!
Хәтерлим, Казансу, ул көнне
Ничекләр каңгырап йөргәнне —
Юашлык кирәкне биргәнне.

Ә аның каравы күңелдә
Чәчәкләр күзләрен ачтылар;
«Чаян»да эшләүче абыйлар
Мин язган шигырьне бастылар —
Мине зур бәйгегә дәштеләр.

Мин — яланаяклы бер ятим
Ул чакта зур шатлык татыдым...
Һәм менә илле ел йөгәнлим
Шул Пегас аталган атымны,
Бозмыйча балачак антымны.

Үзем дә сизмәстән базганмын
Шигърият диварын шакырга —
Күңелем талына кунган моң.
Кол Гали, Сараи, «Бакырган»
Мәйданга мине дә чакырган.

Чөнки бер кузгалган куәтнең
Мөмкин хәл түгел һич туктавы.
Үткәннәр гәрчә күп нокталы,
Халкымның мирасы — кояшлы,
Ул — айлы, йолдызлы, Тукайлы.

Шуңа да адашмый бара ул,
Күзләрен текәп күк йөзенә.
Даһилар бүгенге чордан да
Варислар тапмакчы үзенә —
Дәвамчы вәзенле сүзенә.

Бар ул, бар, алда да булачак —
Милләтнең чишмәсе кипмәгән.
Үткәнне бүгенгә ялгаучы
Күперләр сүтелеп бетмәгән —
Талантлар хәзер дә күпләгән.

Утырам Казансу ярында,
Уйларым уйларга чуалган —
Йә шигырь, йә тарих сүз сорый.
Күзләрем алалмый сулардан,
Мин гыйбрәт тапмакчы шулардан.

Карасам Бишбалта ягына,
Чиркәүле Елантау күренә.
Борынгы бу татар җирендә
Ят кавем күтәргән тәреләр
Нигә соң шәһәрнең түрендә?

Нигә соң бабамнар куылган
Шул Татар бистәсе дигәнгә?
Булса да үзләре имәндәй,
Мал-мөлкәт талангач, ач көе
Көн күргән юеш җир идәндә?

Язмыштан узмыш юк, диярләр,
Фаҗига икән бит ул язмыш.
Ходаем, кодрәтең киң булмыш —
Язмышлар язылган мизгелдә
Юлларны күрсәттең ник ялгыш?

Ярларны актарып юл ярып,
(Суларның ташыган чагы шул?),
Син мәңге агарсың, Казансу,
Дулкыннар тәгәрәр туктаусыз...
Ә миңа ямансу... ямансу...

2

Актарам хәтерем дәфтәрен —
Риваять, мөнәҗәт, бәетләр...
Ышанмас ирсәләр бик күпләр,
Чакырам Ризатдин казыйны —
Сүземне тәгаен ул җөпләр.

Күтәреп гасырлар пәрдәсен,
Хыялда бер Сылу терелә —
Ул миңа томанга төренгән
Фәрештә шикелле күренә —
Искиткеч сөенеч күңелдә.

И Сылу, су алган чагында
(Кулында казаның — алтыннан),
Ялгышып аягың тайдымы,
Чишмәгә шул казан артыннан
Мәтәлеп төшмәдең чак кына.

Фаразлар тагын да бар алар —
Мин күпләр фикерен тыңладым,
Тик җаным әйткәнгә инандым —
Каланың исеме шуннандыр,
Инде дә какшамас иманым.

Юк әле тынганы бәхәснең
Ул серле атама турында —
Галимнәр теләсә нишләсен;
Теләдем бу ихлас җырымда
Әйтергә Сылу кыз турында.

Кем генә ваемсыз калыр соң —
Мәңге дә чибәр бит ул кызлар.
Үтсә дә ничәмә гасырлар,
Һәркайсы мутланып шагыйрьдән
Мәхәббәт турында җыр сорар.

Кемгә кыз, кемгә каз — галимнәр
Төрлечә юрыйлар һаман да.
Дәлилләр бик саллы булса да,
Яхшы ук түгелдер... яман да...
Мөһиме — ярасын заманга.

Булды бит — ни кушса түрәләр,
Кемнәрдер тик шуны хуплады,
Тарихи дөреслек хакына
Ашкынып көрәшкә чыкмады —
«Фәнни»ләп бер-берсен тукмады.

Борынгы хәерсез көннәрдән
Сабаклар аласы урында,
Кемнәрдер Мәскәүгә әләкләр
Яудырды кемнәрдер турында —
Шуңадыр ямансу җырым да.

Күптәнге хөсетлек, көнчелек
Өстендә иссен дип таң җиле,
Җиребез үзе үк куеныннан
Чыгарып күрсәтте дәлилне.
Югыйсә бик мөшкел хәл иде.

Катламнар астында катламнар —
Тарихның серләрен җир саклый;
Акны ак дияргә дәлилләр
Булган бит, булган бит ничаклы —
Тәңкәме, чүлмәкме, пычакмы...

Сөрткәчтен дәверләр тузанын,
Ялтырап балкыды үткәннәр;
Дошманнар юк итмәк булса да,
Халкыбыз барыбер бетмәгән —
Чөнки без бу җирдә күптәннән.

Идел-Йорт чигендә торгандыр
Кальгасы кадими елларның,
Күзәтеп үзән вә үрләрне,
Баһадир егетләр җырлаган
Болгарда ишеткән җырларны.

Казанга инде мең яшь, дибез —
Кемнеңдер эче дә пошадыр;
Татарны сөймичә сөйләсә,
Һичшиксез, уйдырма кушадыр —
Янәсе, берәрсе ышаныр.

Бар ятлар ялалар якканда,
Бәхеткә, Илбашы ир булды,
Ил аңа кадерле җир булды.
Мең карыш ялганнар өстеннән
Калыгып, ил белән бер булды.

Хәлиткеч көрәшкә чыкканда,
Акылның юлдашы — йөрәктер,
Халыклар теләге — терәктер;
«Тот та өз...» диюләр урынсыз —
Дипломат булу да кирәктер.

Ә бүген таяныр нокта бар —
Үпкәләр юылыр барсы да...
Ә без бар...
Булырбыз...
Барабыз,
Төз атлап Сәйдәшев маршына
Өченче мең еллык каршына.

3

Иделгә ашыга Казансу —
Таш-бетон ярларга кага су.
Көн аяз, исә җил, ага су —
Дөньялар үзгәрде бит инде,
Күңелдә нигә соң ямансу?!

Әнә ич, хәзинә тапканнар! —
Әйт шуны — бу моңлы сүзеңдә,
И шаулый бар гавам — түз генә;
Ә Казан, чын-чынлап карасаң,
Бәһасез хәзинә үзе дә.

Казылгач күмерле катламнар,
Нәрсәдер табылыр тагын да;
И Казан, искиткеч иденң бит,
Син көчле, куәтле чагыңда,
Чорларның бәхетле таңында.

Көнләшеп күзәткән күршеләр
Һаман яу өстерде өстеңә,
Кылларын язмышның уйнатып,
Хәвефле чорларны кичтең дә
Баш иденң бәхетсез бер көндә.

Көрәш бит аяусыз — азактан
Каласың йә аста, йә өстә;
Нечкә кыл өстендә торганда,
Хәл итә бәләкәй ялгыш та —
Сакласа тик саклар фәрештә.

Кем әйтер кистереп — иң элек
Йомырка булганмы, тавыкмы?!
Чуалган һәм надан дөньяның
Абсолют җавабын табыйкмы,
Төзәтеп борынгы тарихны?!

Хәтерлә Ходайның каһәрен —
Гыйбрәтле Вавилон кыйссасын,
Бер телдә сөйләшеп адәмнәр
Күкләргә менәргә кыймасын —
Үзләрен көчле дип тоймасын.

Шуңа да ошбу җир йөзендә
Төрлеләр йолалар, шивәләр;
Тәрәккый итәсе урында
Адәмнәр бер-берсен тибәләр,
Дошманлык агуы сибәләр.

Уйларым еракта-еракта,
Уйларым гасырлар артында;
Аңлаган шикелле җанымны,
Дулкыннар бер ярсый, бер тына —
Ниләр бар гасырлар артында?!

Күрәсем килә, дим, кальгада
Кизүлек итүче батырны;
Ул минем хыялда кул изәп,
Янына җайдаклар чакырды —
Болгарга барыр юл такырмы?

Офыкта ят яулар күрәм, дип,
Тиз генә әйтер соң кем генә —
Ә Казан — Болгарның чигендә.
Җилдән дә җитез шул җайдаклар
Хәбәрне җиткерсен көненде.

Ашыктыр атларны, ашыктыр —
Камчыла аласын, коласын,
Җәяләр, сөңгеләр әзерме?
Болгар тиз шул хакта уйласын —
Кем белә алда ни буласын?

Гыйбрәтнең күрдек ич төрлесен:
Ачылмас капкалар ачылды,
Уяулык йоклаган чакларда,
Килмешәк яугирләр баш булды —
Тәндә кан, күзләрдә яшь булды.

Дөнья бу! — исләрең китмәсен.
Без, Тукай әйтмешли, кайчандыр
«Шаярдык вакытлар алмашып».
Һәм теттек кемнеңдер тетмәсен —
Аңа да күз йомып үтмә син.

Ә болай электән күңел киң:
Ниятең изгеме — чит итми;
Ничәмә кавемнәр дус булып
Торган ич бер-берсен кимсетми —
Кемгә соң, кемгә соң ни җитми?!

Дөнья бит тар түгел, хәзинә —
Байлыклар һәркемгә җитәрлек.
Залимнәр азсына ник әле —
Таланган малларны барыбер
Китәлми кабергә күтәреп.

Уйлыйм да вәйраннар буламын —
Ганнибал, Атилла яуларын
Һәм, Алтын Урданы каһәрләп,
Ничәмә-ничә чор шаулады —
Соңыннан эзләр дә калмады.

Заманнар уза да, чал тарих
Куя ул бик кызык итеп тә:
Европа баш игән изге Рим
Сыйган ич бер сыңар итеккә —
Җитмәсә, бер ягы китек тә.

Дөнья бу! Исләрең китмәсен —
Күрсәтә бер алдын, бер артын;
Масаеп йөрсәң дә «Без — кем!» дип,
Үлчәүне, чаманы югалтып,
Вәхиләр иңә бит югартын.

Җайдаклар Болгарга җиткәндә,
Нигәдер кызарып атты таң;
Җил хәбәр китерде еррактан —
Дәһшәт дип, вәхшәт дип какты чаң:
Тәмерләң каланы яндырган.

Идел-Йорт бәлагә тарганда,
Кирәкме яугиргә үгетләр?!
Дәррәү шул сугышка катышып,
Баш салды баһадир егетләр...
Һәм сүнде иң соңгы өметләр.

Соңыннан, аларны олылап,
Мөхәммәд Әмин җыр чыгарыр;
Ничәмә гасырлар буена
Болгарым тарихтан югалыр —
Ул изге җирләрдә көл калыр.

Хәрабә өстендә хәрабә —
Ил-Йортта хәтәрдән-хәтәр чак;
Язмышка салынган жирәбә —
Ни кыла алырсың, Алтынбәк,
Ни кыра алырсың, Галимбәк?!

Тик башын киссәң дә татарның,
Кылычын күтәргән кул калыр,
Өметкә барыбер юл калыр;
Тормышны яңадан башларга
Балалар, оныклар кузгалыр.

И Олуг Мөхәммәд, кил әле —
Тергезче Казанның учагын,
Диварга уратып бар ягын,
Башкала-ташкала ит аны —
Синең бит кодрәтле ир чагың.

4

Утырам уйларга уралып —
Көн аяз, исә җил, ага су;
Казансу, елларны санапмы,
Ярларга дулкыннар кагасың,
Ә үзең кайларга чабасың?!

Сумы соң, сумы син, агымсу? —
Кайчакта шик били күңелне;
Син шушы дәрьяга сыймастай
Бабайлар күз яше түгелме?
Әбиләр күз яше түгелме?

Мөлдерәп тора ич Кабан да,
Мөлдерәп тора ич Болак та,
Ниндидер өн килә — шул көннәр
Авазы чыңлый күк колакта,
Гасырлар артында, еракта.

Ул сулар төбендә — чишмәләр —
Алар, дим, дөреслек яклыдыр;
Суларның гомере — мәңгелек,
Хәтерләп бу көнгә чаклыдыр,
Үткәннәр аһ-зарын саклыйдыр.

Ул чорлар дәһшәтен, вәхшәтен
Күрәбез бер Иван Явыздан —
Яңа сүз гел иске авыздан.
Әйе, ул баш бирмәс ирләрне
Сал итеп Иделгә агызган.

Күңелем алдамый — аңа да
Тиң булыр бәдбәхет табылган,
Данга һәм байлыкка табынган,
Илле мең гаскәрле Шаһгали —
Ничек соң ул безнең кавемнән?!

Шул чорны тикшергән кемнеңдер
Кирәктер зиһенен җилләтү;
Янәсе, милләтләр талашкан,
Кирәкми андый буш сүз әйтү —
Золымның юк аның милләте.

Кил әле, сөекле Сөембикә,
Утырчы яныма чирәмгә;
Идел-Йорт афәткә тарганда,
Кем иде, кем иде тирәңдә —
Ник олуг хакыйкать тирәндә.

Утырып сөйләшик бергәләп —
Кил әле, кил әле, Колшәриф,
Килсеннәр баһадир оланнар,
Үткәннәр аркылы юл ярып,
Үлемнәр аркылы юл ярып.

Ишетсен Казансу... буыннар
Үзара уртак сүз тапканны,
Хәлиткеч яу кызган мәлләрдә,
Кем ачты, кем ачты капканы?
Кем куйды татарга капкынны?

Кайларга агасың, Казансу? —
Тукталып тор әле беразга;
Чыкмасын хилафлык, чир, каза.
Бу хәлләр тузларга язылсын,
Суларга язылмый елъязма.

Тик тарих хәтере җиткерә
Үткәннең яралы хәбәрен —
Җәлладның дүрт гасыр ярымга
Сузылган золымын, җәберен,
Иләктән уздырып кайберен.

Әллә бу якынча гөманмы,
Дөресен әйтүдән качумы,
«Иго» дип «ачыш»лар ачумы;
Ә бәлки, вакыт та җиткәндер
Басарга элекке ачуны.

Тигезли замана һәммәсен —
Ул кая барасын белгәндер;
Буталып, болганып бетсәк тә,
Канунда син дә бер, мин дә бер —
Язмышлар уртак һәм бердәнбер.

5

И Казан, җитте бит, ниһаять,
Тантана итәрдәй таңың да.
Күр әнә, иң хәтәр чагыңда
Мең еллык даныңны саклаган
Иң затлы кунаклар табында.

Ник читтә торасыз, җайдаклар,
Әйдәгез, узыгыз түргәрәк;
Онытып торыгыз үткәнне —
Чор кичкән табыннар түгәрәк,
Бер бәйрәм итикче бергәләп.

И Олуг Мөхәммәд, уз түрдән —
Казаның әле дә башкала,
Кирәкми ясарга ташлама —
Ул чәчәк аткан чор тарихта
Син тәхет тотканнан башлана.

И сылу Сөембикә, тартынма —
Күр, Сафагәрәең чакыра;
Син тәхет варисы улыңны
Кочаклап утырчы янына —
Күңеле шат булыр аның да.

Колшәриф, син — мәңге хәтердә,
Бу җирдә җәсәдең ята дип,
Фидакарь исемең олылап,
Гел сөйләп торсын шул хакта дип,
Өр-яңа мәчетне атадык.

Табында — ханнар вә олуглар,
Ил-Йортны зурлаган галимнәр,
Күнчеләр, сынчылар, ташчылар,
Сунарчы-кошчылар, ашчылар...
Саныйкмы?.. Санасаң тагын бар...

Һәммәсе — яхшымы, яманмы —
Бу Казан каласын үз иткән,
Күзләрен өзмәгән өметтән;
Инде без күптәнге үткәнгә
Карыйбыз гел бүтән күзлектән.

Мөхтәрәм борадәр Худяков,
Ялганнар еpoints ерактан килә, дип,
Син безгә дөресен сөйләдең,
Мең яла ягылган татарны
Гайбәттән сакларга теләдең.

Урының Карамзин янында,
Баскаков, Гумилев кырында;
Сөйлә син кунаклар алдында
Гыйбрәтле язмышлар турында —
Шаһит бул риясыз җырыма.

Бәйрәмчә Казанның табыны —
Эш башка булганга җыр башка;
Күрегез, дус-тату яшәгәч,
Иң матур хыяллар чынгашкан —
Заманнар заманга тоташкан.

Ил-Йортның мөхтәрәм затлары
Эшенә и шаклар катырлык;
Аларның фидакарь җаныннан
Туган ич бүгенге матурлык,
Туган ич бүгенге батырлык.

Тик сатлык-хаиннәр үтмәсен
Бәйрәмчә бизәлгән ишектән,
Юл табып ярыктан, тишектән,
Ә элек яу йөргән көч белән
Уртак сүз табарбыз ничек тә!

И Казан, батырың меңләгән,
Сер бирмәс бер сабан туенда;
Тик җиңү аларның уенда.
Йөзекнең фирүзә кашы күк
Балкырсың гасырлар буена.

Өстәлләр түгәрәк-түгәрәк,
Түгәрәк өстәлнең түре юк,
Табында һәммәбез бертигез —
Бәйрәмнең яшертен сере юк,
Һичкемнең кимсенер җире юк.

Тәбрикләп мөбарәк бәйрәмне,
Илбашы акыллы сүз әйтсен,
Туасы заманнар хакында
Уйларның матурын уйлатсын,
Бәхетле таңнарны уятсын.

Унитар дәүләт дип шауласа,
Һәртөрле сәяси генерал
(Янәсе, биргәнне кире ал?),
Ул булды гаделлек ягында —
Ул булды какшамас федерал.

Мин — Тимер, диде ул көрәшнең
Иң утлы, киеренке мәлендә.
Чор башка, шарт бүтән — аралар
Булалмый элекке хәлендә —
Без тигез Русия илендә.

Кирәкми үпкәләр, рәнҗүләр,
Бәхәстә ярышу — кем кемне?!
Милләтләр даны бер-берсеннән
Аз гына артыкмы, йә кимме —
Тик Вакыт чыгарыр хөкемне.

Язмыш бер, тарихлар кушылган —
Ник аны карага төрергә!
Тырышыйк өр-яңа гасырның
Бары тик Кояшын күрергә,
Чөнки без бу җирдә гомергә.

## IV

*Ай мөлдерәп карый күзләремә —*
*Күңелемдә сәер моңнар тулы;*
*Ничек аңлатыйм соң аның серен —*
*Нәрсә булды миңа, нәрсә булды?*



## *Каршылау идиллиясе*

Тып-тын әле һава аланы —
Очкычлар һәм боргалаклар тын,
Офык буйлап сыза таң-нурын;
Йә, мәрхәбә, яңа көн таңы —
Тып-тын әле һава аланы.

Очкычлар һәм боргалаклар тын.
Таң рәсемен ясыйм — ул гүзәл;
Катыштырмый гына чит сүзләр,
Әйт сурәтнең сихри чынлыгын.
Очкычлар һәм боргалаклар тын.

Офык буйлап сыза таң-нурын,
Көн туар да, гүләр бар алан:
Ярым кайтыр ерак юллардан,
Ярларыннан ташыр шатлыгым —
Офык буйлап сыза таң-нурын.

Йә, мәрхәбә, яңа көн таңы,
Күңелләрнең сүндер сагышын —
Татлы булсын безнең кавышу,
Мәхәббәтен сөйлә син аның —
Йә, мәрхәбә, яңа көн таңы!

Тып-тын әле һава аланы —
Очкычлар һәм боргалаклар тын —
Офык буйлап сыза таң-нурын;
Йә, мәрхәбә, яңа көн таңы —
Тып-тын әле һава аланы.

## *Биеккә!*

Кеше барыбер кошлар нәселеннән.

*С.Сөләйманова*

Гел биеккә алар, гел биеккә! —
Мин көнләшеп карыйм кошларга;
Их, миңа да шушы кошлар кебек,
Зәңгәр киңлекләрдә очарга!

Ярышмакчы булып алар белән,
Уйлар кабат канат кагына
Аэроклублы яшьлек көннәремә,
Хыялымның алсу чагына.

Һаваларга әле менмәс борын
Күгемнән соң кемнәр аерды?
Язмышыммы, кошлар каргышымы
Канатымны шулай каерды?

Үкенсәм дә, хәзер соң шул инде —
Туздырылган күпме оялар!
Кыргый «эшләремне» уйлыймын да
Хыялымнан хәтта оялам.

Ә нигә соң җанда сихри аваз?
Әниләр соң борчый күңелне?
Борынгыдан канда калган геннар
Шулай күккә өнди түгелме?

Ыгы-зыгы тулы бу дөньядан
Гарык булып туйган чагымда,
Әллә ниләр тели күңелем кошы,
Ал хыяллы чагын сагына.

Гел биеккә дәшә, гел биеккә!
Юк, бу хисне тыймыйм... тыялмыйм!..
Артларыннан ләкин җиталмыйм шул —
Канаты юк ерак хыялның!

Гел биеккә кошлар...
Гел биеккә!..

## *Кошлардан көнләшәм*

Ак болытлар оча. Безнең дә бит
Болытлардан өстә бар очкан.
Ләкин хыял чикле: бу җиһанда
Җир белән Күк сирәк кавышкан.

Очар кошлар бездән бәхетлерәк:
Күкләр канат биргән, көч биргән —
Җитәкләшеп җитез җилләр белән
И!.. тәм таба алар очудан.

Аэродинамика дигән фәнне
Үзләштергән алар гомерлек,
Ә без исә, уздырмакчы булып,
Әллә кордык, әллә җимердек.

Без очкычлар уйлап тапкан булдык,
Ракеталар менде галәмгә,
Тик металлга сеңгән энергия
Бик аз ярдәм итте адәмгә.

Без Кояшка Икар булып очсак,
Балавыз күк хыял эреде;
Әле ярый егылып төшкән чакта,
Сөякләрне җыйган Җир иде.

Без — табигать падишасы, диеп
Мактанудан юктыр файда да.
Мин карлыгач булып, лачын булып
Очар идем әллә кайларга.

Кошлар оча. Оча бар тарафка,
Язын — төньяк, көзен — көньякка;
Кошлар — иреклеләр. Тукталу — юк,
Чикләр буйлап читән корсак та.

Ак болытлар оча. Кошлар оча.
Кешеләр дә кайчак еш оча.
Тик нигә соң? Менгезмәскә теләп,
Күк Җир белән һаман тартыша.

Чиксезлекнең чиген эзләр өчен,
Җирдән күккә юкса кем дәшә?!
Кимсетүем түгел кешеләрне,
Мин кошлардан фәкать көнләшәм.

Алар — бәхетлеләр.

* * *

Таң алдыннан берәү, моңнар сибеп,
Тальянкасын сузып җырлады.
Йотылып, тәрәзәгә якын килеп,
Син дә, сеңелем, аны тыңладың.

Тойдың дерелдәвен иңнәреңнең,
Күзләреңә яшьләр тулуын...
Белдең мәллә аның моңнарының
Синең өчен генә булуын?..

## Умырзая

Баш калкытып карлар кочагыннан
Күз кысасың Кояш-чибәргә;
Ашыгасың сабый чагыңнан ук
Мәхәббәттә газап чигәргә.

Нәүмизләнеп кабатлыйсың көн дә:
— Кояш!.. Кояш!..
...гел шул исемне;
Умырзая, әллә яшьлегеңдә
Сөеп туя алмам, дисеңме?!

## *Нәрсә булды миңа?*

Күзләремә никтер йокы керми —
Хәлләремне белеп тора тик Ай;
Нәрсә булды миңа, нәрсә булды —
Ахрысы, мин гашыйк булдым бугай.

Ай мөлдерәп карый күзләремә —
Күңелемдә сәер моңнар тулы:
Көләсе дә килә, елыйсы да —
Нәрсә булды миңа, нәрсә булды?

Беренче кат бит бу барысы да,
Ничек аңлыйм соң мин бөтен серен;
Ничәнче көн инде мин дөньяда
Әллә нинди уйлар белән йөрим.

Ул тик дәшми генә, мин сүземне
Күз карашым белән аңлатырмын.
Ай да әйтер аңа уйларымны —
Яратырмын кебек, яратырмын.

## *Таңда аңлашу*

*(Парлы җыр)*

— Татлы йокылардан уяттым мин,
Таң нурлары үпсен диеп сине;
Үзең сиздең микән, сизмәдеңме —
Җил булып мин кактым тәрәзәңне.

— Син җил булып кактың тәрәзәмне —
Таң нурлары үпте йөзләремне;
Күңелләрем тулды кинәт кенә —
Аны сиңа әйтми түзәрменме?

— Аны миңа әйтми түзалмассың —
Күзләреңә яшьләр килер тулып;
Әйтер сүзләремне әйтер өчен,
Мин сайрармын таңда былбыл булып.

— Син сайрарсың таңда былбыл булып,
Моңнарыңнан сөю хисем ташыр;
Җиде ятлар ләкин сизми торсын —
Хисләреңне, зинһар, тирән яшер.

— Хисләремне ничек яшерермен —
Бәхетем, дим сиңа — гүзәл кызга;
Сизелер бит барыбер, сизелер бит,
Мин гөл булып үссәм бакчагызда.

— Син гөл булып үссәң бакчабызда,
Мин кадармын сине түшләремә;
Бердәнберем итеп, ярым итеп
Күрдем сине бүген төшләремдә.

## *Соңгы чәчәк*

*...га*

Сагындым моңсу карашың,
Сагындым сылу сының —
Син бит иң соңгы чәчәге
Күңелем бакчасының.

Язмышлар күптән язылган,
Языбыз түгел бергә.
Ничек соң, барын онытып,
Ялгышны төзәтергә?!

Сагынган саен саргаям,
Сагынам тагын... тагын...
Минем бит көзге бакча күк
Саргаеп кибәр чагым.

Шатланыйм әле соңгы кат,
Язымның күреп соңын,
Син инде соңгы чәчәге
Күңелем бакчасының.

## *Экспромт*

Тротуарлар — тимерче сандалыдай,
«Тук!» та «тук!» —
каблуклар-чүкечләр;
Бар урамнар шул авазны кабатлый,
Бар урамнар маҗаралы төштәй.
Урамнардан атлый каракашлар
(Мона Лиза кебек мәңге яшьләр!).
Урамнардан атлый бөдрә чәчләр,
Һәр ир-атка назлы караш ташлап.
Рәхмәт, сеңелкәшләр һәм яшьтәшләр,
Рәхмәт сезгә, ханым һәм туташлар,
Яшьлегегез,
яшәвегез өчен,
Безне вакытында ташлавыгыз өчен,
Безнең ихтыярны чикләмәгән өчен —
Тормыш читлегенә бикләмәгән өчен.
Ә ул гүзәл —
тормыш (сихерле төш!) —
Мона Лиза сыман серле елмаюлы.
Төшенеп кара барын — кирәксенсәң —
Лабиринттай борма-борма юлы.
Ә без аны мондый килеш түгел,
Яралгыдай самим чагын күрик;
Урамнардан атлыйк күкрәк киереп,
Күңелләрне мәхәббәткә төреп.
Каргалган, мәсхәрәләнгән Дон-Жуаннар,
Рәхим итегез урамнарга!
Үч итеп бар акыллы башларга
Һәм һәртөрле Ходай органнарга,
Каратыгыз — карата алган кадәр,
Яратыгыз — ярата алган кадәр.
Урамнарда ханым һәм туташлар —
Брюнеткалар, блондинкалар,
Бөдрә чәчләр, кара кашлар...

Кирәкми әйтергә: «Аннан нишләргә?»
Нигә «Мәңгегә!» дип антлар эчәргә,
Нигә мәхәббәтне чүпрәккә төрергә,
Дүрт стена кысасына кысылып керергә?!
Урамнар яшәсен,
Бакчалар...
Урманнар...
Ирен вә кочаклар...
Серлелек...
Наз...
Рәхәт...
Яшәсен алдаусыз аңлашу-серләшү...
Яшәсен эчкерсез мәхәббәт!
Үч итеп бар акыллы башларга
Һәм һәртөрле Ходай органнарга,
Каргалган, мәсхәрәләнгән Дон-Жуаннар,
Рәхим итегез...
        урамнарга!..

* * *

Сак белән Сок кебек, карурманда
Адашканбыз, илдән еракта;
Инде кавыштык дип ымсынгач та,
Искәртмәстән генә таң ата.

Өмет дигән нәрсә әллә һаман
Алгы көнгә күчә барамы?
Ничә еллар саргайдык бит инде —
Кем соң ялгар ике араны?!

* * *

Кичкән чорда гомер экваторын,
Очрашсак та кабат күзгә-күз,
Посып калды күңел почмагында,
Әйтелмичә калды әйтер сүз.

Әллә ничек телем әйләнмәде,
Сылтау итеп ярсу елларга,
«Калган гомерләрне икәүләшеп
Үтик мәллә?..» — диеп сорарга.

Чөнки «үткән» үткәндә шул инде —
Дәшми калуым да шуңадыр...
Кайбер нәрсәләрне яшьрәк чакта
Хәл итәргә кирәк булгандыр.

## *Соңлап килгән мәхәббәт*

Йолдызларга карап юрамадык
Соңлап килгән сөю турында;
Көтелмәгән ак бәхетем булып
Балкыдың син күңелем түрендә.

Кичегүләр җирдә була тора —
Соңлап килгән язлар азмы соң?!
Син дә шулай соңлап урын алдың
Мөнбәрендә минем язмышның.

Еллар әле суытмаган икән
Йөрәкләрнең кайнар хисләрен;
Саклый алган өмет иртәләрен,
Саклый алган бәхет кичләрен.

Гомер юлларында өзелеп көтеп
Табыла алган ярлар — яр икән;
Язмышларны юкка ялгыш, диләр,
Язмышлардан узмыш бар икән.

## *Гөлүсә*

*(Җыр)*

Тәрәз төпләрендә гөл үсә,
Пәрдәләрне сыйпап җил исә;
Язны ямьләп чәчәк атсын дип,
Гөлләргә су сибә Гөлүсә.

Тәрәзләрдә нурлар уйнаклый,
Пәрдәләре зәңгәр, уймаклы;
Тик нигә соң, нигә үзенең
Күзләрендә сагыш шулчаклы?

Язлар моңы аңа күчкәнме,
Вәгъдәләре искә төшкәнме,
Шаян җилләр сөйгән ярыннан
Әллә хәбәр бирми искәнме?

Яз ямансу гомер-гомергә —
Күңелләргә шуңа моң күчә;
Тәрәз төпләрендә гөл үсә,
Үзе чәчәк бүген Гөлүсә.

## *Үкенеч*

Гүзәл мизгелләрне мәңгелеккә
Тоташтырган чылбыр шикелле,
Сәйләп булып сүзләр тезелде дә
Кинәт кенә күңел җилкенде.

Җилкенмәскә мөмкин түгел иде,
Дәрт ташуга чама юк иде,
Әллә нишләп инде сыкы сарган
Йөрәгемә утлы ук тиде.

Ай-һай, безнең яшьләр аермасы —
Сеңел генә дия алмассың;
Кавыштырмас безне фани дөнья —
Мин китәсе, ә син ... каласы.

Төрле-төрле чорда туганбыз шул —
Табып булмас юньле сәбәп тә;
Мин гөнаһсыз, син хур кызы булып,
Их, очрашсак иде... җәннәттә.

## *Сулышыма утлар капкан*

*(Җыр)*

Идел буйлап кына барасы бит —
Ерак түгел юллар арасы;
Күзләреңә тутырып карармын да
Басылыр күк күңелем ярасы.

Әллә ничек кенә безнең хәлләр —
Араларда йөрми хат-хәбәр.
Очрашулар кыска төш шикелле,
Сагынуларым көчле шулкадәр.

Рәсемеңне көнгә мең кат карыйм —
Һәр былбылның була үз гөле;
Никтер сирәк туры килә безгә
Бәхетләрнең татлы мизгеле.

Ак пароход белән, Идел буйлап,
Кайчан гына тагын килерсең;
Сулышыма утлар капкан минем —
Сөюемне шуннан белерсең.

* * *

Ык буйлары ник уйларны
Суларга сала икән?
Үпкән-кочкан җилгә очкан...
Юк, истә кала икән.

Ык буенда ник куенында
Назланып яттым икән?
Сөймәсәм дә, «Сөям» диеп,
Ник ялгыш әйттем икән?

Ык буенда чык коена
Айның аксыл нурында;
Син дә оныт, мин дә онытыйм
Ул очрашу турында.

## *Соңгы үпкә*

Мин сиңа арган чагында
Терәлер терәү генә;
Меңнәрдән бердәнбер түгел,
Меңнәрдән берәү генә.

Нигә соң күпме гомерләр
Сәгадәт язын көттем;
Мең кабат сиңа рәнҗеп тә,
Мең кабат гафу иттем.

Алдандым иреннәреңнең
Тылсымлы тәмен тоеп,
Юаттым мәҗнүн йөрәкне,
Көн килер әле, диеп.

Мин ихлас идем, шуңадыр
Төзәлми җан ярасы,
Уйда гел — бакча юллары,
Сөембикә манарасы…

Тик вакыт… тынычланырга —
Онытылыр үпкәләр дә…
Инде соңдыр…
Соң шул инде
Кайтырга үткәннәргә.

* * *

Беләм, инде мине сөймисең син —
Оныттырган барын башка наз;
Бер үк ялкын, бер үк хисләр белән
Кабатланамыни һәммә яз?!

Икәү каршылаган аккош... киткән,
Күлләр кипкән...
Хисләр түгелгән...
Бар да үткән...
Күлләвекләр сыман
Сагыш кына калган күңелдә.

Өзгәләнмим эзләп үткәнемне —
Мин дә инде сине сөймимдер;
Мөгаен, шул ерак мизгелләрне
Яд итәргә генә телимдер.

## Соңгы очрашу

Бу... булырга тиеш иде инде —
Котылгысыз, ямьсез сөйләшү.
Хушлашмыйча гына аерылыштык,
Кемдә иде гаеп — белмәссең.

Кил дигәнгә генә килгән идем,
Син көтәрсең диеп көтмәдем;
Китеп бардым яңгыр яуган мәлдә —
Килгән трамвай ялгыз китмәсен.

Бер булырга тиеш иде инде
Нәтиҗәсе елак елларның;
Сагыш иде җанда — еламадым,
Минем өчен трамвай елады.

Трамвай гына елый-елый чапты
Коеп яуган көзге яңгырда,
Оныттырыйм диеп, бар булганны,
Син дә оныт — юкка кайгырма!..

## *Синең елмаюың*

Күңелеңдә әллә ниләр бардыр,
Күңелеңдә җил вә давыллардыр,
Парә-парә килгән йөрәк белән
Көлеп кенә яшәү, әйе, авыр.

Ләкин күңелең азат кара шомнан,
Йөзләреңә һәрчак кояш кунган —
Тирә-юньдәгеләр боек чакта,
Шифа таба синең елмаюдан.

Эчеңдә ут янса, әйдә, янсын,
Иреннәрдән һаман нурлар тамсын —
Үткәндәге тик үткәндә калсын —
Үз-үзеңне җиңеп гел елмай син.

Син елмайсаң, җанга рәхәт була,
Син елмайсаң, җанга шатлык тула;
Югыйсә бит күңел бакчасына
Бәхет кошы, ай-һай, сирәк куна.

Дөнья кырыс. Әмма яшисе бар.
Яшәү тәмен татып яшьнисе бар —
Боегудан, күңел төшүләрдән
Коткара тик керсез елмаюлар.

## *Елама!*

Елама, кимсенмә, горур бул —
Күп алар рәнҗергә сәбәпләр.
Син ышан — барыбер бар алда
Сәгадәт китерер сәгатьләр.

Гомер бит! — диңгезләр кичәсе,
Дару да, агу да эчәсе.
Көн үтәр — ә гомер соңында
Хәтердә калыр соң ничәсе?!

Син, бәлки, кешеләр, үзең күк,
Риясыз һәм ихлас, дисеңдер,
Бу кырыс дөньяда газап күп,
Ә син үз-үзеңне үсендер.

Йөрәккә ук булып кадалган
Гамәлләр күп булыр, ләкин түз —
Бу минем сиңа чын күңелдән,
Дусларча юатып әйткән сүз.

Җанында изгелек утларын
Сүндерә алмасын еллар да,
Яшисе гомерләр бар әле —
Горур бул, кимсенмә, елама!

## *Тәүбә*

Бакчада җилбәзәк яфраклар тангосы.
Шыксыз көз үртәшә тешләрен ыржайтып.
Кайда син, беренче сөйгәнем — таң кызы,
Юатчы күңелемне, риясыз җыр әйтеп.

Кайда син, унҗиде яшь җиткән егет чак,
Ләйләнең эчкерсез Мәҗнүне кебек чак...
Гыйшкымны таптым да...
югалттым мәңгегә —
Язмышның көлүен тоям соң мин нигә?!

Күзләрем күзләде никтер һәр чибәрне,
Гүзәллек яныннан битараф үтмә, дип,
Һәм назлы иреннәр пышылдый бирделәр:
«Китмә, дип, китмә, дип, тик ялгыз итмә, дип...»

Дон-Жуан, дисәләр, диярләр — юк сүзем,
Күпләрне саргайттым, күпләрне сөйдем мин;
Хәтта Җир шарының бар кызын берүзем
Бәхетле итәрмен шикелле идем мин.

Йөрәкнең биге юк, нәфеснең чиге юк,
Акыл, баш күтәреп тар тормыш базыннан,
Илерә-илерә тәкрарлый яшь коеп:
— Маңгайда күпме сыр... —
Язмышлар язылган...

Беренче мәхәббәт! Эх, эзләр идем мин,
Кайтсачы үткәннәр кирегә барысы да...
Сап-сары яфраклы ак каен шикелле,
Утыз көз моңаеп яшь коя каршымда.

Яфраклар ник болай сагыштай сарылар,
Аларның тангода биерлек пары бар.
Мин исә саргайган яшьлеккә сызланам,
Кыш көтеп сагайган каенны кызганам.

## *Мәхәббәт вальсы**

*(Җыр)*

Күңелләр кояшлы —
Ни тылсым бар анда?!
Әйтерсең син дә мин
Бу гүзәл җиһанда...
Күзгә-күз елмая,
Тагын да... тагын да...
Мин синең яныңда,
Син минем янымда.

Кушымта:
Кояшлар балкысын
Мәхәббәт хисендә —
Онытылып биик без
Бу бәйрәм кичендә.
Әйләник вальста —
Бар дөнья әйләнсен,
Сергә сер ялгансын,
Чәчкә чәч бәйләнсен.

Юллар бар, җырлар бар
Без уртак итәрлек,
Сөярлек, янарлык
Саф хисләр җитәрлек.
Биик без вальста,
Яшьлекләр үткәнче,
Күңелләр күңелгә
Серләрен түккәнче.

Кушымта.

* Мәсгудә Шәмсетдинова музыкасы.

## *Карлар ява*

Тәңкә-тәңкә карлар яуган кичтә,
Яңа елны каршылаган истә;
Син ап-актан киенгәнгә мәллә
Чумган иде дөнья ап-ак төскә.

Чыршыбызга хәтта аклык иңде,
Табын түрләрендә шатлык иде,
Без биедек икәү ул чагында
Бөтерелеп моңнар кочагында.

Телләргә тик татлы сүзләр килде,
Иреннәрдә тик елмаю иде,
Онытмаска күңелләргә сеңде
Шул кичәнең матур истәлеге.

...Бер ел гомер кичкән — ядкарь исән —
Ак тылсымлы кичә чыкмый истән;
Тик нигә соң кабат сагыш җанда,
Сүнү белмәс утлар яна анда...
Күр, уйларга безне сала-сала,
Тагын ... былтыргыча карлар ява.

## *Җаннар талпына*

Хатын-кызның бөтен матурлыгы,
Бөтен күрке — ана булуда.

*Һ.Такташ*

Бер фараз бар: имеш, хатын-кызлар
Җаннар оясыдай бер нәрсә...
Һәм ул тәмам тынгы тапмый, имеш,
Туасылар туып бетмәсә.

Нигә, димсез, хәзер гаиләдә
Сәер тарткалашу юк-барга?
Яшәешне камил итәр өчен,
Туасы җан тумый дөньяга.

Хатын-кызда ничә җан икән соң —
Күпме бала аннан җан ала?
Шул сорауга катгый җавап кирәк
Мәхәббәттә үткән таңнарда.

Яшь хатыннар дәртле, таза да бит,
Нигә аз соң болай... сабыйлар?
Югыйсә күр, әнә нинди ипле,
Нинди гүзәл безнең әбиләр.

Кайсы тугыз, кайсы унны тапкан —
Бушангандыр шуңа күңелләр.
Без яраткан ярлар нигә әле
Алар кебек сабыр түгелләр.

Табигатьнең мәңге үзгәрешсез
Төгәл кануннары хакына,
Якты дөнья теләп, хатын-кызның
Йөрәгендә җаннар талпына.

## *Бишек җыры**

*(Җыр)*

Әллү-бәллү, чәчәгем,
Бәллүр мәллә бишегең?
Йоклачы эреп кенә,
Матур төш күреп кенә.

Төшеңдә дә янында
Булыр әти-әниең,
Иң-иң тәти курчагың,
Иң-иң тәмле мәмиең.

Әй ак кынам, пакь кенәм,
Тыныч йокла, нәнием,
Уянмады микән дип
Борчылмасын әниең.

Чулпан йолдыз таңгача,
Бишегеңне тирбәтер,
Фәрештәләр, җыелып,
Тел ачкычын өйрәтер.

Иртән сине ал кояш
Назлый-назлый уятыр,
Сөя-сөя һәммәсе
Иң-иң иркә сүз әйтер.

Мин дә назлап сөярмен,
Шатлыгым син, диярмен.
Бәхетле бул, дәү үс, дип,
Изге теләк теләрмен.

---

* Рамил Курамшин музыкасы.

* * *

Бөтенесен заман юньсез якка борды —
«Секс» сүзе «мәхәббәт»не алыштырды:
Гыйффәтлеләр чибәркәйләр табынында
Ни өчендер хәзер артык кашык булды.

Ни өчендер ябык чырай, озын торык
Матурлыкка эталон дип дан алдылар —
Күкрәкләрне, билләрне вә арт саннарны
Миллиметр белән хәтта санадылар.

Үлчәүләре туксан, алтмыш, туксан да бит —
Бу саннарга гәрчә шаклар катырлык та,
Ялкын юкта, илһам юкта, сөю юкта
Нинди ямь бар мондый кысыр матурлыкта?!

И кайда сез, Рафаэльчә — сабыйларын
Күкрәгенә кыскан гүзәл мадонналар?!
Карашыннан ут дөрләтер чая кызлар,
Сез соң хәзер артыкмыни бу дөньяда?!

Подиумда — тонык күзләр, сыгылма сын,
Адым тигез — ничекләр ул абынсын соң?!
Дөрләп янган ут сорый бит шагыйрь җаны —
Аннан башка ул ничекләр кабынсын соң?!

Зөләйха вә Ләйләләргә, Зөһрәләргә
Гашыйк җаннар, ни кызганыч, сирәк инде —
Үткән чорның Мәҗнүн рухлы шагыйрьләрен
Кирәксенми инде заман, кирәксенми.

Чәчәккә тиң чибәркәйләр акча өчен
Ауный бүген кемнәрнеңдер түшәгендә;
Ни булды соң бу дөньяга — югыйсә бит
Бөтенесе дөрес иде... кичә генә.

Аккошлардан безгә үрнәк аласы ла...
Мәхәббәтләр мәңгелеккә каласы ла —
Бәхет тә шул, тәхет тә шул, ләхет тә шул,
Ни җитми соң тагын... адәм баласына?!

## Көзге төндә

*(Бүгенге тормыш манзарасы)*

Усал җилләр, улый-улый,
Көз салкынын сылый тәнгә;
Чү, ни күрәм — кара төндә
Шыңшый-шыңшый кем елый?!

Елый каршымда бер малай.
Әйтте ул шунда ни барын...
Өйдән кыйнап чыгарганын
Әнисенең... Һәм тагын...

Һәм тагын... кайчак кичләрен
Бер дәү абый килгәнлеген,
Әнисенең аның белән
Калганлыгын сөйләде.

Сөйләде — сызды йөрәгем —
Юатып ни хәл итәсе?!
Аерылып киткән әтисе —
Юк икән шул терәге!

Терәлеп ялгыз каенга,
Шыңшый сабый. Ә җил ачы;
Аңлаулар, ай-һай, кыен ла
Бу адәмнәр язмышын!

## *Мәхәббәт сәерлекләре*

Хатын-кыз үз, ир-ат үзгә,
Җенесләр төрле, димә;
Күр, аллар алга сыланган
Һәм зәңгәр — зәңгәренә.

Үтмәгән әле, үтмәгән
Нероннар кичкән заман, —
Табигатьнең төп кануны
Билгесез мәллә һаман?!

Кемдер гыйш-гашрәт эчендә
Канунны сукмый санга,
Баш булмыйча нәфесенә,
Кемнәндер үрнәк ала.

Атабыз Адәм генәдер,
Анабыз Хава гына
Бердәнбер ысул тапканнар
Гомерләр дәвамына.

Алмасын урлап җәннәтнең,
Хәләлен сыйлагач та,
Алар Җирдәге тормышның
Иң бөек серен ачкан.

Ачканнар татлы мизгелнең
Җәннәттә тоймаганын
Һәм читкә кагып гөнаһның
Әхлакка сыймаганын.

Яралтылгач пар-пар булып,
Күк әмерен кем бозган?!
Ник наз тели ирләр — ирдән,
Хатын-кыз... хатын-кыздан?!

## *Ышанасы килә*

Толымнары кара кайгы сыман...
Алдаганнар —
Бардыр бушанасы.
— Ышанмасын!
Ә кыз елый-елый:
— Ышанасым килә, ышанасым...
Ул, фәрештәм, диеп йөртте мине —
Ничек горур җаның кымшанмасын:
Ул, яратам, диде... Мәхәббәтнең
Сафлыгына килде ышанасым.
Толымнары озын...
Зиһен тузган...
Кай арада әле яшьлек узган —
Ул мөлдерәп карый үткәненә...
Гыйбрәт алсак иде шушы кыздан.
Без, ир-атлар, беркатлылар түгел —
Язмыш безне ничек тышаулasын?
Тик шулай да кайчак җир йөзендә
Бар нәрсәгә килә ышанасы.
Әйтерсең лә инде бу дөньяның
Мәкере юк бер дә, ялганы юк.
Әйтерсең лә татлы вәгъдәләрнең
Матур әкият булып калганы юк.
Ышанасы килә көләч йөзгә,
Ышанасы килә тәмле сүзгә,
Атар таңның алсу булырына,
Йөрәкләрнең ярсу булырына,
Чәчәкләрнең гел пакь булырына,
Хыялларның гел ак булырына,
Өметләрнең якты булырына,
Бар дөньяның яхшы булырына
Ышанасы килә...
Ышанасы килә!

## *Хөкем*

Хисләр инде тәмам тупасланган —
Юш килдеме яшьли юрауларга,
Җавап таба алмыйм «Сөясеңме —
Сөймисеңме?» дигән сорауларга.
Көзгеләрдән карыйм йөзләремне —
Бөтенесе элеккечә кебек;
Ә күңелнең яшерен бер читендә
Дориан Грей[1] тора усал көлеп.
Гөнаһлар зур, алдашулар байтак —
Вәгъдәләрне артык күп бирелгән;
Сизәм, сизәм — хисап көне җитсә,
Калкыр алар җанның бар җиреннән.
Көзгедә яшь егет — элеккечә —
Кемнәргәдер була әле ярап.
Тик Дориан Грей рәсеменнән
Инде бетәшкән карт тора карап.

---

[1] Инглиз язучысы Оскар Уайльдның мәшһүр романы каһарманы.

## V

*Энекәшләр, сеңелкәшләр бездән*
*Мирас итеп алсын бу таңны да,*
*Яшәешкә гыйбрәт кирәк чакта*
*Хәтерләсен безнең заманны да.*



## *Мәрхәбә, Яңа ел!*

Сөенечкәдерме, көенечкәме
Замананың шаулы агышы —
Ишетелә еллар аръягыннан
Инде яңа чорлар тавышы.

Без күрәсен башка башлар күрмәс —
Давылда без шактый чыныккан.
Ышанабыз әле, зур хыяллар
Әверелер, диеп, чынлыкка.

Яхшысы да, яманы да булыр —
Сикәлтәләр аша юлыбыз.
Ә шулай да изге теләк телик:
Котлы булсын Яңа елыбыз!

Ул Яңа ел алга барыш булсын,
Ниятләргә ныклык өстәсен.
Яз булсын да, кояш нурлап торсын
Илебезнең һәрбер иртәсен.

Табыннарга ямь һәм кот өстәсен
Яңа хисләр тулы яңа җыр.
Беравыздан чакырыйк без аны:
— Хуш киләсең, әйдүк, Яңа ел!

## *Кыш иртәсе*

*(Этюд)*

Тымызык һава. Зәһәр суык
Талчыбыкларга сыра.
Төз каеннар моңсу, боек,
Ак шәлдән басып тора.

Ишек ачуга, битеңә
Суыкбай килеп куна.
Шаярган төсле итенә,
Аннан чеметеп куя.

Ялкау кояш йокысыннан
Өшеп-туңып уяна.
Күк йөзе, чытлык кыз сыман,
Алсу төскә буяна.

Суга китә ал шәлләрдән
Яшь кызлар вак-вак басып,
Бизәкле көянтәләргә
Зәңгәр чиләкләр асып.

Ак бәсләрен зәһәр суык
Шәл-бүрекләргә сыра.
Иртә тудым дигән кебек,
Шатланып авыз ера.

## *Әби белән Нәби*

Карлар ера-ера,
Әби суга бара.
Авыл коесына
Шактый ерак ара.

Йә сөртенеп ала,
Йә төртелеп кала;
Тормыш итүләре
Ялгыз кыен аңа.

Аның атлауларын
Күргәч беркөн Нәби
Чиләкләрен алып
Әйтте: «Яле, әби,
Җилтерәтеп кенә
Үзем илтеп куйыйм —
Әле көн бик озын,
Көтеп торыр уен».

Һәр көн, карлар ерып,
Суга бара Нәби.
«И тәүфыйклы җан», — дип
Рәхмәт укый әби.

* * *

Ап-ак кар каплаган
Җир йөзен.
Моңая киң алан
Көн озын.

Янына, кешеләр,
Килмисез,
Нигә соң, дус-ишләр,
Белмисез
Ялгызга күңелсез
Икәнен?
Җәйнеңме көтәсез
Җиткәнен?
Ал чәчәкнең мәллә
Атканын?
Йә яшьлекнең мәллә
Кайтканын?

Ап-ак кар җир йөзен
Каплаган.
Моңая көнозын
Киң алан.

## *Яшенле яңгыр*

Болытлар каплады кинәттән офыкны,
Сызылып килгәндә таң нуры.
Һәм койды шыбырдап гүзәл май аеның
Беренче яшенле яңгыры.

Яуды ул озаклап, юды ул һәрьяклап
Назларга сусаган җир тәнен;
Күрәсең, күкләр дә, бүлмик дип эшләрен,
Чәчүләр беткәнне көткәндер.

Кыр, болын, урманнар яшелдән киенде,
Бар гөлләр — сөмбелләр сөенде.
Бу гүзәл мизгелдә көтүләр кала бит,
Ява дип кайгыра кем инде?!

Калсын ла көтүе... Мөһиме — күңел шат,
Ниятләр ае бит бу майлар;
Иртәнге намазда яңгырның шифасын
Муллыкка юрыйлар бабайлар.

Тын гына туктады гөрләвек җыры да,
Җанланды җиһанда бар тере;
Һавада игенче өмете шикелле
Сызылды салават күпере.

## *Сөекле матур калам*

Казаным минем, Казаным,
Сөекле матур калам,
Гүзәллегеңә мин синең
Көн саен хәйран калам.

Инде мең яшең тулса да,
Син һаман яшьтер кебек;
Таңнарың ата алланып,
Кояшың чыга көлеп.

Урамнарың киң һәм иркен,
Бакчаларың чәчәкле.
Әйтерсең безгә телисең
Иң матур киләчәкне.

Горурлык хисе уятып,
Йөрәктә дөрли ялкын.
Яшә син, гүзәл башкалам,
Яшәсен сөйгән халкым!

* * *

Яз атлый җирне яшәртеп,
Яшәүгә өмет биреп,
Гаҗәпләндереп һәркемне
Сабый күңеле кебек.

Шуңа ашкын күңелләр дә
Зәңгәр күк сыман аяз,
Таң калырлык гамәлләргә
Илһамчы булыр бу яз.

Ямьгә күмеп бөтен җирне,
Күктән нур ага ташып…
Планета май җырын җырлый,
Планета язга гашыйк!

## *Нинди икмәк тәмлерәк?*

*(Күрше малае Нургали, сабанга җигелгән сыер, малайлар үстергән иген турында хикәят)*

— И-сән-ме-сез?
— Исәнме?
Ә-ә-ә! Синмени, Нургали?!
Йә, курыкма, кыю дәш...
Нишлисең бит, булгалый...
Үпкәләмә беркөнне
Колагыңны борганга.
Шулай килеп чыкты шул,
Әйбәт кенә торганда...
Мин дә кызып киткәнмен...
Ләкин юкка кызмадым —
Син ипине футбол итеп
Уйнаганга түзмәдем.
Ипигә дип барышмы?
Әйдә, мин дә кибеткә...
Төшке ашка утыргач,
Карыйбыз — ипи беткән.
Әле ярый кибет бар —
Барасың да аласың,
Йә агын, йә карасын,
Күмәчен һәм калачын.
Ә мин әле хәтерлим
Ачка интеккәнемне,
Синең кебек чакларда
Игеннәр иккәнемне.
— Минем кебек чактамы?
— Әйе...
Миңа ун иде...
Әти сугышта иде...
Язгы матур көн иде...

Мин әнигә ияреп
Кырга киттем.
Ерак кыр...
Сыерлар җир сөрәләр...
— Ә атлар?..
Ә трактор?..
— Трактор да, аты да
Ул заманда санаулы:
Сабанга да җиктеләр
Сыер — юеш танауны.
Китә барды фронтка
Арыш, бодай, арпалар.
Эш эшләргә авылда
Әниләр дә апалар.
...Әни бик арган иде —
Тырысын миңа бирде;
«Улым, шушы бөртекне
Җиргә сибеп чык», — диде.
Киттем буразна буйлап
Селтәнеп тә төртенеп,
Язгы юеш кәсләргә
Адым саен сөртенеп.
Кара тиргә батсам да,
Сер бирмәдем әнигә —
Сиздертмәдем арганны,
Зарланмадым.
Ә нигә
Иркәләнеп торырга —
Күбрәк тутыр тырыска!
Әтиләр бит сугышта —
Җиңү өчен тырыша.
Язлар үтте, җәй җитте —
Игеннәр буй сикертте;
Шатланып кырда йөрдем —
Мин бит икмәк үстердем!

Сары басу өстендә
Чалгылар да ураклар.
Көлтә бәйли әниләр —
Арта бара зуратлар.
— Ә нәрсә ул — «зуратлар»,
Атларның зурысымы?
— И, ул чакта син безнең
Күрсәң ул тырышуны!
Комбайн юк, атлар аз,
Атның зуры — тик төштә.
Урак өсте авылда —
Яше-карты гел эштә.
«Бәләкәй генә бөкре
Бөтен кырны бетерде», — дип,
Элек халык уракны
Гел шулай атап йөрде.
Ул чакларда сез белгән
«Колос», «Нива»,
«Дон»нар юк...
Лобогрейка дип йөрткән
Ат ургычын җыйнадык.
Җилпи-җилпи канатын,
Келтер-келтер бара ул.
Игеннәрне камылга
Учма-учма сала ул.
Ә апалар, әниләр
Аның арттан селтәнеп,
Тузмасын дип, нык итеп,
Билен бәйли көлтәнең.
Без — малайлар аннары
Тырма белән тырмыйбыз.
Калмый җирдә бер башак —
Арыйбыз дип тормыйбыз.
Көлтәләрне кибүгә —
Көтә ындыр табагы.

Дөп-дөп төшә башакка
Чукмар башлы чабагач.
Алтын төсле саламның
Сарысына тимә хет.
Асларында — бөртекләр!
И сөенеч, и бәхет!
И беренче ашлыкның
Кабартмасы, коймагы!
Шундый тәмле!
Аз булгач,
Тамак кына туймады.
И Нургали, Нургали,
Син икмәкне юл буйлап
Футбол итеп типкәндә,
Мин шуны алдым уйлап.
Хәзер безнең халыкка
И яшәүләр җиңел соң!
Үпкәләмә,
Мин беләм —
Начар малай түгел син.
Үкенерсең — ышанам,
Үкенерсең хатаңа.
Без бит әйбәт кешеләр...
Әйбәт кеше атаң да,
Тоз сипмәссең аның да
Җанындагы ярага.
Әләкләшмик, безнең сер
Калсын ике арада.
Сизәсеңме — хуш исләр!..
(Игътибар ит аңа син!)
Димәк, безгә икмәкнең
Китергәннәр яңасын.

## *Борчак һәм тугыз капкорсак*

Безнең борчак кырында
Тугыз симез капкорсак
Уздырыша-уздырыша
Чүпләп йөри яшь борчак.

Беренчесе Бирән, ди,
Инде ачтан үләм, ди,
Икенчесе Исәр, ди,
Бертуктамый күшәр, ди,
Өченчесе Өтек, ди,
Кигән тишек итек, ди,
Дүртенчесе — Дивана,
Ни борчак, ни корт аңа,
Бишенчесе Биштәрле,
Биштәрендә — биш тәре,
Алтынчысы Ахмак, ди,
Кабатлый гел такмак, ди:
— Борчак, борчак, капкорсак,
Безнең корсак — шәп корсак.
Җиденчесе... Җирән ич!..
Үзе бигрәк җирәнгеч,
Сигезенчесе Симез, ди,
Ашый көнгә сигез, ди,
Тугызынчысы Туймас, ди,
Борчакны һич куймас, ди.

Тугыз ачкүз — капкорсак
Ашыйлар, ди, һәй, борчак,
Безне да кабып йотарлар,
Авыз ачып тик торсак, —
Дидек тә без, малайлар,
Җыелышып киңәштек,
Капкорсакларны борчактан
Биздерергә сөйләштек.

— Әгәр алтатар корсак...
— Көпшәсен кырга борсак...
— Куркытып тамак кырсак...
Нишләр тугыз капкорсак?

Алтатарны кордык без,
Аны кырга бордык без,
Тамакларны кырдык без,
Куркырлар, дип тордык без,
Курыкмады берсе дә...
Нилектән? Сәбәп нидә?..
Алтатар дип, аның без,
Белмәгәнбез җаен без...
Борчак белән корганбыз,
Кире якка борганбыз.

Аптырашып тордык та,
Дары салып кордык та,
Ут кабынып ялт итте...
Һәм алтатар шарт итте.
Шуннан тугыз капкорсак
Тотындылар чабарга,
Ыграк курыксыннар дип,
Без калмыйбыз алардан.

Капкорсаклар, әй, чаба...
Чаба Каф тауга таба.
Бирән берзаман арып,
Бишмәтен атты салып,
Исәр иске ыштаннан,
Ычкырлары бушаган,
Тишек башлы итек тә
Төшеп калды Өтектән.

Бишенче — күр! — нишләве...
Тишек икән биштәре,
Үзе «Ах!» иткән була —
Борчаклары коела,
Ахмак инде ул — ахмак —
Кабатлый һаман такмак:
— Борчак, борчак, капкорсак,
Безнең корсак — шәп корсак...
Җирән, Симез һәм Туймас
Инде килергә кыймас —
Капкорсаклар — әт-тә-тә! —
Котлар очкан, әлбәттә,
Чабалар абына-абына,
Туп-туры Каф тавына.

Ә анда, Каф тавында
Утыра ялгыз гына
Корсагын кашый-кашый,
Аждаһа — тугыз башлы.
Шунда күреп алды да
Капкорсаклар узышын,
Берәм-берәм кабып йотты
Тугыз башы тугызын.

Без шаккатып тордык та
Кире чаптык авылга.
Без күргән бу маҗара
Онытылмас дип, мең ел да.
Бөтен халык бу хәлне
Көлә-көлә тыңлады!
Тик нигәдер беркемне
Ышандырып булмады.

Берчак борчак өлгерде —
Җыеп алдык яхшылап,
Амбарларга ташыдык
Һәм куйдык җиңел сулап.
Тегермәндә тарттырып,
Пешекчегә бирделәр,
Бөтен авылга җитәрлек
Чумар да пешерделәр.
Бигрәк тәмле чумары, дип,
Әллә кемнәр сөйләде.
Бөтенесе сыйланды, тик
Миңа гына тимәде.

## VI

*Тәүфыйксызмындыр мин... тыныч кына*
*Матурлыкны мактар урында,*
*Йә илереп аһлар, яшьләр түгәм,*
*Йә шаркылдап көләм... җырымда.*



## *Карурманда киңәшмә*

*(Мәсәл)*

Закон — тайга, медведь — хозяин.

*Урыс мәкале*

Карурманда зур киңәшмә җыйды Аю —
Өстән булгач әмер, ай-һай, бармый кара!
Җыелдылар пошилар да, бүреләр дә,
Төлкеләр дә, керпеләр дә, еланнар да
Тартар белән җитәкләшеп килде челән,
Ябалак та соңармады байгыш белән,
Килде бурсык, килде карга, килде куян,
Былбыл, күке, тукран, көртлек һәм саескан.
Карурманда күпме булса җан иясе —
Һәркайсының шәхси делегациясе.

Башта Аю әфәндегә сүз бирелде —
Ул вәкарьле тавыш белән болай диде:
— Безнең ошбу демократик карурманда
Тату яши, бердәй тигез һәммә җан да.
Һичкайсыбыз рәнҗетелми һичбер кемнән —
Без һәммәбез Аю дигән бер нәселдән.
Бөҗәкме без, җанвармы без, кош-кортмы без —
Минем сыман бер үк Аю токымы без,
Сөйләшергә кирәк безгә бер үк телдә —
Торабыз бит демократик азат илдә...

Алан шуннан тынып калды берәр мәлгә,
Ачык җавап табалмыйча мондый хәлгә.

Аннан чебен кунды очып трибунага —
Телмәрен бит Аю язган иде аңа:
— Гәрчә мине филгә тиңләп зурлыйлар да,
Ризамын мин Аю кебек булырга да...

Тукран исә үз туксанын тукылдады,
Тик берәү дә: «Рег-ла-мент!..» —
дип кычкырмады.
Санап китте:
— Беренчедән...
Икенчедән...
Пункт-пункт тезеп чыкты әллә ниләр.
Ә чыгышы булды аның шундый озын,
Ләкин һичкем аңламады әйткән сүзен.
Чебен әйткән фикерләрне өнәмичә,
Куертмакчы иде сүзне әллә ничә
Мескен куян: «Сүзем юк шул...» —гына диде,
Чөнки Аю кырын карап куйган иде.

Тартар белән челән генә карыштылар,
Фәнни яктан дәлилләргә тырыштылар:
— Телебез бит, урмандашлар, төрле-төрле,
Кемдер улый, кемдер сайрый, кемдер гүли!..

Чәчрәп чыкты шулчак төлке — көлтә коерык:
— Аю әйткән тәкъдим безгә булсын боерык...
Киңәшмәне бик озакка сузмас өчен,
Мин тавышка куям, — диде,— Аю фикерен.
Нәтиҗәсен карыйк... Ачык болай да бит —
Туксан тугыз бөтен уннан тугыз процент.

...Бу мәсәлнең мәгънәсе ни, диярсез дә,
Әйтсәң — сүз шул, төрттең исә чыга күз дә.
Хакыйкатен яшәешнең күрер кем дә —
Бер әйләнеп карасын тик тирә-юньгә.

## *Исерек кырмыскалар*

*(Мыс һәм Ка кушаматлы ике салмыш кырмыска турында уйдырма кыйсса)*

Мыс эшкә дип барганда
Юлыкты буш шешәгә,
Әй бу юньсез адәмнәр
Лыкынганчы эчә дә
Ташлап китә шешәсен.
Кырмыска соң нишләсен? —
Урап үтәргә кирәк йә
Кире китәргә кирәк.
Булыр диеп, юл кыска,
Туры китте кырмыска;
Ә шешәдә ни дисең...
Бәй, аракы диңгезе.
Миңа да бит ярыйдыр,
Яле, татып карыйм дип,
Эчкән иде — көч керде...
Һәм Мысыбыз исерде.
Әй җырлый Мыс, әй җырлый,
Кырмыска илен зурлый —
Чикерткәләр, коңгызлар... —
Һичбере чүп тә тормый:
— Әй кырмыска, кырмыска,
Үтмәсен гомер бушка...
Әй ямьләнде дөньялар —
Бер кайгым юк тормышта.
Ашарга табасы юк,
Гөбләләр савасы юк,
Өй салам дип аптырап,
Еракка чабасы юк.
Менәсе юк, төшәсе,
Тирләп-пешеп эшләсе,
Комнан аркан ишәсе, һәй,
Аунап ятсын шешәсе...

...Очратты ул Каны да,
Сыйлыйм диеп, аны да
Алып керде шешәгә:
— Ка дускаем, эч әйдә...
Исерделәр Мыс һәм Ка —
Эчтеләрмени юкка;
Киттеләр икәү җырлап,
Кырмыска халкын хурлап:
— Әй кырмыска, кырмыска...
Гомерләр үтә бушка...
Бөтен дөнья түгәрәк лә —
Типтереп кал тормышта...
Батырайды хәтта Ка —
Китереп типте ташка.
Эшләүче бар кырмыска
Дошман бу ике дуска.
Кайсын төртеп ектылар,
Ә кайсына сукты лар,
Гел эшләтә безне, дип,
Кыр патшаны сүктеләр.
Һәр уңган кырмыскага
Туктаусыз үч иттеләр...
Өйгә кайтып йоклагач,
Урынга пес иттеләр.
...Иртәгәсен җыелды
Кырмыска халкы съезды —
Тикшереп Мыс һәм Каны
Фикерләр шундый кызды.
Бертавыштан бу съезд
Шундый карар чыгарды;
Шешәне ләм белән Кыр
Лично үзе сылады.
Кырмыскалар патшасы
Кыр тамагын кырды да
Мыс һәм Каны куарга
Хөкемен әйтте шунда.

Кайгыралар Мыс һәм Ка —
Ике сәрхуш кырмыска;
Дөньялар көтәсе бар,
Салкын кыш җитәсе бар...
Инде хәзер нишләргә?
Ни ашап, ни эчәргә?
Бергә булган рәхәт чаклар
Керер инде төшләргә.

* * *

Баш шәрифләренә акыл кирәк тә —
Хатын булып аннан алда тел чаба...
Бу мәгънәсез дөньядагы хәлләрнең
Бер асыл мәгънәсен эзләп кем таба?!
Бар нәрсәгә була көлеп карап та—
Тормыш уен булса да бик кыен бит;
Хатын-кыз баш түгел дә, ләкин башны
Як-якка бора алучы муен бит.

Ниләр генә булды соң бу дөньяга —
Акыллы башны да узып тел чаба;
Туксан тугыз мәгънәсез сүзгә каршы
Берданбер мәгънәле сүз табып кара?!
Фәгыйләтен, фәгыйләтен, фәгыйләт —
Дөньяның бу хәлләренә ни сәбәп?!

## *Төш күреп уянгач, төн уртасында язган шигырь*

И кара эт, кара эт,
Төшләремә керден дә
Бүлдең татлы йокымнан,
Һаулый-һаулый өрдең дә.

Ыржайткансың тешләрең —
Төштә тешләр идеңме?
Син ташлангач, мин әллә
Җебеп төшәр, дидеңме?

Мин тагын бер эт күрдем
Шул ук төштә — ак иде;
Синдәй разбуй салмады —
Кулларымны ялады.

Бу дөньяның төсләре
Кара белән акмыни?!
Кара эт — кара язмыш,
Дигән сүзләр хакмыни?!

Без бу җирдә агын да,
Карасын да күтәрдек —
Язмышларны узарга
Әле гайрәт җитәрлек.

Ул кадәрле шашынма,
Шашынсаң — үз башыңа;
Кара язмыш, читләп үт —
Чәбә-чәбә, кара эт!

## *Тәүфыйксызлар*

Җитдиләнеп җитеп булмый әле, —
Малайларча бөтен кыланыш…
Малаем да инде үзем буе,
Тик күренми һаман кылган эш.
Ятимнәрдә хыял гел ал була —
Мин атадан сабак алмаган;
Хәяттан мин тоташ наз көткәнмен,
Ә ул мине тоташ… алдаган.
Кайберәүләр юкса салмак кына,
Уч төбендә үлчәп һәр сүзне,
Акылны да инде байтак сатты,
Ышандырып үзен һәм безне…
Мин — тәүфыйксыз, никтер тыйнак кына
Сын катырып йөрер урында,
Йә илереп аһлар, яшьләр түктем,
Йә шаркылдап көлдем җырымда.
Югыйсә мин былбыл биеткәндә,
Ана карынындагы егетләр
Иң кимендә бүген «йә Дәрдемәнд»,
«Йә Бабич», «йә Такташ» кебекләр.
Чебенгә һәм кандалага каршы
Кылыч болгап күпләр ат алды;
Биш ел элек язган шигыре өчен
Һәр җыелыш саен макталды.
Әй мәдхия яуды һәр тарафтан,
Әй багланды олуг өметләр;
Тик… шигырьгә ясин укыдылар
Бу эшлекле тәти егетләр.
Ә иманын байрак итә алганнар
Елгырлыкта гәрчә калышты,
Дөньякүләм яу кырына чыгып,
Аждаһалар белән алышты.
Бүген алар хаклык кануннарын
Йөрәк каны белән язалар;

Тик аларга түгел фимиамнар,
Дәрәҗәләр, диплом-мазарлар.
Дипломсыз да җирдә яшәп була,
«Җитди» булмаса да кылган эш;
Малайларча булсын ләкин хыял,
Шагыйрьләрчә булсын кыланыш.

## *Җыелыштан соң...*

*(Җитәкче урындыгы белән стена аркылы сөйләшү)*

Сез инде ял итә торгансыздыр —
Кабинетта тындыр, урын нык...
Хыялымда гына дәшәм Сезгә:
— Исәнме Сез, иптәш Урындык?!

Миңа юкса бары имза кирәк —
Рөхсәт кирәк кадак кагарга...
Инстанцияләрдә килешенгән...
Чыгарылган хәтта карар да...

Ике сәгать буе көттем дә бит,
Көтәр идем тагын... «Кал!» дисә...
Җыелыш бетте... ә ул чыгып китте,
Минем якка күз дә салмыйча.

Сездә утырган ул адәм миңа
Күптән таныш — бергә укыдык;
Бер тиенгә тормас малай иде —
Кеше итте үзен Урындык.

Хәзер килеп аңа баш иябез,
Ә ул башын ия башкага...
Замана бит: мәҗүсиләр әнә
Баш игәннәр, диләр, ташка да.

Сез горурдыр, Сезгә шундый хөрмәт —
Сез назлыйсыз аның арт санын;
Кайчак аннан нотык сөйләтәсез,
Өстәл төйдерәсез кайчакны.

Көчле шул Сез, шуңа бар түрәләр
Ике куллап Сезгә ябышкан,
Үзләренең исә коты оча
«Хәбәрдарлык» дигән тавыштан.

Киңәш итеп кенә әйтәм Сезгә:
Бюрократка инде урын юк —
Надан башлы андый түрәләрдән
Котылыгыз, иптәш Урындык.

## Дөнья бу!..

Читен тормыш, капиталга тукынмасаң...

*Г.Тукай*

Түрәләр шундый тәкәббер —
Йөз ертып үтенмә дә;
Сәлам бирергә кирәктер
Аларның этенә дә.

Ялагай булганга түгел,
Юк артык нидер теләү —
Дөньяда ләкин юньлерәк
Яшәп карыйсы килә.

Капитал атлы аждаһа,
Атланып муеныңа,
Уңга йә сулга борырга
Әмерләр бирә сиңа.

Кыйблаңны синең сорамый,
Төкерә фикереңә,
Һәм акча атлы әфәнде
Йөгәнләп йөртә бирә.

Түрәгә түрә булырлык
Бер тылсым тапсаң инде! —
Ул чакта аның эте дә
Сәламнәр бирер иде.

Дөнья ул... катлы-катлы шул:
Өстән һәм астан тора;
Сиңа ни кирәк дигәндәй,
Замана авыз ера.

## *И заман!*

Заманы шундый (нишлисең?!):
Шәрехләпниләр языйм?!
Шулай да ахмакны «ахмак»
Дип тукый тору лязем.

Син «ак» дисең, ул «кара» дип,
Гел үзенчә сукалар;
Дәлилләрме? Фәнниләрме? —
Аның өчен юк алар.

Ахмакка тинтәк ияргән,
Тинтәккә ... тиле-миле;
Әйтегезче: кай тарафтан
Исә бу афәт җиле?!

Монафыйклар басты илне —
Тыярмын, димә һич тә;
Бер үк бизмәндә үлчәнә
Фәрештә дә, Иблис тә.

Язганда «Локман хәким»ен
Исхакый атлы даһи
Шундый көн килер заманны
Күздә тоткан, билләһи.

Без күрәсен, йә, кем күрсен —
Ходай, дибез, язгандыр;
Бу — кылынган гөнаһларга
Тарихи бер җәзадыр.

Заманга сылтарсың да бит —
Аны да фашлыйсы бар.
Намусың ваклап сатмыйча,
Бу җирдә яшисе бар.

## *Замана такмаклары*

Нигә миңа политика,
Тыныч кына ятыйм, дим,
Суверенный ире булып
Суверенный хатынның.

Заманыбыз бигрәк мәзәк:
Ниндие юк законның?!
Приватизацияләнү —
Исәпләре хатынның.

Мин каршысын каршы түгел,
Түлисе дә сөясе;
Ләкин эшкә аяк чала
Акча эмиссиясе.

Кесә такыр — ул хатынга
Ничек алыйм «Аляска»,
Эшебездә конверсия —
Чыгарабыз коляска.

Әй җанашым, бигрәк инде
Күтәргәннәр хакыңны!
Әллә бартер юлы белән
Алыйм микән хатынны?

Компенсация бирсәләр,
Бәлки әле җитәр дә
Шул законный хатынымны
Үземнеке итәргә.

Ә конфетлар, перәннекләр,
Ит, сөт, май, тоз, колбаса
Кайсы кибет бирер, дисең,
Купоннарың булмаса.

Тагын шундый проблема:
Кайдан табыйк «ярты»ны.
Запрос бирик әле, дуслар,
Депутатлар аркылы.

Сакалбайлар рәхәт яши,
Сүз сөйли дә су эчә,
«Регламент!» дип чәчрәп чыга,
Законга юл бирмичә.

Әй сессия, сессия лә,
Синдә бик зур миссия.
Бу тормышны рәтлик әле,
Төзеп бер комиссия.

## *Ходай ярлыкасын...*

Әхлак читәннәрен урый-урый,
Күз төштеме берәр матурга,
Иблис белән икәү култыклашып
Йөргәләдек гыйшык сатырга.

И урланган бәхет, татлы җиңү!
Ә соңыннан... яну кирәктә,
Пүртәнкәңне киптерерлек кенә
Мескен бер ут пыскый йөрәктә.

Цезарь хатыны да гыйффәтлеккә
Беләсез бит! — дәгъва итмәгән.
Байлык һәм дан — һәммә нәрсә булган,
Тик барыбер ... нидер җитмәгән.

Баш очында кояш елмайсын да,
Тәннәрдән дәрт ташып торсын да,
Кыен үтеп китү кызыкмыйча
Таза бәдән, зифа буй-сынга.

Патшаларны хәтта сугыштырып
Һәм мәхәббәт татып канунсыз,
Күпме фаҗигагә сәбәп булган
Гайрәтле ир, назлы хатын-кыз.

Югыйсә бит бу дөньяда бары
Пар аккоштан үрнәк аласы...
Гөнаһларны Ходай ярлыкасын —
Без бит фәкать Адәм баласы.

Оҗмахлардан куып чыгарылган
Атам Адәм, анам Хава да;
Бер алманың серен белгән өчен
Дучар ителгәннәр җәзага.

Ә безгә соң... безгә ни эшләргә? —
Яшәүнең бит бар үз кануны;
Адәм гөнаһлары мирас икән,
Кирәк бары шуны тануың.

Гөнаһларны юып булмасмыни
Ходай каршысына барып та...
Без кешелек яралганнан бирле
Ялварабыз:
— Үзең ярлыка!

## *Җыр бар чакта*

Тыныч кичтә ай балкышы,
Кызлар эштән кайталар;
Сандугачтан откан җырны
Әйтәләрме әйтәләр.

Юлларына юлыкты да
Ниндидер бер бәндәсе,
Көлгән булды: «Җырларыгыз
Тара-бара», — янәсе.

Китеп барды алпан-тилпән,
Йөрәк рәнҗеп какса да,
Шовинистик таш ыргытып,
Безнең милли бакчага.

Тынып калды сандугачлар,
Сискәнделәр каеннар...
Өзгәләндем, шуларны, дим,
Юатыр ни җаем бар?

Кимсенмәгез әле, кызлар,
Телләшә, дип, бер явыз;
Үз илебез, үз җырыбыз,
Җыр бар чакта җырлагыз.

* * *

Бауман урамыннан тотам юлны.
Кызлар килә — абау, чибәрләр!
Һәм берсенең назлы елмаюы
Күңел кылын чиртеп җибәрә.

Кара, кызый! Елмай елмаюын,
Тик синең өчен
Сөю дигән нәрсәм калмады;
Бик күпләргә мин өләштем аны,
Кисәкләргә бүлеп алмадай.

Күзләремдә инде җорлык беткән,
Күкрәгемдә ялкын сүрелгән —
Тик нигә соң, әйтче, мин нилектән
Сиңа гашыйк төсле күренәм?

Әллә булгач кашнэ, эшләпәдән,
«Зур кеше» дип мине уйлавың?
Бу бит инде синең ничәнче кат
Эземә басып урам буйлавың...

Син белмисең минем үткәнемне,
Син белмисең ни бар уемда,
Тын бакчада кемне үпкәнемне,
Йоклавымны кызлар куенында.

Мәрфуга да, Берта, Наташа да
Авыз иткән минем иреннән —
Туйдым сөю дигән саташудан:
Тел кагарга хәтта иренәм...

## *Трамвайда*

Трамвайга чибәр бер кыз керде —
Күзләр аны тик бер мизгел күрде;
Ләкин йөрәк кинәт шашып типте —
Ул шулкадәр сокланырлык иде.

Трамвайда исә халык... шыгрым —
Кымшатырлык түгел аяк астын,
Өстәвенә, чибәр кызны каплап,
Арага бер әби кереп басты.

Үрелеп тә карыйм, күрим диеп,
Якынаймак булам кызга таба,
Әмма шыр сөякле озын әби
Һаман кызны карар юлны яба.

Кайдан килеп чыктың соң син, әби,
Өйдә генә утырсаң, ни булган?!
Бу пик сәгатьләрдә синнән башка
Болай да бит трамвай шыплап тулган.

Соңгы тукталышта төште халык,
Сүгә-сүгә төште кемдер кемне,
Вагон бушап калды, ләкин инде
Анда мин кызыккан кыз юк иде.

Трамвайда мин дә әби генә...
Шул әбекәй генә эшне бозды;
Күзләр туйганчы да күрми калдым,
Ни кызганыч, шундый чибәр кызны.
Их, син, әбекәй!

## *Ике әтәч*

Әтәч менгән читәнгә
«Ки-ке-ри-кү-үк!» итәргә;
Әтәчкә повестка килгән
Армиягә китәргә.

*Шаян җырдан*

Уң як йортта — яшь әтәч,
Сул як йортта — карт әтәч;
Яшенә күрсәттеләр,
Кайсы китә, дип әйткәч.
Кайгы төште башына
Әтәчләрнең яшенә;
Армиягә кит, имеш,
Җитлегеп җиткәч кенә.
И шатлана карт әтәч,
Китә диеп, көндәше;
Аның тавыклары да
Инде аңа күчәсе.
Юкса бик азган иде,
Юлыннан язган иде,
Аның хатыннарының
Гыйффәтен бозган иде.
Ачуыннан карт әтәч
Сугышып та карады,
Ләкин җиңә алмады —
Тик канаты канады.
Күп уйланды яшь әтәч,
Юлын тапты эзләп тә;
Калдырсыннар соң аны
Альтернатив хезмәткә!
Язды бик шәп гариза,
Уйлап язды һәр сүзен;
Шушы ике йортта, дип,
Фактически берүзем.

Демократик дөньяда
Болаймы соң алдыйлар;
Армиягә... «годен» дип...
Карт әтәчне алдылар.
«Утны-суны кичкән ул,
Туксан тугыз сугышкан,
Хәзерге яшьләр кебек
Качып йөрмәс сугыштан».
Карт әтәчне шулай дип,
Мактаулар тага-тага,
Контракты төзетеп
Җибәрделәр Чечняга.
...Яшь әтәчнең эш худта —
Берүзенә йөз тавык;
Арып бетә көнозын
Шулар артыннан чабып.
Берүзең йөз тавыкка
Дәртле ир булып кара!
Алдандыммы әллә дип
Үкенсә дә... ни чара?!

## *Былтыргы күкәй*

*(Мәсәлме, мисалмы?)*

Әй кытаклый тавык, әй кытаклый —
Әйтерсең лә алтын күкәй салган;
Ул чәберчек күкәй юкса былтыр
Оя өчен мая булып калган.

Тирләп-пешеп берәү «шигер» яза.
Бик тиз генә танылырга — уе;
Чәлдерде дә фикер бөекләрдән,
Бик канәгать калып кулын куйды.

Дан казанып калу иде — ният,
Килеп чыкты пшик... плагиат.

## *Кайбер әсәрләрне укыганда...*

Саф татар сүзе белән дә
Русча язып була;
Бәйнәлмиләл кемнәргәдер
Шул тел «язык» була.

Иясе бар, хәбәре бар —
Фәкать җөмлә җыйна;
Бар сүзләр татарча... ләкин
Аңлашылмый гына.

## *Карьерист*

Гәүдә төп-төз, әйтерсең лә
Уклау йоткан;
Башта бушлык, әмма кулга
Портфель тоткан.

Вак-төяккә исе китми —
Эре кеше;
Очраганда атасын да
Күрмәс төсле.

Бил бөгәр тик түрәнең дә
Олысына,
Өмет итеп урындыкның
Җылысына...

## *Ходайга шөкер!..*

И Ходаем, ни кылсаң да, кодрәтең киң —
Беләм, миннән рәхмәт сүзе көтмәгәнсең;
Мең-мең шөкер, шушы тәти егетең күк
Мине надан һәм ялагай итмәгәнсең.

## *Тәнкыйтьче портретын ясарга хыялланган рәссамга киңәш*

Табалмассың шәбрәк натурщик,
Хет бу җирне туксан кат ура;
Менә дигән тере халтурщик —
Үз-үзенә карикатура.

## *Китегез!*

Агыйделнең аръягында
Бер инәгә бер сыер...

*Шаян җыр*

Һәр чат саен кемдер разбой сала —
Суверенлык аңа ошамый;
Имеш, Мәскәү хәзер татарларга
Өстәл төеп өстән кушалмый.

Югыйсә бит әле тамагы тук
Һәм заманча тәти киемнән,
Эшләсә дә әпән-төпән генә,
Калдым, ди ул, сукыр тиенгә.

Агыйделнең, имеш, аръягында
Бер инәгә сыер бирәләр,
Милләт диеп анда баш ватмыйлар —
Бәйнәлмиләл һәммә түрәләр.

Китегез соң, монда хөрти булгач,
Алтын ява торган төшләргә —
Адәм рәтле яшәр өчен ләкин
Анда да бит кирәк ... эшләргә.

Китегез соң... урыс... яһүдме син,
Йә иманын саткан татармы —
Аңларга бит кирәк ахыр чиктә
Илгә яный торган хәтәрне.

Сәрхуш Рәсәй һаман бәйрәм итә,
Матәм көне — атна аралаш;
Тернәкләнә алмас, ахры, инде —
Бар җиһанда аңа шул караш.

Бу бәхетсез илдә азмы-күпме
Татарстан имин, нык нигез;
Ошый икән — разбой кычкырмагыз,
Ә ошамый икән ... китегез ...

Китегез хет океан артларына —
Булсын җәннәт, булсын җәһәннәм;
Безнең эшкә генә тыкшынмагыз,
Юлыгызга сезнең ак җәймә —
Анда, бәлки, бәхетлерәк җирдер —
Рәхим итеп шунда китегез!
Китегез!

## *Чукчаны талаганнар*

Акча бездә бер букча,
Дип мактанган бер чукча...
Айныгач тышка чыкса,
Торып калган тик чучка.

Тайгада киек атып,
Шулар тиресен сатып,
Балык тотып... ул аннан
Байтак маллар туплаган.

Бихисап булган сәмән,
Алып кайткан берзаман
Ниндидер бер марҗаны...
Марҗаның да бар җаны!

Валлаһи, түгел ялган —
Туксан урыстан калган
Булса да сасы марҗа,
Чукчага майлы калҗа!

Бер атнамы, бер аймы
Тормышлар барган җайлы;
Марҗа аңа кич-иртән
Тик самогон эчерткән.

Кәефләнгән мәлләрдә
Түзәмени ир җаны!
Кочаклыйм дип марҗаны
Коча икән морҗаны.

Салгач инде, билгеле,
Ак һәм кара күренми —
Марҗадыр дип чукчабыз
Сөя икән чучканы.

Марҗалар бит хәйләкәр —
Туксан тугыз юл табар:
Чукча салып ятканда,
Тү-тү иткән акчалар.

Баеп алган марҗабыз,
Уңмадым дип бу ирдән,
Бер яшь тюремщик белән
Качып киткән бу җирдән.

Башын кашый чукчасы —
Бушап калган букчасы;
Баш төзәтер өчен дә
Җитми икән акчасы.

Марҗа... марҗа... дисәгез,
Вәт шулай ул, җәмәгать.
Бер кат кисәр алдыннан
Уйлау кирәк җиде кат!

## *Биографик белешмә*

Әхмәт Рәшит (Әхмәт Әхәт улы Рәшитов ) 1936 елның 25 мартында Татарстанның Буа районы Яңа Чәчкап авылында туа. Тугыз яшьтән бөтенләй ятим калып, сеңелесе белән бергә әтисенең абыйсы Каюм абзыйның ишле гаиләсендә тәрбияләнә. Туган авылында җидееллык белем алгач, укуын Олы Тарханның беренче номерлы һәм Буа шәһәренең М. Вахитов исемендәге урта мәктәпләрендә дәвам итә. 1954 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә. Ләкин матди кыенлыклар аркасында өченче курстан соң укуын бүлеп торырга мәҗбүр була. 1957—1958 елларда ул Төркестан — Себер тимер юлының Семей кондукторлар резервында эшли. 1960 елда университетны тәмамлагач, аның язмышы журналистика белән бәйләнә. Апас район газетасы, Казан һәм Лениногорск телевидениеләре, «Социалистик Татарстан» газетасы, язучыларның Г. Тукай исемендәге клубы... Лаеклы ялга чыгар алдыннан, ул Татарстан радиосында нәфис тапшырулар буенча баш мөхәррир вазифаларын башкара.

Әхмәт Рәшит әдәбият белән бик яшьли — ун яшьтән үк мавыга башлый. 1952 елда беренче шигырьләре район газетасында һәм «Чаян» журналында күренгәч тә, басма сүзнең тәмен бер татып алгач та, аның иҗаты активлашканнан-

активлаша бара — ул инде калын журналлар ишеген дә шакый башлый. Шигъри көлтәләр, күмәк җыентыклардан соң үзенең мөстәкыйль китабы да дөнья күрә. Аның янына тора-бара икенчеләре, өченчеләре... уникенчеләре өстәлә.

Киң катлау укучыларга Ә.Рәшит иң элек «Беренче мәхәббәт», «Зәңгәр күлмәк», «Күңелләрдә яз булсын» җырлары һәм актуаль темаларга язылган публицистик шигырьләре белән танылa. Аннан ул шигъриятнең поэма кебек киң планлы жанрында да көч сыный. Аның «Минем шәҗәрәм», «Авылдашлар», «Йолдыз вакыты белән», «Варислар», «Ирләр», «Автопортретка штрихлар» поэмаларын әдәби җәмәгатьчелек югары бәяләде, ә «Сөембикә» һәм «Колшәриф» дигәннәре исә Г. Исхакый бүләгенә лаек булды. Эре пландагы бу әсәрләргә соңрак «Мөхәммәдьяр», «Офыклар аръягында», «Без — татарлар» һәм «Казан» поэмалары өстәлде. Шагыйрьнең җыр жанрында эшләве дә активлаша төште — халык арасында шактый киң таралган «Республикам», «Колшәриф мәчете», «Әле кичә генә» һәм башкаларны профессиональ җырчылар да, һәвәскәрләр дә бик тиз күтәреп алды.

Әхмәт Рәшит — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе һәм атказанган мәдәният хезмәткәре.

# *Библиография*

Беренче адымнар: (Шигырьләр һәм поэмалар). — Казан: Татар. кит. нәшр., 1971.— 87 бит, 3.000 (Роза Хәлиуллина, Данис Хәбибуллин әсәрләре белән).

Хатирә: (Шигырьләр).— Казан: Татар. кит. нәшр., 1972.— 95 бит, 3 000.

Сәяхәтнамә: (Шигырьләр).— Казан: Татар. кит. нәшр., 1978.— 79 бит, 4.500.

Кояшлы ил — бәхет иле: (Шигырьләр).— Казан: Татар. кит. нәшр., 1981.— 59 бит, 10. 000.

Киек Каз Юлы: (Шигырьләр һәм поэма).— Казан: Татар. кит. нәшр., 1982.— 64 бит, 5. 500.

Күңел кыңгыраулары: (Шигырьләр һәм поэмалар).— Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.— 192 бит, 1.400.

Давыллар кайтавазы: (Шигырьләр һәм поэма).— Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.— 80 бит, 3.600.

Иман яңартканда: (Публицистика һәм тәнкыйть).— Казан: Татар. кит. нәшр., 1991.— 160 бит, 1.000.

Таң илчесе: (Шигырьләр, җырлар, поэмалар).— Казан: Татар. кит. нәшр., 1996.— 288 бит, 2.000.

Ике гасыр арасында: (Поэмалар).— Казан: «Матбугат йорты» нәшр., 2002.— 160 бит, 1.000.

Фидаиләр: (Тарихи поэмалар).— Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.— 80 бит, 2.000.

Млечный путь: (Стихотворения и поэма. Перевод А.Руденко). — Москва: «Современник», 1983.— 48 стр., 5.000.

## Аның турында

Исхак Ә. Әхмәт Рәшитов // Казан утлары. — 1979. — №10.

Фәйзуллин Р. Яшәүгә ышаныч // Социалистик Татарстан. — 1983. — 17 июль.

Галиуллин Т. Тәрәзәләр язга елмая (Шагыйрьнең «Күңел кыңгыраулары» китабына кереш сүз). — Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.

Л е р о н  Л. Йолдызлы сәйар күңел // Яшь ленинчы. — 1986. — 26 март.

М о р а т о в  Г. Йолдыз вакыты белән // Татарстан яшьләре. — 1986. — 27 март.

Х и с м ә т у л л и н  Р. Һәнүз алга барам! // Ленин нурлары (Түбән Кама). — 1986. — 29 март.

А б д у л л и н  З. Гөнаһларын кая куярсың? // Шәһри Казан. — 1992. — 26 июнь.

Х и с а м о в  Н. Шагыйрьнең публицистикасы // Татарстан. — 1993. — № 6.

Ә г ъ л ә м о в  М. Колшәрифле, Сөембикәле чор // Ялкын. — 1993. — № 10.

А х у н о в  Г. «Колшәриф»кә килү юлы // Ватаным Татарстан. — 1994. — 18 февраль.

А к м а л  Н. Кулъяулыктагы язу // Мәгърифәт. — 1996. — 2 август.

В ә л и  Р. Әтиләрсез үскән буыннан без... // Шәһри Казан. — 1996. — 23 март.

М и ң н е г у л о в  Х. Бөтен язмышым — шигырьләремдә // Ватаным Татарстан. — 1996. — 22 март.

Ә г ъ л ә м о в  М. Хакыйкать эзләп // Казан утлары. — 1996. — № 3.

Г а л и у л л и н  Т. Тарих мизгелләре... // Казан утлары. — 1997. — № 8.

У р м а н ч е  Ф. Шигырь миңа тиңсез кодрәт бирде // Шәһри Казан. — 1997. — 1 август.

Ә х м ә т җ а н о в  М. Күктә йолдызлар, җирдә без бар // Мәдәни җомга. — 1997. — 12 сентябрь.

Җ а м а л е т д и н о в  Л. Шагыйрь йөрәгендә ил язмышы // Байрак (Буа). — 1998. — 19 май.

Ф ә с х и  И. Гасырлар чатында очрашулар // Мәдәни җомга. — 2003. — 15 август.

К о л л е к т и в. Әхмәт Рәшит : биобиблиографик мәгълүматлар.— Казан:«Матбугат йорты» нәшр., 2001.

Б р о в м а н  Г. Перекличка времен // Литературная Россия. — 1964. — 27 июля.

С а л а х о в а  Д. Каждый человек переживает взлеты и падения (Беседа с поэтом А. Рашитовым) // Татарские края. — 1996. — июль.

## *Эчтәлек*

«Мөмкин» белән «түгел» арасы. *З.Мансуров* ............ 5

«Җир Кояш тирәли әйләнгән арада...» .................... 26
Кәбисә ел ..................................................... 26
Бер уйлап карасаң... ........................................ 27
И Ходаем, рәхмәтлебез Сиңа ............................... 29
«Әлмисактан алып шушы көнгә кадәр...» ................. 31
Рәсүлебез Мөхәммәд ......................................... 32
Бәйрәм мөбарәк булсын! ..................................... 34
Философлар хакында фәлсәфә ............................... 35
Фәлсәфи парадокслар ........................................ 36
Бәхетсезләрне кызганып... ................................... 38
Сәхәр вакыты .................................................. 39
И дөнья... ..................................................... 40
Җаннан каннар тамганда... .................................. 41
Халык васыяте бит ул ........................................ 42
Ялгызлык ....................................................... 43
«Кар-буранлы тар хәятта...» ................................ 44
Сонет ............................................................ 44
Күңел төшкәндә ............................................... 45
Мин үткәнгә кире кайтмас идем ............................ 45
«Кайсы байга барып башым иим...» ........................ 46
Сукбай эт ...................................................... 46
«Керфегемә кунган күз яшем...» ............................ 47
Авыру язмалар ................................................ 48
«Дошманнарым юк, дидем — алданганмын...» ........... 49
Ашыгыч ярдәм ................................................. 50
Гыйбрәт алыйк ................................................ 51
«Мин яшеннән, яшен ташыннан мин...» ................... 53
Шигырь бәйрәме — 2000 ..................................... 55
Мөһаҗирләр ................................................... 58
Без — бар ..................................................... 59
Без — татарлар ............................................... 61
Империя, ач күзеңне! ........................................ 76
Китап — хикмәт .............................................. 77

Колшәриф мәчете ........................................ 78
Корбан бәйрәме ........................................ 79
Динебезне зурлап ........................................ 83
Таптыңмы? ........................................ 84
Мәйдан көтә ........................................ 85
Уяныгыз, гладиаторлар! ........................................ 86
Офыклар аръягында ........................................ 88
Юксыну ........................................ 98
Күңелдә кинә калды ........................................ 99
Шагыйрь дигән исем картлык белми... ........................................ 101
Әллә?.. Әллә?.. ........................................ 102
Сәхнәләрнең иң түреннән ........................................ 102
Саклыйк дусларны ........................................ 103
Ул диңгезнең кайсын гына күрмәгән ........................................ 104
Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗан истәлегенә ........................................ 105
Соңгы юлга озатканда ........................................ 106
Камышлы ........................................ 107
Рәхмәтләр килә төяп ........................................ 108
Яралган ул ялкыннан... ........................................ 109
«Ватаны була күңелнең...» ........................................ 110
Ә йөрәктә милли хисләр... ........................................ 111
Киек казлар кайткан чакта ........................................ 111
Заман белән бәхәстә ........................................ 113
«Бу гармунның ни тылсымы бардыр?..» ........................................ 113
Җырлар сәламе ........................................ 114
Мәзәктәй мәзәкчән, мәкальдәй мәгънәле ........................................ 115
Әкиятче турында әкият ........................................ 116
Туплар тынып торганда ........................................ 117
Уртак җыр ........................................ 118
Исемем шундый минем ........................................ 119
Һәйкәл ........................................ 121
Хәтер ........................................ 124
Чорлар чатында ........................................ 125
Атам кабере кайда — кем әйтер?! ........................................ 126
Минем шәҗәрәм ........................................ 127
Илаһи моң булып... ........................................ 143
Җанга якын Норлатым ........................................ 149
Карт өянке ........................................ 150
Билгесез партизан кабере ........................................ 151
Вахитов мәктәбе хатирәләре ........................................ 160
Тостка чакыру ........................................ 165
Сабакташлар бергә җыелгач... ........................................ 165
Изге Болгар җирендә ........................................ 166
Селәү авылы бәетләре ........................................ 168

Бизнә .......... 168
Карман истәлеге .......... 169
Арча читекләре .......... 169
Республикам .......... 171
Кайту .......... 172
Юлчыларга теләк .......... 172
Дога .......... 173
Ялгыз ана җыры .......... 174
Казан .......... 175
Каршылау идиллиясе .......... 194
Биеккә! .......... 195
Кошлардан көнләшәм .......... 196
«Таң алдыннан берәү, моңнар сибеп...» .......... 198
Умырзая .......... 198
Нәрсә булды миңа? .......... 199
Таңда аңлашу .......... 200
Соңгы чәчәк .......... 201
Экспромт .......... 202
«Сак белән Сок кебек, карурманда...» .......... 204
«Кичкән чорда гомер экваторын...» .......... 204
Соңлап килгән мәхәббәт .......... 205
Гөлүсә .......... 206
Үкенеч .......... 207
Сулышыма утлар капкан .......... 208
«Ык буйлары ник уйларны...» .......... 208
Соңгы үпкә .......... 209
«Беләм, инде мине сөймисең син...» .......... 210
Соңгы очрашу .......... 210
Синең елмаюың .......... 211
Елама! .......... 212
Тәүбә .......... 213
Мәхәббәт вальсы .......... 214
Карлар ява .......... 215
Җаннар талпына .......... 216
Бишек җыры .......... 217
«Бөтенесен заман юньсез якка борды...» .......... 218
Күзге төндә .......... 219
Мәхәббәт сәерлекләре .......... 220
Ышанасы килә .......... 221
Хөкем .......... 222
Мәрхәбә, Яңа ел! .......... 224
Кыш иртәсе .......... 225
Әби белән Нәби .......... 226
«Ап-ак кар каплаган...» .......... 227

Яшенле яңгыр ........ 228
Сөекле матур калам ........ 229
«Яз атлый җирне яшәртеп...» ........ 230
Нинди икмәк тәмлерәк? ........ 231
Борчак һәм тугыз капкорсак ........ 235
Карурманда киңәшмә ........ 240
Исерек кырмыскалар ........ 242
«Баш шәрифләренә акыл кирәк тә...» ........ 244
Төш күреп уянгач, төн уртасында язган шигырь ........ 245
Тәүфыйксызлар ........ 246
Җыелыштан соң... ........ 247
Дөнья бу!.. ........ 248
И заман! ........ 249
Замана такмаклары ........ 250
Ходай ярлыкасын... ........ 252
Җыр бар чакта ........ 254
«Бауман урамыннан тотам юлны...» ........ 255
Трамвайда ........ 256
Ике әтәч ........ 257
Былтыргы күкәй ........ 259
Кайбер әсәрләрне укыганда... ........ 259
Карьерист ........ 260
Ходайга шөкер!.. ........ 260
Тәнкыйтьче портретын ясарга хыялланган рәссамга киңәш ........ 260
Китегез! ........ 261
Чукчаны талаганнар ........ 262

**Биографик белешмә** ........ 264
**Библиография** ........ 266

Литературно-художественное издание

*Ахмет Рашит*

*(**Рашитов** Ахмет Ахатович)*

**Ветры судьбы**

Стихи и поэмы

Казань. Татарское книжное издательство. 2006

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

*Әхмәт Рәшит*

*(**Рәшитов** Әхмәт Әхәтович)*

**Язмыш җилләре**

Шигырьләр һәм поэмалар

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы *Т.В.Пашагина*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә
салучысы *В.А.Савельева*
Корректорлары *Р.Н.Шакирова, С.Н.Галимуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 24.01.2006.
Форматы 70×90 $^1/_{32}$. Офсет кәгазе.
«Kudriashov» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 9,95. Шартлы буяу-оттиск 10,24.
Нәшер-хисап табагы 10,44. Тиражы 2000 д. Заказ З-33.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.